Татарстан Республикасы “Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте” дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе
"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе
"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының "Ямаширмә "Йолдыз" балалар бакчасы" мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

# “ИҢ МИЛЛИ ТӘРБИЯЧЕ”

## *( ТӘҖРИБӘ УРТАКЛАШУ)*

Биектау, 2023

Төзүче авторлар:

Яруллина М.Р. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе ярдәмчесе;

Габдрахманова Р.Г. - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе мәктәпкәчә белем бирү методисты;

Фәтхриева Э.А. - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе педагогларның һөнәри үсеше буенча методисты;

Гыймадиева Л.М. - “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә “Йолдыз” мәктәпкәчә бюджет белем бирү учреждениесе мөдире;

Төхфәтуллина Ә.Г. – филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы “Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте” дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе татар теле һәм әдәбияты укытучысы;

Яруллина А.Р. - “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә “Йолдыз” мәктәпкәчә бюджет белем бирү учреждениесе тәрбиячесе

“Иң милли тәрбияче”: бәйгегә килгән эшләр белән тәҗрибә уртаклашу җыентыгы./төз.авт:Яруллина М.Р., Габдрахманова Р.Г., Гыймадиева Л.М., Төхвәтуллина Ә.Г.,Фәтхриева Э.Ә., Яруллина А.Р.- Биектау, 2023.- 173 б.

Рецензент : Төхфәтуллина Ә.Г. – филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы “Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте” дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

Җыентыкка “Иң милли тәрбияче” Республикакүләм бәйгесенә килгән иң яхшы эшләр урын алды. Җыентык милли белем һәм тәрбия бирүче балалар бакчалары педагоглары, татар теле укытучылары, әти – әниләр өчен ярдәмлек булып тора.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы коллективы оештырган бәйгедә җиңүчеләрнең эшләреннән тупланган “Иң милли тәрбияче” дип аталган методик материаллар җыентыгына

**БӘЯЛӘМӘ**

Җыентык мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә билингваль белем бирү юнәлешендә эшләү һәм балаларда этномәдәни копетенция тәрбияләү максатын тормышка ашыруга юнәлтелүе белән актуаль. Анда балаларга ана телен өйрәтү бурычы халкыбызның әдәби байлыгына, фольклор мирасына, аның гореф-гадәтләренә таянып алып бару аша хәл ителә. Чөнки бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән рухи хәзинәләребезне саклап калу, онытыла башлаган гореф-гадәт, йолаларыбызның, иң матурларын сайлап алып, киләчәк буынга өйрәтү – мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе педагоглары алдында торган иң мөһим бурычларның берсе.

Үсеп килүче яшь буын өчен халкыбызның гасырлардан килгән зирәк акылы, моңлы күңеле, җор теле тудырган иҗат җәүһәрләре, йолалары, җырлары, бәйрәмнәре уеннары, гореф-гадәтләре – мөһим тәрбия чарасы. Бала кечкенә яшьтән шушы тарихи ядкарьләребезнең мәгънәсен аңлап, сеңдереп үскәндә генә анда милли үзаң формалаша ала. Тәрбиячеләрнең иҗади эзләнеп төзегән методик хезмәтләре туган як тарихын, мәдәниятын, гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәтү аша балаларга рухи-әхлакый һәм патриотик тәрбия бирүне күздә тота. Шулай ук туган телгә өйрәтү бурычын да тормышка ашырырга ярдәм итә. Авторлар чын милли җанлы, бар яктан үсешкә ия балалар тәрбияләүдә бәйрәмнәр, йолалар белән таныштыруның бик отышлы тәрбия чарасы булуын күздә тотып эш иткәннәр. Эшләр методик таләпләргә һәм балаларның яшь үзенчәлекләренә дә туры килә. Шулай ук аны тормышка ашыру принциплары, метод һәм алымнар, интерактив һәм мәгълүмати чаралар да Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандарты таләпләренә тулысынча җавап бирә. Төрле темаларны, халкыбызның бай мирасы булган гореф-гадәт, йолаларны эченә алган хезмәт балаларда бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү; ана телендә фикерли алуларын үстерү; йолаларны өйрәнеп, аңа үз мөнәсәбәтләрен белдерә алу; милли мәдәниятны, мәдәни мирасыбызны өйрәнү кебек белем һәм күнекмәләр бирүне күздә тота.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Биектау муниципаль районының Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы коллективы төзегән “ИҢ МИЛЛИ ТӘРБИЯЧЕ” дип аталган методик материаллар җыентыгы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә милли һәм патриотик тәрбия бирү юнәлешендә эшләү өчен файдалы чыганак.

Төхфәтуллина Ә.Г. – Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте укытучысы, филология фәннәре кандидаты

ЭЧТӘЛЕК


1. Халитова А. Р. *“Чәй яны - гаилә җаны”*.................................................. 7 б.
2. Фәйзрахманова Г. В. *“Беренче көлтә” бәйрәме*.................................. 12 б.
3. Әхмәтшина Ф.Ф. *“Тирес сугу” күренеше* ........................................... 20 б.
4. Зиннәтова Г. Б. *“Печән өмәсе” күренеше* ............................................. 26 б.
5. Касимова Л. Р. *“ Орчык өмәсе”* ........................................................... 31 б.
6. Каюмова Р.М., Сагитова Р.М. *“Базар ярминкә”* ................................... 37 б.
7. Шәмсиева Л.Г. *“Исемең матур кемнәр куйган?”*.................................. 42 б.
8. Рәхимова Г.Р. *“Хуш киләсең, Нәүрүз!”*................................................. 47 б.
9. Галиуллина А.М. “ *Бүген бездә Нардуган”* ........................................... 51 б.
10. Гыйлаҗиева Э. Г. *«Авылларда каз өмәсе гөрли»*................................ 57 б.
11.Гайфуллина Л.Ф. *“Карга боткасы”* .................................................... 69 б.
12. Хәмидуллина Л.Ф. *“ Гаилә бәйрәме”*.................................................... 77 б.
13.Вахитова Э.Г. *Серле сандык”* ................................................................ 83 б.
14.Хаматгалимова Й. Т. *“Акча кайдан килеп чыккан?”*............................ 88 б.
15.Сәхәбиева Г.Җ. *“ Лего мультфильм”*...................................................... 90 б.
16.Ибраһимова А. Р. *“Әкият аланында”*..................................................... 93 б.
17.Ибраһимова Л.Ә. *“ Татар милли ризыклары”* .................................... 101 б.
18.Закирова Ч.Г., Мөхәммәдиева Э.Р. *“ Урманчылык кәсепләре”* .......... 102б.
19.Әхмәтханова Г.К. *“Кара икмәк”*.......................................................... 112 б.
20.Хәсәнова Р.И. *“Кем ул тәрбияче?”* ...................................................... 114 б.
21.Әхмәтова Г. И. *“ Тылсымлы тартма”*.................................. ............ 117 б.
22.Йосыпова Г. Ф. *Мини – музей “Татар өе”*......................................... 120 б.
23.Камалиева Г. Р. *«Тылсымлы сандык»*.................................................. 124 б.
24.Зиатдинова Ф.Х.,Хисамова А.М.*«Айсылу һәм Аленага кунакка”*....... 131 б.
25.Мөхәммәтҗанова Р. С. *«Милләтләр дуслыгы»* .................................. 134 б.
26.Сафиуллина Л. А. *«Татар халкының җырлы-биюле уеннары»* ......... 136 б.
27.Шәйдуллина Л.Р. *“Тылсымлы бөҗра”* ................................................ 141 б.
28. Гайнетдинова М.А. *“ Милли киемнәр”* .............................................. 146 б.
29.Кәримуллина Г. С.*Мастер-класс “Энәсез пэчворк” (Кинусайго)*....... 147 б.

30.Абдрахманова Г.Р. *"Милли бизәкле букча"*.......................................... *152 б.*

31.Габделхаева Гөлшат Мәгъсүм кызы *“Виммельбух технологиясе кулланып – сөйләм үсеше аша әхлакый сыйфатлар тәрбияләү”.... ...................* *154 б.*

32.Гатауллина Э. Г. *“Балалар остахәнәсе”*............................................. *157 б.*

33.Габитова Р. Р.*“Гөлназның читекләре”*................................................ *159 б.*

34.Минһаҗева А. Р. *“Милли ризыклар-табын түрендә”*....... ................. *164 б.*

35.Минһаҗева Р.Г. *“ Сөмбикә ядкарьләре”*............................................ *167 б.*

36.Борханова Г.Г. “*Татар халкының милли ядкарьләре буйлап сәяхәт” ( маршрутлы уен)*......................................................................................... *174 б.*

37.Закирова Р. Н *"Бишек җыры"* ............................................................ *177 б.*

**КЕРЕШ**

Татарстан Республикасында 2030 елга кадәр милли мәгариф үсеше концепциясе расланды. Концепциянең максаты : заман шартларында милли мәдәниятне һәм телне саклау, үстерү, киләчәк буыннарга тапшыру өчен милли мәгарифне камилләштерү. Милли мәгариф системасын үстерү бүгенге көннең актуаль проблемаларының берсе булып санала. Дәүләт һәм ата-аналар алдында гаиләдә, балалар бакчасыннан алып, мәктәпкәчә ана телендә тәрбияләү һәм укыту мәсьәләсен хәл итү бурычы тора.

Бүгенге көн балалары, хәтта аларның ата-аналары да, радио һәм телевидение, урам йогынтысы нәтиҗәсендә, туган телен, туган халкының гореф-гадәтләрен камил белми. Шул сәбәпле, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында яшь буынга туган телләрендә белем һәм тәрбия бирү эшенә зур игътибар бирелергә тиеш.

“Иң милли тәрбияче” бәйгесе Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе тәрбиячеләре арасында милли белем һәм тәрбия бирүне гамәлгә ашыру һәм киң җәелдерү кысаларында гамәлгә ашырыла.

Милли гореф – гадәтләрне искә төшерү, аларны яңарту, миллилекне үстерү татар телле тәрбиячеләрнең төп бурычы булып тора. Шул максаттан оештырылган бәйгегә килгән иң уңышлы эшләрне сезнең хозурыгызга да тәкъдим итәбез.

**Гыймадиева Ләйлә Мансур кызы,**
*“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә “Йолдыз” мәктәпкәчә бюджет белем бирү учреждениесе мөдире*



Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Дөбъяз «Гөлчәчәк» балалар бакчасы», мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе беренче квалификацион категорияле тәрбиячесе

**Халитова Алсу Рафик кызы**

Чәй бәйрәме ***“Чәй яны - гаилә җаны”***

***Максат:***

1)Авыл халкын халкыбызның борынгыдын килгән чәй эчү традициясе, аның барлыкка килү тарихы, чәйнең сәламәтлеккә йогынтысы, файдасы белән таныштыру,

2) Татар халкының тормыш көнкүренешенә кызыксыну, халыкның үткәненә, гореф-гадәтләренә хөрмәт уятуга этәргеч ясау.

3) Авыл халкында үзара дуслык, бердәмлек, бер –берсенә ихтирам хисләре булдыру.

4) Авылдашларның иҗади сәләтләренә, аш-су пешерү osталыкларына соклану һәм хөрмәт хисләре уяту..

***Әзерлек:*** авылның урамнарында яшәүчеләр берләшеп әзерләнгән аш- су табыннары.

***Җиһазлау:*** “Чәегез тәмле булсын!” дигән плакат, чәй коробкаларыннан төзелгән күргәзмә, чәй өстәлләре, самавырлар күргәзмәсе, мәктәп музее күргәзмәсе.

1. А.Б. Исәнмесез, хәерле көн, авылдашлар, бәйрәмебезгә килгән кунаклар! Без сезне Дөбъяз авыл җирлегенең матур табигатендә күрүебезгә бик шатбыз. Ә бездә зур бәйрәм.

2. А.Б. “Без тынычта аттай эшлибез. Без сугышта арысландай көчлебез” дигән татарның бөек улы Габдулла Тукай. Хак сүзләр! Шөкер, әби –бабаларыбыз борын-борыннан кирәк чакта бар тырышлыгын куеп хезмәт итә белгән, ял итеп алган арада тальян моңнарына кушылып үзенә, якыннарына чын бәйрәм дә ясаган. Ләкин бер генә эшен дә “Бисмилла” сыз башламаган халкыбыз.

1. А.Б. Дога кылу- сөннәт гамәл. Дога –гыйбадәтнең желе, мөэминнең коралы, җир белән күкнең нуры, диннең терәге. “Дога кылып эчкән суның да булмышы үзгәрә, тагын да шифалы була”, -дип исбатлаган галимнәр дә. Ил-көннәребезгә, яшәгән җирләребезгә иминлек сорап, бүгенге бәйрәмебезне тагын да ямьләр өчен шушы урында сүзне Дөбъяз авылы җирлегендә гомер итүче Ләлә абыстай Усмановага бирәбез:

*Абыстайның чыгышы.*

1.А.Б. Ләлә абыстай. Бик зур рәхмәт сезгә. Барлык теләкләребез кабул булсын! Ә хәзер сүзне моңлы-җырлы “Казансу” ансамбленә бирәбез.

*Музыкаль номер.*

2.А.Б. Чәй... Күңелне күтәреп җибәрүче, җанны иркенәйтүче, арыганлыкны бетерүче, зиһенне ачучы, ялкаулыкны куычы һәм тәнне сафландыручы. Халкыбыз гомер-гомергә чәйне яратып кулланган. Эчәсе килсә дә, ашыйсы килсә дә, арыса-талса да, кәефе кырылса да, сөенеч шатлыклары ташып торса да халкыбыз шушы могъҗизалы эчемлеккә мөрәҗәгать иткән. Без дә сезне Чәй бәйрәменә чакырабыз. Исеме дә аның “Чәй яны- гаилә җаны” дип атала.

1.А.Б. Ә хәзер әйдәгез бераз гына чәй тарихына тукталып китик. Халкыбыз гомер-гомергә чәйне яратып кулланган. Элеккеге татар өйләрен җырлап утыручы самавырдан башка күз алдына китереп булмаган.

2.А.Б. Карл Фуксның татарлар турында язып калдырган истәлекләрендә дә “Татарларның чәй эчү, чәй белән кунакларны сыйлау –бик күркәм йола, кунакчыллык билгесе”, -дип яза.

1.А.Б. “Чәй”, “чәй эчәбез”- дибез. Ә чәйнең кайчан һәм кайда килеп чыгуы турында без ни беләбез соң?

2. А.Б. Бик күп гасырлар элек, Кытай императорына эчү өчен су кайнатканнар. Савытларына бер куактан яфрак төшкән һәм суның төсе карангыланган. Судан

бик хуш  ис килгәнен  тоеп алганнар шулчак. Эчеп карагач, гаҗәпкә калганнар. Димәк, чәй иң беренче Кытайда барлыкка килгән.

1.А.Б.Ә татарда чәй эчү кайчан башланган?

2.А.Б. Моны белү өчен күренекле мәгрифәтче Каюм Насыйри китергән риваятькә мөрәҗәгатъ итик:

“Бик борынгы заманда бик тә  диндар  суфый яшәгән ди. Ул гомеренең күп өлешен юлда уздырган. Бервакыт Төрекстанга килеп чыккан. Бик арыган, талчыккан бу. Кытай чигендә урнашкан бер авылда ял итеп алырга дип бер йортка кергән. Хуҗа  өенә килеп кергән талчыккан картны күреп, аны бик яхшы итеп кабул итә һәм аңа кайнар эчемлек бирә. Юлчы ике  чынаяк эчемлек эчә.  Һәм менә могҗиза, бөтен ару –талуы бетә, күңеле дә күтәрелеп китә. Ул мангаена бәреп чыккан тирләрен сөртә-сөртә: “Менә бу эчемлек ичмасам. Бу ходай бүләге. Монын турында кешеләргә сөйләргә кирәк”, - дип соклана.

1.А.Б. Менә шулай итеп халык арасында чәй эчү киң  җәелә. Бүген дә чәйнең дәрәҗәсе зур. Ул хәрвакыт  табын түрендә. Ә без сәхнәбез түренә шушы минутларда биюче кызларыбызны чакырабыз.

*Музыкаль номер. Бию.*

2.А.Б. Татар халкы борын- борыннан ук бик кунакчыл халык. Ул еш кунак җыю белән бергә, үзе дә кунакка йөрергә һәвәс, аның  табыны мул, ризыклары да күп төрле була.

1.А.Б. Рухы юмарт мөселман үзенең кунакчыллыгы белән аерылып тора. Ул кунакларны шатлык белән каршы ала һәм аларга хәленнән  килгәнчә кадер-хөрмәт күрсәтә. Рәсүлебез әйткән: “Аллахыга һәм Кыямәт көнендә инанган кеше үз кунагына хөрмәт күрсәтсен”.

2. А.Б. Ә хәзер бирегә хөрмәтле бәйрәмебезнең кунакларын  Татарстан Республикасы Татар Конгрессы  башкарма комитеты каршында эшләп килгән, татар хатын-кызларының “Ак калфак” иҗтимагый оешмасы  рәисе Кадрия Рәис кызы Идрисованы, Биектау муниципаль районының  башлыгы Рөстәм Галиулла

улы Калимуллинны, Дөбяз авыл җирлеге башлыгы Әсхәт Сөнатулла улы Низамовны, Биектау муниципаль районы Татар хатын-кызларының “Ак калфак” берлеге рәисе Гөлсинә Шәфыйк кызы Шакированы чакырабыз. Рәхим итегез.

*Кунакларның чыгышлары.*

1.А.Б. Теләк һәрчак уртак була диләр. Аны юллаучыга да, юлланучыга да матур көннәрнең дәвамын теләп бәйрәмебезне җыр-моң, дәртле биюләр белән үрәбез.

Музыкаль номер. Айзат Шакиров, Ләйсән Хайруллина башкаруында.

2.А.Б. Безнең бүгенге бәйрәмебез түбәндәгечә узачак. Билгеле булганча, бүгенге бәйрәмебез кунакчыл Дөбъяз җирлегендә уза. Димәк, бүгенге чарабызның хуҗалары- Дөбъязлылар.

1А.Б. “Әй, Дөбъязым - җәем, язым, ярату һәм сөю назым. Шул турыда җырлый җырлый урамнарын узамын”,- дип җырлаган җырны радиокинлекләре аша еш ишетәсез. Шул авыл урамнары бердәм булып, ләкин аерым-аерым, сый өстәлләре әзерләделәр. Һәр урам үз өстәлен якларга тиеш. Ә моның өчен сез, кунаклар, аларга ярдәм итәргә тиеш буласыз. Ягъни, һәр өстәлне карап, андагы сыйлардан авыз итеп, сездән фикерләр көтеп калабыз. Әлбәттә инде, төп игътибар чәйләргә һәм самавырларга булырга тиеш.

2.А.Б. Ә инде аның аралыгында сезгә күңелле уеннар, дәртле биюләр һәм берсеннән берсе матур, моңлы җырлар да бүләк итәрбез.

*Музыкаль номер. Парлы бию.*

*Өстәлләр үзләре белән таныштыралар.*

1.А.Б. Һәр мәктәптә диярлек туган төбәкне өйрәнү музейлары бар, алар укучыларда ватанпәрвәрлек хисләре, туган як тарихына, тормыш көнкүренешенә кызыксыну, халыкның үткәненә, гореф-гадәтләренә хөрмәт уятуга этәргеч булып тора. Дөбъяз урта урта мәктәбенең дә шундый горурлык өчен сәбәбе бар. 1994 нче елның 19 мартыннан анда мәктәп музее ачыла.

2.А.Б. Музей... Монда нәрсә генә юк! Укучылар музейны тулыландыру максатыннан аерым кешеләрдән, шәхси коллекционерлардан тарихи әйберләр, истәлекле язмалар җыйганнар. Күптөрле һәм эчтәлекле экспозицияләр

укучыларга туган төбәкнең үткәнен өйрәнергә, халкыбызның гореф-гадәтләренә, матур традицияләренә ихтирам тәрбияләүдә, тарихның төрле чорларында туган төбәгебез үсешенә зур хезмәт куйган шәхесләребез, Бөек Ватан сугышы каһарманнары, оешмалар турында күбрәк белергә ярдәм итәләр.

1.А.Б. Музей эшчәнлегендә туган ил тарихын өйрәтүгә зур игътибар бирелә. Укучылар өчен музейда үткәрелгән сыйныф сәгатьләре балаларга бай тарихи мәгълүмат бирә,тарихи вакыйгаларны аңларга ярдәм итә, илебез тарихына кызыксыну уята. Татар халкы тарихын өйрәнүдә музейда сакланган экспонатлар, фоторәсемнәр, китаплар белем һәм тәрбия бирүдә зур әһәмияткә ия. Әлеге музейның җанлы эшчәнлеге башында торучы якташыбыз, озак еллар Дөбъяз урта мәктәбендә укучыларга тарих фәнен өйрәтүче Азат Галлямов. Сүз уңаенан, үзем дә тарихка мәхәббәт уяткан Азат абый укучысы булум белән чиксез горурланам.

*Мәктәп музее җитәкчесе чыгышы.*

*Музыкаль номер “Су буенда” биюе.*

2.А.Б. Дөбъязлылар, гомүмән, тарихка битараф түгел алар. Авылдашыбыз Рәфик абыйның да шәхси музее бар. Анда бүгенге көндә 20 якын самавыр үрнәкләре бар. Үзен бирегә чакырыйк әле.

*(Шәхси коллекционер Рафик абый белән әңгәмә)*

*Музыкаль номер.*

2.А.Б. Замана гел алга омтыла. Бүген барлык эшләребезне автомат техника башкара. Керне юа да, киптерә дә –бик җиңел. Элек әбиләребез, апаларыбыз, гүзәл кызларыбыз кер чайкарга су буена юл тотканнар. Шушы урында әйдәгез бергәләп бию аша булса да шул елларга кайтып килик әле. Мәйдан түренә Дөбъяз музыка мәктәбе биючеләре чакырыла.

*Музыкаль номер.Бию.*

1.А.Б. Бүгенге бәйрәмебез ахырына якынлаша, хәзер инде сүзне жюри әгъзаларына бирәбез. Алар иң матур бизәлгән өстәлләрне билгеләр.

Сүз жюрига бирелә. Нәтиҗәләр ясала. Бүләкләр тапшырыла.
2.А.Б. Ачык чырай-такта чәй

Татарларның әхлак билгесе

Кунакчыллык якты чырай

Халкыбызның күңел көзгесе

“Хәерле” дип эш башлаган идек

“Хәерле” дип тәмам итәбез.

Шушы болында  кабат очрашуны

Түземсезлек белән көтәбез.

1.А.Б.Кадерле авылдашлар! Безнең чәй бәйрәмебез шуның белән тәмам. Иртәләрегез хуш исле тәмле чәйдән башлансын. Сезгә исәнлек-саулык, гаилә бәхете теләп калабыз.

*Бәйрәм чәй табыннары  артында дәвам итә.*



Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Бала үсеше үзәге - Арча шәһәре 4 нче балалар бакчасы" муниципаль  бюджет  мәктәпкәчә белем учреждениесе физик тәрбия инструкторы

**Фәйзрахманова  Гөлназ Вәзил кызы**

***“Беренче көлтә” бәйрәме***

**Максат:** әби-бабаларыбыз белгәнне яшь буынга калдыру;

Халкыбызның тарихын, гореф-гадәтләрен, йолаларын, җыр-моңнарын, уеннарын, икмәкнең каян килгәнен күрсәтү;

Хезмәт кешенә дан җырлау;

Балаларның сөйләм күнекмәләрен үстерү;

**Җиһазлау** :компьютер, арба, курчак, төенчекләр,кечкенә ураклар(картоннан ясалган) балалар саны буенча, сандык 2 штук, киемнәр балалар саны буенча (альяпкыч, чабата, кәләпүш, яулык), зур сөлге 2 пар, кәчтрүл 2 штук, суган, он, бәрәңге, кишер, йомырка ( уеннар өчен атрибутлар), кечкенә таякчыклар, каеш , фанердан ясалган ат сыны 2 пар, милли бизәкләр балалар саны буенча,камка рәсеме.

Зал көзге басу итеп бизәлгән.Сәхнә артында сыер мөгрәгән, сандугач сайраган, чыбыркы шартлаткан тавышлар ишетелә.5 бала төенчекләр,ураклар күтәреп чыгалар.

**1 нче бала** (арбадагы баланың урынын рәтләштреп куя).Менә кызым,килеп тә җиттек,елама , йокла яме.

**2 нче бала.** Кызлар, төенчекләрне менә шунда куйыйк әле!

Күтәреп килгән төенчекләрен залның бер почмагына куялар.

**3 нче бала.** Җәмәгать эш башларга вакыт,кояш тау өстеннән күтәрелеп килә.

**Барысы:** Әйдәгез, башлыйбыз!!!

“Уракчы кыз” җыры башкарыла. Урак күтәргән балалар,ике яктан җырлый-җырлый чыгып, зал уртасыннан парлап төшәләр. Аннан бер пар уң якка, бер пар сул якка китәләр.Зал уртасында очрашып 4 рәт булып төшәләр.

Нәни ураклар белән гомуми үсеш күнегүләре ясыйлар.

1. “Ураклрны күрсәт”
   Төп торыш: куллар аста,аяклар җилкә киңлегендә.
   1-уракларны өскә күтәрәбез
   2- уракларны аска төшерәбез.(6 тапкыр кабатлау)
2. “Бер- береңә күрсәт”
   Төп торыш: шул ук.
   1- Уракларны алга күтәрәбез

2- Уңга(сулга) борылабыз, кулларны кырыйга сузабыз.

3- Уракларны алга күтәрәбез

4- Төп торышка кайтабыз.(6 тапкыр кабатлау)

3. “Ураклар җирдә”

Төп торыш: шул ук.

1-Чүгәлибез, уракларны калдырабыз.

2-Төп торыш

3-Чүгәлибез, уракларны алабыз.

4-Төп торыш .(6 тапкыр кабатлау)

Уракларны җыеп куеп, урындыкларга утыралар.

**Алып баручы:** Хәерле көн, балакайлар! Татар халкының милли бәйрәмнәре бик күп. Тик кызганыч, күбесе инде онытылып беткән. Бүген без монда рухи хәзинәләрбзнең берсе булган “Беренче көлтә” бәйрәменә җылдык.

**4 нче бала**. Халкыбызның йолаларын

Искә төшерик әле.

Гомергә истә калсын диеп

“Беренче көлтә” үткәрик әле.

**5 нче бала.** Ә “Беренче көлтә” бәйрәме нәрсәне аңлата? Ул кайчан уздырыла?

**Алып баручы.** Авылларда уракка төшүнең борынгыдан килгән үз тәртибе , үз яме булган. Игеннәр өлгергәч, уракка төшәр вакыт җиткәч,уздырылган бу бәйрәм. Яше-карты,бала-чагасы әбәд төенчекләрен күтәреп иртә таңнан эшкә кузгалган. Иртәнге дүрттән соңга калган кешене басу капкасыннан кертми торган булганнар, дип искә ала авылыбыз өлкәннәре.Ә бала-чага җирдә калган башакларны җыярга ярдәм иткән. Бәйрәмбезне бүгенге заманга яраклаштырып уздырырга тырышырбыз. Биербез, җырларбыз,борынгы, онытылган барган бабаларыбыз уйнаган уеннарны уйнарбыз.

Әби-бабаларыбыз , иң бернче эш итеп, сандык төпләрендә яшеренеп яткан чиста, матур (ак альяпкыч, чабата, тастымал, чүлмәк) киемнәрен барлап

куйганнар. Әйдәгез, бездә сандыкларыбызны барлыйк, матур киемнәрбезне киеп карыйк!

**Уен “Сандыкта niләр яшеренгән?”.** Залның бер башында сандык куела. Эчендә төрле киемнәр. Балалар ,сигнал булуга ике командага бүленеп, сандыкка барып кием алып кияләр.

**Алып баручы:** Әфәрин,балалар! Булдырдыгыз. Ә хәзер киемнәрнең атамаларын искә төшерик.

Соңрак атларын бизәргә керешәләр. Бездә атларыбызны бизәп, җигеп куйыйк!

**Уен “Милли атларны бизәү”.** Залның бер башына ат  сыннары куела. Балалар сигнал булуга, бер милли бизәк алып ат  сынын бизиләр. Кайсы команда тизрәк бизәп бетерә. Мили бизәкләрнең атамаларын атау.

Киләсе эшебез (уеныбыз**) “Әбәд төенчеге җыю”.** Һәр кеше үзе белән басуда ашарга алып бара.Залның бер башында азык- төлек куела. Балалар кирәклесен генә алып төенчек җыярга тиешләр.

**Алып баручы**. Барысы да әзер, бәйрәмебезне дәвам итик!

**Балалар барысы бергә:** “Уракка төшер чак җитте!”диләр.

**Алып баручы**:  Никтер кояш күренми. Әйдәгез ,кояшны чакырыйк әле, балакайларым! Җылырак булып китәр.

Кояшка эндәш:
Кояш, чык!
Аяз, ач,
Болыт, кач,
Без эшләрбез җылыткач!

**Алып баручы**. Менә кояш та күренде. Элек уракны бер уңган кешедән башлатканнар.  Кем башлаган икән, бигрәк авыр булды быел, кулларны кисеп бетердек, дигәннәр. Ә усал кешеләр исә, караңгыда чыгып башлап куя торган

булганнар. Әйдәгез, кайсыгызның кулы җиңел икән? Карап карыйк! Кемнән башлыйбыз?

Балаларның җаваплары.

**Уен “Урак уру”.** Ике командага тигез итеп бүленәбез. Бер егет чалгы белән урып бара, икенче кыз җирдә яткан башаклардан көлтә бәйли, өченче кыз көшел өеп куя.

**Алып баручы**. Беренче көлтәләребез дә бәйләнде. Булдырдыгыз, балакайларым!

**Барысы бергә**

“Илебез халкы тук булсын,
Игеннәребез күп булсын
Эшләребез гөрләп торсын
Каршылыклар булмасын!!!”

Шулвакыт бер малай “Карагыз әле, минем кулыма камка килеп кунды. Бабам өйрәткән әйтенүне бергәләп кабатлыйк, дусларым!

Нәпис-купис,
Киявең килә, кач, кач.
Көмеш капкаңны яп,яп,
Тимер капкаңны ач,ач!!!

**Бер кыз.** Әйдәгез, әз генә ял да итеп алыйк. Күп эшләдек, такмаклар әйтешик!

*Егетләр җырлыйлар:*

Яшел саплы урак белән
Урак урасым килә.
Эй, дусларым сезнең белән
Бергә яшисем килә!

*Кызлар :*

Егетләре килгәннәр,

Ишек ачып кергәннәр.

Безнең өмәгә барганны,

Эллә кайдан белгәннәр.

*Егетләр:*

Кызлар урак уралар,

Зурат сылап куялар

Җир башыннан егет узса,

Ашамыйча туялар.

*Кызлар:*

Чылтырамый, чылтырамый

Чылтырамый тәңкәсе,

Моның гына чаклы бии

Безнең чеби бәбкәсе.

**6 нчы бала.**Бигрәк күңелле булып китте. Бабаларыбыз уйнаган уеннарыбызны **“Йозаклыны**” уйнап алыйк әле!

Ике уенчы кулга-кул тотынышып, “йозак ясап” басалар. Калганнар җырлый-җырлый, түгәрәк буйлап бер- бер артлы биек “йозак” аша үтәләр. Җыр туктауга йозак эчендә калган уенчы уеннан чыга.

**7 нче бала**.Ә минем бабаларым **“Агыйдел күперен**” уйнаганнар. Телисезме, өйрәтәм? Парлар бер- бер артлы тезеләләр. Алда берәү парсыз булып басып тора. Җыр вакытында парлылар, тотынган кулларын селкеп, аякларын тыпырдатып биеп торалар. Алдагы кеше, тоттынган куллар астыннан чыкканда, үзенә иптәш алып чыгып, парлылар артына баса. Уен берөзлексез “агым булып” дәвам итә.

**Алып баручы**. Эш, җыр,уен, бию барысы бергә үрелеп барылган.

Әбәд вакыты якынлашкан... Ул үзе бер бәйрәм төсен алган. Кырда ашарга пешерүче “кашавар” дип аталган. Ул умач уып, әбәд җиткәч тәмле аш

пешергән.Ә сезнең, балакайларым умач ашы ашаганыгыз бармы? Менә хәзер пешереп карарбыз.

**Уен “Умач ашы пешерү**” . Залның бер ягында аш пешерү өчен кирәк булган әйберләр ята. Кызлар  ике командага бүленеп  аш пешерәләр.

**Алып баручы:** Аш пешеп чыкканчы егетләребез **“Йомырка”(“Күкәй”) уенын** уйнарлар.

Элек кош-корт күп асраганнар. Әниләр йомырка пешереп биргәннәр. Һәр кеше алып килгән йомыркасын тезеп куя  . Туплар булмаганлыктан, ике түбәтәйнең эченә чүпрәк тутырып бәйләп куялар. Түбәтәйдән эшләнгән тупны тәгәрәтеп җибәрәсең, йомыркага тисә - ул синеке.Тидерә алмасаң, уеннан чыгасың.

**1 малай.** Бигрәк күңелле уен булды бу!

**1 кыз.**Ашларыбыз әзер, егетләр! Табын түренә , рәхим итегез!

**Алып баручы**. Кашавар кояш төш турысына җитүен атламлап белгәч, кырда эшләүче халыкны ашка чакырган.  Умач ашы бик тәмле булды. Телдән язмыйк тагы. Әйдәгез “Башы телемдә, ахыры төендә” уенын уйнап алыйк. Мин мәкальнең башын әйтәм, ә сез ахырын дәвам итәрсез.

-Эш беткәч, уйнарга ярый.

-Эшләмәгән ашамый.

-Җәй эшләсәң кыш ашарсың.

-Көн-эш, төн – ял өчен.

**Алып баручы.** Булдырдыгыз, балакайларым. Бик зирәк балалар икәнсез. Тамак ялгап алганнан соң яше - карты эшләрен ,ә балалар уеннарын дәвам иткәннәр.

**8 нче бала**. Тагын бер кызык уйнап карыйсыгыз киләме? **“Каеш салыш”** уены. Егетләрнең каешын аласың да кызның исеме белән әйтеп теге егеткә сала.

Мәсәлән, Алсу идәндә ята, диеп. Әгәр дә Алсуны яраткан кеше булса, ул каешны ала. Кызлар салганда егетләр исемен әйтеп салалар.

**9 нчы бала.** Мин тагын бер уен беләм. **"Биш мунчалы" .** Элек шобага әйтешеп командаларга бүленик.

-Тешләп тимер өзгән кирәкме,

Өреп пыяла ваткан кирәкме?

-Гөрләп торган алмагач кирәкме,

Сайрап торган сандугач кирәкме?

Таяклар ярдәмендә 5-10-15 тирәсе ара калдырып урыннар билгеләнә.Болар мунча диеп атала. Һәр команда берсенә-берсе каршы килә. Уенның төп максаты кайсы як күрше якка тизрәк чыгып бетә. Бер команда беренчә мунчадан, икенче команда бишенче мунчадан башлыйлар. Беренче уенчылар берүк вакытта сикерәләр. Калганнар көтеп тора. Беренче уенчы сикереп бетүгә икенче уенчы сикерә. Уен шулай дәвам итә.

**10 нчы бала**. Уйнаган көе элекеге уеннарыбызның берсе булган **"Чүрәкәйле"** не дә уйнап алыйк инде. Бер мәйданчыкка казык кагыла, аның башына ботаклы агач кисәгеннән "чүрәкәй" ясалып, элеп куела. Казыкның биеклеге ярты метрдан артык булмый. Менә шул "чүрәкәйне" бер әби саклап тора, калган уенчылар 8-10 адым ераклыктан чүрәкәйне таяк ыргытып бәреп тәшерергә омтыла. Кемнеке ераккарак очып китә. Әби тизрәк чүрәкәйне алып кире урнаштырырга тиеш. Таякны ыргытучы шул арада йөгереп барып үзенең таягын алып кире урынына басарга тиеш. Барып җитмәсә "әби" булып кала. Бу уенда җитезләр генә ота.

**Алып баручы**. Балалар инде кояш та сүрелде. Безгә дә өйләребезгә кайтырга вакыт.Бәйрәмебез бик күңелле үтте. "Беренче көлтә" бәйрәме менә шулай узган. Эшен дә эшләгәннәр, күңел дә ачканнар. Игенне уручылар ярышып

эшләгәннәр. Алдынгы бригадага Кызыл әләм тапшырылган, артта калган кешеләргә ташбака төшерелгән чыпта бирелгән. Шуңа күрә һәр кеше тырышып эшләргә тырышкан.Хәзер дә бу бәйрәмнәребез онытылмый. Ел да уздырылып килә. Бездә әби- бабайларыбызның милли бәйрәмнәрен онытмыйк. Аларның дәвамчылары икәнне һәрвакыт истә тотыйк! Сау-сәламәт булыйк!

Татарстан республикасы Сарман муниципаль районы "Зур Нөркәй “Кояшкай” балалар бакчасы" муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесесе

1 категорияле тәрбиячесе

**Әхмәтшина Фәридә Фоат кызы**

***«Тирес сугу күренеше»***

**Максат:** балаларда татар халык аваз иҗаты аша халкыбызның традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү.

**Бурычлар:**

- Балаларның монологик, кара-каршы, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерүгә, татар халык иҗатын тулырак күзаллау өчен шартлар тудыру;
- сәнгатькә, сәхнәгә, иҗатка тарту, сәләтләрен үстерү, иҗади фикерләүгә якынайту;
- балаларда милли үзаң, горурлык хисләрен уяту.
- Балаларда кызыксынучанлыкны, иҗади мөмкинлекләрне, танып белү активлыгын үстерү.
- Уеннар аша балаларда гомум кешелек, намуслылык, тугърылык, кайгыртучанлык сыйфатларын тәрбияләү.

Җиһазлау: татар өе күренеше, палас, калыплар, түбәтәй, чигүле мендәр, чәшкеләр, самавыр, бал мичкәсе.

*Фәридә апа өендә. Калыпларны, кирпичләрне чыгаралар. Палас җәеп,*

*самавыр, 1-2 чынаяк, бал мичкәсе куялар.*

**(**Фәридә апа җыр җырлап чынаяклар әзерли)

**Җыр:** Алым җәл түгел сиңа.

***Кызлар килеп керәләр. Ишеккә шакып:*** Фәридә апа! Исәнмесез!

**Фәридә апа:** Исәнмесез, кызлар! Әйдәгез, керегез, керегез!

- Өмәбезне башлар алдыннан, чәйләп алыйк. Менә кичә генә бал аерткан идек. Бал белән тәмләп чәй эчик әле. *(Шау-гөр килеп кызлар керәләр, утырышалар, көлешәләр, чәй ясыйлар.)*

***Малайлар керә.***

**1 малай:**Исәнмесез, кызлар, һавадагы йолдызлар, ерык авызлар.

**Фәридә апа:** Бәй, Сез дә тирес сугарга килдегез мени?

**2 малай:** Юк, тирес сугарга килмәдек.

**3 малай:**Менә бер табышмагыма җавап эзләп йөри идек әле. Шуңа җавап табып булыр микән, юк микән.

**Фәридә апа:** Әйдә, әйт әле шул табышмагыңны, күмәкләшеп уйлап карыйк.

**2 малай**. Тыңлагыз: Менә мондый табышмак ишеткәнегез бармы икән сезнең?

Ыж-ыж аждаһа,
Йөрәгендә уты бар,
Корсагында суы бар,
Түбәсендә күзе бар,
Ярый әле үзе бар. (*Самовар*)

**2 кыз:** Ай –һай ни булыр микән инде ул, кызлар?

**3 кыз:** Паровоздыр әле. Йөрәгендә уты да булгач.

**Фәридә апа:**Юк-юккк. Кызлар. Паровоз тугел. Менә без инде ул. Аждаха булгач кайнанадыр инде ул? Безне гел шулай диләр бит. (*Көлеш)*

**4 кыз:** Юктыр, алай түгелдер ул.

**1 малай.** Сез бик кыстагач утырыйм әле мин дә .(көлешеләр)

**БЕРГӘ:** Әйдәле, утыр әле.

**5 кыз:** Каяле, миндә бер табышмак әйтим эле.

Яткан җире – җир булыр, ботка булыр, таш булыр

Иң соңыннан көл булыр. Басуларга сибәрләр, игеннәр үстерерләр.

Кайсыгыз белә? Яле, ныклабрак уйлагыз әле.

**4 кыз:** Менә монысы тирес була. Борын-борын заманнарда, әби-бабайларыбыз тиресләрне теләсә кая түкмәгәннәр, тиресләрдән кирпечләр сукканнар. Кирпичләрне мичләргә ягып, өйләребезне җылытканнар, ә көлләрен бакчаларга түккәннәр. Бик яхшы ашлама булган.

Фәридә апа: Дөрес, балалар. Бабайларыбыз заманында тиресне беркайчан да ташламаганнар. Аны ашлама буларак кулланганнар. Алар белән өйләр җылытылган. Безнең бабаларыбыз тиресне кадерләп җыйганнар, аннары болгатып, озын агач формага салып, аны ялангач аяклары белән томалап тыгызлап куйганнар, кирпеч кебек брикетлар килеп чыккан һәм аларны кояшка куеп киптергәннәр. Алар кипкәч, коры урынга өеп куйганнар, кәрҗингә салып алып кереп, кыш буе шуның белән өйләрен җылытканнар. Борынгы ырым буенча, кояшта киптерелгән, кояш нурларын сеңдергән тирес кышын күбрәк җылылык биргән.

**БЕРГӘ:** әйее, бик дөрес.

**6 кыз:** Карале, туганкай, синең табышмагыңның җавабы – Самавыр түгелме?

**2 малай**. Белделәр бит, ә!

**7 кыз:** Әлбәттә Самавыр була, кайчаннан бирле Самавырдан чәй агызып утырып, шуны белмә инде, ә?

**Фәридә апа:** Кызлар, малайлар, әйдәгез әле миңа һөнәрләрегезне күрсәтеп,бер җырлап, уйнап алыйк булмаса.

**8 кыз:** Уттай эш вакытында нинди җыр җырлап утыру ди инде ул, яңгырга чаклы тиресләрне сугып өлгерергә кирәк.

**3 кыз:**-и, Ләйсән, туганым, тукта инде, кая шулай ашыгасың, эш бүре түгел, урманга качмас, азрак җыр җырлап алсак, арганнар бетеп китәр.

**8 кыз:** Ярар инде, ярар, тулке 1-2 генә җыр.

**Бергә.** Әйдәгез әйдә. Рәмис, уйна гармуныңны!

**"Зәңгәр чәчәк"**

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бала, чигүле кечкенә мендәр тотып, уртага чыгып баса. Балалар түгәрәк буенча җырлап әйләнәләр:

Юл читендә зәңгәр чәчәк
Якты нурлар тарата.
Безнең кызлар һәм малайлар
Зәңгәр чәчәк ярата.

Туктап биеп-җырлап торалар, ә уртадагы бала, мендәр тотып, түгәрәк буенча биеп йөри:

Якын дуслар арасыннан
Берсен сайлап ал әле.
Тезләреңә ипле булыр -
Мендәреңне сал әле.

Мендәр тоткан бала мендәрен бер бала алдына куя һәм, тезләнеп, аңа кулын бирә. Ул бала аның тирәли әйләнә, башкалар кул чабып торалар.

**( җырлаганда 1-2 се самавыр белән чәшкаларны алып керәләр)**

**Фәридә апа:** Ай-һай, кызлар, җегетләр, Бигрәкләр моңлы җырлыйсыз инде, менә яшь чакларым искә төшеп китте бит әле. Әллә мин әйтәм, әзрәк селкенеп алыйк микән, дим.

**БЕРГӘ:** Әйе шул, әйдәгез, әйдә (көлешәләр, кул чабалар, такмаклыйлар)

**(*барысы да торалар, бию, уен башлана*)**

**"Түбәтәй" уены**

Түбәтәйнең иң матурын кигәнсең,
Бик ераклардан кунакка килгәнсең.
Эшкә батыр, төскә матур икәнсең,
Тирә-юньне сокландырыйм, дигәнсең

Бала түбәтәен алып, бер балага бирә, түбәтәйне бер-берсенә биреп түгәрәккә җибәрәләр. Җыр дәвам итә.

Кушымта. Түп-түп, түп түгәрәк түбәтәй,

Түп-түп, түп түгәрәк түбәтәй,

Түбәтәем энҗеле дә, укалы,

Түбәтәем менә кемдә туктады.

(җәзалар: Милла шигырь, санамыш һ.б.)

**Бию "Шома бас"**

**2 малай:** Ай, булдырдыгыз кызлааар!

**4 кыз:** Ягез кызлар, җитәр, җитәр, эшебез кала, төшкә җитеп киләбез, әйдәгез, җәтрәк булыгыз, әйдә,әйдә. *(Калыплар янына килеп басалар)*

**1 кыз:**Я ярар, эшебезне башлыйбыз, изге сәгатьтә булсын!

**Фәридә апа:** Икендегә җитмәсен,

чыкны –суны күрмәсен.

Ай күрде, кояш алды,

эшнең башы уң булсын, дип башлыйбыз.

**Фәридә апа:** Я кызлар, кулларыгызны, аякларыгызны майладыгызмы?

**БЕРГӘ:**Майладык, майладык. (Җиңнәрен сызганалар)

**Фәридә апа:** Ә калыпларыгызны , такталарыгызны суладыгызмы?

**БЕРГӘ:** (иелеп) Суладык, суладык.

**Фәридә апа:** Алайса, аллага тапшырып, башлыйк.

**7 кыз:** Әйдәгез, әйдә, исән-сау сугып бетерергә язсын. (*калыптагылар үзләре сала.*)

**3 кыз:** куй елы –кытлык, **5 кыз:** сыер елы-туклык,

**2 кыз:** Куян елы –йотлык, **1 малай.** барс елы байлык,

**6 кыз:** Кошлар елы-уңсын, **2 малай:** буранлы –карлы булсын.

**4 малай:**Суккан тиресләребез, кыш буена җитсен,

**Фәридә апа:** бәрәкәтле булсын,

**(Бергә)**Бәрәкәтле булсын.

**Фәридә апа:** И, рәхмәт яугырлары. Менә бит эшебезне дә тәмамладык. Хәзер

эш беткәч, җырлап-уйнап алсак та ярый.

**“Төен”** уены.

**1 бала: -** Әйдәгез, санамышлар, тизәйткечләр әйтешәбез.

Ыргадан, мыргадан
Мәче йөри колгадан.
Мәче түгел, ата каз,
Ата казның башы таз.
Сыртыңа төшкәнче таш,
Тизрәк моннан чыгып кач!
Чак-чак кабып чәк-чәкне.
Чәй эчү бигрәк тәмле,
Чәшкеләре чәчкәле.

Чәк-чәк белән чәй эчкәндә,
Мияу, мияу мышлаган,
Мич башында кышлаган.
Бүген тычкан тотмаган,
Тотар иде – йоклаган.
Баш бармак бау ишә,
Имән бармак имән кисә,
Урта бармак утын яра,
Атсыз бармак ат җигә,
Чәнчә бармак чәй эчә.

- Әйдәгез, бер биеп тә алыйк

**Бию “Без бит авыл малае”** (балачак күренешләре)

**Хор:** Әби – бабайларыбызның йолалары онытылмасын, милли рухыбыз сүнмәсен!



Татарстан республикасы Арча муниципаль районы
“Арча 1 нче балалар бакчасы” муниципаль бюджет
мәктәпкәчә белем учреждениесе тәрбиячесе

**Зиннәтова Гөлнара Барый кызы**

**“Печән өмәсе” күренеше**

**Максат:** Балаларны татар халкының милли гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыруны дәвам итү, бу гореф-гадәтләрне, йолаларны сакларга кызыксындыру.

**Бурычлар:** 1.Милли җырлы-биюле уеннар аша татар телебезне сакларга, хөрмәт итәргә өйрәтү.

2. Татар телендә аралашуларын камилләштерү, сынамышлар, такмаклар өйрәтү.

3.Табигатькә сакчыл караш тәрбияләү, сезонлы эш вакытында әти-әниләренә ярдәмләшергә кызыксындыру, һәр ел фасылына хас үзенчәлекләр белән таныштыру.

**Җиһазлау:** зал печән басуы күренешендә бизәлә, идәндә яшел тукыма өстендә чын печән түкләре, ясалган печән көлтәләре, чүмәләләре, урман буенда яшел чирәмлек, агачлар, агач бүкәннәре, уфалла арбасы, бедон, ашьяулык, ризыклар, агачтан ясалган чалгылар, ураклар, интерактив такта, презентация, кош тавышлары, печән чапкандагы чалгы тавышы, татарча бию көе, “Уракчы кыз”, “Батыр егет печән чаба” җырлары.

**Барышы:**

*Зал печән басуы күренеше белән бизәлгән. Әби белән бабай урман аланына килеп, печәннең өлгерүен карап йөриләр. Кошлар сайлавы ишетелә. Интерактив тактада өлгергән печәннәр күренә.*

**Әби:** Бабайсы, карале, өлгергән бит бу печән, тизрәк җыярга кирәк.

**Бабай:** Әйе шул, бик яхшы булып үсеп җиткән печәннәр, көннәр дә бик кызу тора, яңгырларга киткәнче печәнне чабып, җыеп эшен бетерергә кирәк.

**Әби:** Бабайсы, әйдә, печән чабу өмәсенә балаларны чакырыйк әле.

**Бабай:** Андый ярдәмчеләр булганда бик тиз җыеп куярбыз без аны, Аллаһы боерса.

**Әби:** ИншәәАллаһ, бабайсы. Оланнар, балалар бирегә килегез әле!

*Татар халык киеменнән Солтан керә, башында түбәтәй,*

**Солтан:** Әссәләмәгәләйкүм, әбекәй, бабакай, ни булды?

**Бабай:** Вәгәләйкүмәссәләм улым Солтан. Менә печәннәр дә өлгергән, җыеп аласы иде дә бит.

**Солтан:** Борчылмагыз, әбекәй, бабакай! Хәзер җыябыз аны! Шаулатып печән өмәсе ясыйбыз!

Әй, малайлар, кызлар, килегез әле! Чалгылырны, уракларны алыгыз әле! Печән өмәсе башлана!

*"Батыр егет печән чаба" көе яңгырый. Татар милли киемнәре кигән балалар керә. Кулларында чалгылар, кызлар урак тотканнар. Олылар белән исәнләшәләр.*

**Балалар:** Әссәләмү галәйкүм, әбекәй, бабакай.

**Бабай:** Вәгаләйкүмәссәләм балалар. Ай рәхмәт төшкерләре , балакайларым, ярый әле сез килдегез, яңгырларга киткәнче печәнне чабып, җыеп куясы иде.

**Әби :** Менә бит мондый балалар булганда печәнне дә тиз арада чабып, җыеп алырлар, Аллаһы борса.

**Бабай:** Аллаһы Тәгалә куәт , көч бирсен!

**Әби :** Сез эшләгез, эшләгез, ә без бабагыз белән төшке аш әзерләп алып килербез. Армыйча эшләгез!

*Әби һәм бабай чыгып китә. Печән чапкандагы чалгы тавышы яңгырый. Экранда печән чабучылар күренеше. Балалар эшли башлый. Алгы рәттә малайлар чалгы белән печән чабалар, арткы рәттә кызлар урак белән печән уралар, печәнне көлтәлиләр .*

*"Уракчы кызы" җыры яңгырый. Бераздан әби белән бабай уфалла арбасы тартып керәләр.*

**Бабай:** Печән чабучыларга, урак уручыларга әссәләмү галәйкүм! Печәннәр мул булсын! Илләр көннәр тыныч булсын!

**Әби :** Бу кызуда эшләп аргансыздыр, чалгы, уракларыгызны читкә куеп торыгыз, әзрәк ял итеп тамак ялгап алыгыз.

**Бабай:** Әйдәгез балалар, менә бу аланлыкта табын корып җибәрик. Тамагыгыз да ачкандыр инде! Сез дә ярдәм итегез.

*Әби белән бабай ашьяулык җәяләр,ризыклар куялар, бедон белән су куялар, балалар булыша. Ашьяулык тирәли утыралар.*

**Бабай:** Менә авылыбызның чишмәсеннән сезгә дип шифалы су алып килдек!

**Бала:** Каян белдең, бабакай, бик сусаган идек!

*Балалар ризыкларны мактый, мактый ашыйлар.*

**Бала:** Бәлешең бигрәк тәмле булган, әбекәй!

**Бабай:** Әбиегез бик тәмле пешерә шул!

**Бала:** Ипиең дә уңган!

**Әби :** И эшләгән кебек тырышып ашагыз балакайлар!

**Бала:** Чабып бетердек бетерүен, яңгыр яумасмы икән?

**Бабай:** Юк, юк яумас, иншәәАллаһ. Бүген иртән чык күп төшкән иде, көне бик эссе була, печән бик тиз кибәр.

**Бала:** Ә безнең иртән мәче табанын ялады. Әби әйткән иде, әгәр дә мәче табанын ялаcard, көн аяз була, дигән иде.

**Әби:** И, рәхмәт төшкере, балакаем, бик хак сүзләр!

**Бала:** Әнә бит бака да су эчендә кычкыра – димәк көн аяз була.

**Бабай:** Бик дөрес әйтәсең, олан.

**Бала:** Ә мин тилгән кычкырганны ишеттем. Тилгән кычкырса да, көн аяз була.

**Бабай:** Карале, әбисе балалар бик күп сынамышлар да беләләр икән.

**Әби :** Шулай шул, сүбхәәнәАллаһ, күзләр тимәсен, сүзгә оста, эшкә сәләтле балалар икәнсез, үстергән эти- әниләрегезгә рәхмәт! Ашагач бер дога кылып алыйк , оланнар.

*Барысыда дога кылалар, рәхмәт әйтәләр.Табынны җыештырып куялар.*

**Бабай:** Без яшь чакта да печән өмәләре үткәрә идек. Бик кызык була иде, имә әбисе.

**Әби:** Әйе шул, бабайсы, бик күңелле була иде. Күмәкләшеп эшли идек, матур итеп ял  да  итә идек. Әйдә сез дә күңел ачып алыгыз әле!

**Бала:** Кызлар, малайлар, әйдәгез такмак әйтешәбез!

**Бала:** Әйдәгез!

*Кызлар, малайлар кара –каршы тезелеп басалар, әби белән бабай бүкәнгә утыралар.*

Идәнегез тигез икән,
Фанер җәйдегез мәллә?
Килдегез дә утырдыгыз
Тамыр җәйдегез мәллә?
Беләзегем-йөзегем
Киярмен әле үзем.
Сезгә ялынып тормыймын
Биермен әле үзем.
Бие әйдә, бие әйдә
Биегәнгә бер бәрән.
Әгәр бии белмим дисәң,
Кайтарам да җибәрәм.
Агыйделнең суы ага
Су астыннан ком ага.
Җырлыйбыз да, биибез дә
Күз тимәсен дип кара.

**Бала:** Әйдәгез, “Йөзек салыш” уенын уйныйбыз.

**Бала:** Әйдәгез, уйныйбыз!

*Балалар печән өемнәре өстенә утыралар, йөзек салышалар. Йөзек әбидә кала.Әбине тотып алалар.*

**Әби:** Ай рәхмәт төшкерләре, мин кузгалып өлгергәнче тотып та алдыгыз.

**Бала:** Әбекәйгә нинди җәза бирәбез.

**Бала:** Биетәбез.

**Әби:** Мин инде үзем генә биемим, бабайсы , әйдә, икәүләп бер картлыкта – бер яшьлектә, дигәндәй биеп алыйк әле.

**Бабай:** Әбиегез яшь чагында бик матур бии иде.

*Татарча бию көе яңгырый. Экранда күмәкләшеп бию күренеше.Әби белән бабай бииләр, балалар кул чабалар, бииләр.*

**Әби:** Хай рәхмәт яусын, балалар.Яшьлеккә кайткан кебек булдык.Без кайтыйк инде, кичке ашны әзерләр вакыт җитә.

**Бабай:** Эшләгәндә сусасагыз чишмә суын шушында куям.Армыйча эшләгез! Аллаһ куәт бирсен.

*Әби һәм бабай уфалла арбасы тартып чыгып китә. Экранда печән көлтәләре күренеше. Печән чапкандагы чалгы тавышы яңгырый. Балалар эшли башлый. Алгы рәттә малайлар чалгы белән печән чабалар, арткы рәттә кызлар урак белән печән уралар, печәнне көлтәлиләр*

**Малай:** *(куллары белән маңгаендагы тирләрен сөртә)* Малайлар, кызлар, әйдәгез бүгенгә җиттеп торыр. Печән өмәсе бик күңелле булды.

**Кыз:** Кояш та байый башлады.

**Малай:** Көтү кайтыр вакыт җитте. Иртәгә дәвам итәрбез!

*"Батыр егет печән чаба" көе яңгырый. Экранда кояш баю күренеше. Малайлар иңнәренә чалгылар, кызлар уракларын тотып җырлап кайтып китәләр.*



Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы
Алан балалар бакчасы мәктәпкәчә белем бирү
муниципаль бюджет учреждениесе тәрбиячесе

**Касимова Ләйсән Рәкыйф кызы**

**Орчык өмәсе**

***Тәрбияви максат:*** Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны борынгы, онытылып барган татар йолалары аша мөстәкыйль, иҗади, күпкырлы фикер йөртүче, актив итеп тәрбияләү; кеше тормышында һөнәрнең мөһим урын тотуына
ышандыру; кеше хезмәтенә, йолаларыбызга ихтирам, хезмәт сөючәнлек тәрбияләү.

***Белем бирү максаты:*** Йон тетәргә, йомгак чорнарга өйрәтү.

***Үстерелешле максат:*** “Орчык өмәсе” турында мәгълүмат бирү, әби – бабаларыбызның тормыш- көнкүреше турындагы күзаллауларын киңәйтү; яңа сүзләр хисабына балаларның тел байлыгын үстерү;

***Җиһазлау:*** кабалар (1 зур, һич югы 1-2 кечкенә, йомгаклар, йомгак салырга пластик савытлар, орчыклар, йон (язылмаган, кабага беркетергә, орчыкка эрләнгән йон), бәйләү энәләре, бәйли башлаган оекбаш, бияләйләр, катнашучылар санынча кульяулыклар, күз бәйләргә яулык, урындык, эскәмияләр, самавыр, чиккән сөлге, чәк-чәк (чын я муляж), уенчык ат башы, гармун)

(Катнашалар: малайлар, кызлар, 2 әби. Барысы да татар халкының милли киемнәреннән);

***Көтелгән нәтиҗә:*** Әниләрне, әбиләрне тәрбия эшчәнлегенә күбрәк тартылуы, үсеп килүче буында халкыбыз йолаларына карата кызыксыну уяну, буыннар чылбыры өзелмичә гореф-гадәтләрнең буыннан-буынга тапшырылуы.

**Чара барышы**

*Әбиләр чыга. Җырлыйлар яки фонограмма (“Шәл бәйләдем”)*

Шәл бәйләдем, шәл бәйләдем,
Шәл бәйләдем, шәл бәйләдем,
Шәлем түгәрәк түгел лә,
Шәлем түгәрәк түгел.
Әннә-гидер, геннә-гидер генәем лә,
Әннә-гидер, эннә-гидер генәем.

**1 Әби**: И-и-и күрше, син гомер буе шулай тигез итеп, гәрәбәдәй йон эрләдең, кулың ятып тора шул эшкә, син эрләгән җептән бәйләнгән оекбаш-бияләйләр дә матур, җылы һәм чыдам була.

**2 Әби**: И-и-и күршекәем, аның бөтен сере - синең картың ясаган орчыкларда. Үзләре шундый җайлы, кулга ятып торалар.

*Бер-берсенең эшләрен макташалар, кызларның җырлаган тавышы ишетелә*

**1 Әби:** Карачы күршекәем, урамда яшьләр тавышы ишетелә, өйгә якынлашалар түгелме?!

**2 Әби:** Килсеннәр, килсеннәр эшләгәннәре кеше өчен булса, өйрәнүләре үзләре өчен булыр.

**1 Әби:** Шулай, шулай.

*Кызлар керә*

**Камилә:** Хәерле кичләр! Өегезгә бәрәкәт иңсен. Бүген сездә “Орчык өмәсе” була дип ишетеп килдек. Без дә ярдәм итсәк ярыймы?

**Әбиләр:** (бергәләп) Әйдәгез, кызлар, әйдәгез, Түрдән узыгыз!

**Камилә:** (чиккән сөлгедә Чәк-чәк)

Өстәлләрнең яме булып
Балкып утыра чәк-чәк
Телләреңне йота күрмә
Авыз ит аннан чак-чак!
Рәхим итеп ал әле әбекәй.

**2 Әби:** Рәхмәт төшкере, күчтәнәчләр белән килгәннәр. Бар, алайса кызым, самавыр куй, эштән соң чәйләп алырбыз.

**1 кыз:** Була ул әбекәй (Самавыр куйгандай хәрәкәтләр ясый)

**2 кыз:** Әйдәгез, йортка дога кылыйк әле, кызлар.

*Ул арада ерактан гармун тавышы ишетелә, егетләрнең җырлаган тавышы өйгә якынлаша.*

**3 кыз:** Кызлаар, егетләр дә килә түгелме?.. Без бит кызларны гына чакырган идек.

**1 Әби:** Алай димә, кызым, мин бабаңа аларга да дәшергә куштым. Килүләре бик шәп булган, бабаң янында орчык ясарга өйрәнерләр.

**2 Әби:** Әйдәгез оланнар,түргә узыгыз, уз. Никадәр булышчы. Сөбханалла! Болай булгач, язылмаган бер йон да калмый инде.

**2 кыз:** Әбекәй, ә "Орчык өмәсе" нәрсә соң ул? Аны кайчан бәйрәм итәләр?

**1 Әби:** *(экранда фотолар-борынгы йорт, йолалар, бәйләгән әйберләр, җырлы-биюле уен күренешләре күрсәтелә бара)* Хәзер бит заманалар башка, кибетләрдән җаның ни тели шуны алырга була. Сез йонны кайдан алуларын да, ничек эшкәртүләрен дә белмисез шул. Яшьләрне гаепләп булмый. Заманасы шул. "Орчык өмәсе" – безгә әби - бабаларбыздан калган мирас ул, балалар. Ул кара көз җитеп, җиргә кар төшкәч уздырыла. Хуҗа кеше күп итеп йон әзерләп куя. Кичтән тәм - томнар көйли. Өмәгә күрше - күлән, дус - ишләр чакырыла. Бергәләп җыелгач, күмәк эш башлана: кемдер йон яза, кемдер эрли, кемдер йомгак чорный, кемдер бәйли. Эшне бүлешеп эшлиләр. Ә инде күңелсез булмасын өчен, болар барысы да уен - көлке, җыр – бию белән үрелеп бара. Эшләр тәмамлангач, хуҗа эшчеләрен тәмле ризыклар белән сыйлый.

Менә бүген бездә шундый бәйрәм инде. Өмәгә килгәч сез дә эшсез тормагыз. (эш бүлеп бирә: кызлар йомгак чорный, малайлар йон тетә, әбиләрнең берсе бәйли, берсе эрли, бер малай орчык тигезли)

**3 кыз:** Әйдәгез эшебезне җырлый-җырлый эшлик әле.

*Мәсәлән, "Утыр әле яннарыма" яки "Суда-суда"...)*

**1 Әби.** Күршекәем, без бит җырлашып кына утырмый идек, табышмаклар, әйтемнәр әйтешә идек.

**2 Әби.** Әйе шул. Үзем әйтим әле башлап.

Бүген мин җепләр каттым

Йомгаклар санын санагач

Үзем дә шаклар каттым.

**1 кыз:** (алга чыгып сөйлиләр) Мин дә беләм!

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү

Барысы бергә сигез

Эрләгән йомгакларның

Зурлыклары бертигез.

**1 малай:** Орчык яхшы әйләнсен дип

Салдык без табакларга

Мондый күмәк эшләрне

Гел кирәк кабатларга

*Һәр шигырь саен хуплап-җөпләп торалар*

**2 малай:** (буялмаган орчык тотып килә)

Агач юынам, орчык ясыйм

Зыр-зыр әйләнсен диеп

Кышка җылы бияләйләр

Тизрәк бәйләнсен диеп.

Әбекәй, әбекәй, карале. Булдымы?

**2 Әби:** Сөбханалла, булган бу улым! Кулларыңнан куан балам.

**2 малай:** Ягез алайса "орчык бөтерү" уены уйнап алыйк.

*Алга таба уеннар тиз-тиз берсен-берсе алмаштыра бара.*

*1."Орчык бөтерү"*

*Әкрен музыка. Орчыкны әйләндереп җибәрәләр, очы кемгә карый, шуңа җәза бирелә. Әбиләрнең берсе әйләндерә)*

**Барысы бергә:** ...нишләтәбез?

**Бергә:** Тизәйткеч әйтсен!

**Малай/кыз:** Мич башы (2)
Мич башында 5 мәче
5 мәченең 5 башына
Ишелмәсен мич ташы
**Бергә:** Булдырдың!
**3 малай:** Әйдәгез “Утыр-утыр Мәликә”не уйныйбыз
(“Әй кара каш кара күз” музыкасына кулларны тотынмый гына бер – бер артлы әйләнеп биеп йөриләр. Бер бала уртада урындыкта утыра, күзе бәйләнгән)
Утыр-утыр Мәликә
Алмагачның төбенә
Каршыңда кем басып тора
Әйтеп бирче тиз генә
Тиз генә бер кыз урындыктагы бала каршына баса.
**Бала:** (капшап карап) Кем икән бу? Камиләдер бу?
**Бергә:** Юк шул, белмәдең! Кызлар нишләтәбез?
-Шигырь сөйләсен!
**Бала:** Әти миңа ат бирде,
Иярлә дә чап диде
Матур-матур кызлар күрсәң
Өйгә алып кайт,-диде
(Көлешәләр)
**1 малай:** Яулык салышны да уйныйк инде.
(Ярымтүгәрәккә басалар, берәү чиккән кульяулыклар тарата)
**Бергә:** талы-талы талчыбык
Уртасында балчыбык
Ал яулык, гөл яулык
Бирче миңа бер яулык.
*Шуннан музыкага берәү яулыкларны кире җыя. Аннары уенчыларга арты белән иң алга килеп басып, карамый гына бер яулыкны тартып алып өскә күтәрә:*
-Кызлар, егетләр, бу кем яулыгы, - дип сорый

-...неке!

-Нишләтәбез?

-Җырлатабыз (биетәбез, шигырь сөйләтәбез...)

**Бергә:** Булдырдың!

**2 кыз:** Ярышып йоннар эрләдек

Бөтерелде орчыклар

Алып килгән йоннар бетте

Бушап калды капчыклар!

Инде дусларым таралышырга да вакыттыр.

**Бергә:** Әйе шул

**1 Әби:** Бик күңелле булды бу балалар, күпме эш тә эшләнде. Рәхмәт яусын барыгызга. Бүгенгә җитеп торыр.

**1 кыз:** Әйе, без дә күпме әйбер белдек.

**2 Әби:** Тагын шулай килегез бәбекәйләрем.

**Бергә:** Килербез, килербез әбекәйләр.

**3 кыз:** Сарыкларыгыз бәрәнләп торсын,  икенче елга да күп булсын.

**1 малай:** Бәйләгән әйберләрегез өстегездә тузсын!

**1 Әби:** Әйдәгез кайтып киткәнче табынга үтеп, чәйләп алыйк. Үз күчтәнәчеңнән авыз итсәң картаймассың ди...

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль  районы муниципаль  бюджет мәктәпкәчә белем  бирү учреждениясе “Мамадыш шәһәре 4 нче “Экият” балалар бакчасы тәрбиячеләре

**Каюмова Рузилә Минневакыйф кызы**

**Сагитова Рузия Мәүләви кызы**

## ***Базар ярминкә***

**Максат:** Татар халык иҗаты турында белемнәрне ныгыту, татар халык уеннары уйнау, балаларда физик һәм әхлак тәрбиясе күнекмәләре булдыру, дус,тату уйнауга ирешү.

**Диктор**: *Вакыт машинасы Алсу белән Данилны мең дә бер йөз еллар элекке заманнарга алып китте.Алар кеше күп җыелган җиргә таба юл тоттылар.Якынрак килгәч,аның зур базар икәене күрделәр.Бөтен җирдә халык,тавыш,ыгы-зыгы.Берәүләр сата,берәүләр ала.янында гына чүпрәк курчаклар,туплар, кием-салым, итек- читек һәм башкалар.*

Алсу Данилны җитәкләп, барысына да сокланып карап йөрде.Аннан Алсу башлады:

-Данил,кара әле никадәр күп уенчыклар монда.Их! Шуларны алып бер уйныйсы иде.

-Әйдә Алсу, иптәшләрне чакырыйк , бергәләшеп уйнарбыз

.Кинәт шау-шу купты,уен дигәндә балалар күп җыелды.Рәхәтләнеп базардагы булган

әйберләрне,уенчыклар белән таныштылар.

**Алсу**

Шундый зур безнең базар

Шундый бай безнең базар.

Базар бай,кесәсес ай-вай.

Дарым-шарым,тәңкә ярым

Күпмегә алсан, шуңа сатам.

Кирәкме, алмыйсызмы?

***Сатучы ( җырлый)***

И  ал бит ул, ал бит ул

Ай,тырдыр,там-там.

Мал базарда бар бит ул

Ай тырдыр там-там.

Базарга кил ,соңга калма

Ай тырдыр там-там.

Иртән иртүк килеп җит

Ай тырдыр там-там.

**Данил:** Кызлар,карагыз әле ,нинди матур челтәрле шәл әйдәгез сатучы ападан сорыйк әле...Апакаем безгә челтәрле шәл бирегез әле?

**Сатучы апа:** "Кунак ашы –кара каршы " ди татар халык .Ә сез миңа бәяне ни белән кайтарасыз?

**Балалар:** Ә без сезгә "Чума үрдәк,чума каз" җырлы-биюле уенын уйнарбыз.

"**Чума үрдәк ,чума каз" җырлы-җиюле уены уйнала.**

***Сатучы апа***

И балалар бик күңелле булып китте әле,менә сезгә четәрле шәл .

**Азалия**

-Апакаем, кулъяулыкларың бик матур икән?

**Сатучы апа**

-Зиһен сынаш уеннын уйныйк,дөрес җавап бирсәгез кулъяулыклар  сезгә. Бу уен"Төенчек" уены дип атала. Мәкальнең яртысы минем телемдә, ә икенче яртысы  - шушы төендә. Мин мәкальнең беренче яртысын әйтәм дә, бу төенне кайсыгызга булса да ыргытам, әйтә алган кеше мәкаль төенен чишкән була.

**Мәкальләр**

-Сәламәт тәндә- сәламәт акыл.

-Чисталык -сәламәтлек билгесе.

-Җыр- кешенең юлдашы.

-Әти шикәр- әни бал.

-Кем  эшләми  шул ашамый.

-Аюдан курыксан урманга барма

-Бүредән курыксан сарык асрама.

***Сатучы апа***

Алай тапкыр булгач,минем сүзләргә дә җавап бирегез инде.

Прәннек-авызыңа керәм бит.

Сөт-танавыңны сөрт.

Читән-бер  чеметәм дә китәм.Шуннан?-Утырганда шуган.

Шуннан?-Кишер белән суган.

Шуннан?-Койрыгы туңган.

Шуннан?-Сыерлары ат булган.

Шуннан?-Тирән күлгә чумган.

Уч төбендә бензин,керосин исе,иснәп кара әле. (Иснәгәндә борыннарын кыса).

Булды, мин дә хәйләләдем сезнен. (Көләләр)

**3. Азалия**

-Апа курчакларыгыз бигрәк матур, минем дә уйныйсым килә.

**Сатучы апа**.

Курчак турында шигырь сөйләсәң курчак синеке.

**Курчагым.**

Менә минем курчагым

Ике күзе бар анын

Ә менә бу- борыны

Бу – билгеле муены

Колакларын күрсәтим

Чәчен сыйпап иркәлим

Бигрәк матур битләре

Авызында тешләре

Ә менә болар куллар

Чәбәк-чәбәк уйныйлар

Кечкенә аяклары

Бик матур тыпырдыйлар

Тытыр- тыпыр,тыпыр- тыпыр

**Сатучы апа:**Безнен Азалиябез ничек матур итеп шигырь сөйләде.Курчагыңның исеме ничек соң кызым?

**-Гөлбану**

Эх,яшь чакларым искә төшеп китте әле,без дә яшь вакытта чишмәгә суга бара идек,кич белән кичке уенда "Гөлбану" уенын ,йөзек салыш уйный идек.Әйдәгез, йөзегемне алыгыз, ә бәясе " Йөзек салыш "уены

(Кирилл санамыш санап йөзек салучыны билгели, йөзек ала,йөзек салыш уены уйнала)

Каенда карга

Имәндә чыпчык

Җирдә елан

Һавада кош

Бар синдә оч

**Сатучы апа:** Кирилл ничек матур итеп санамыш әйтте.

Йөзек кемдә була,шул "Күз" жырын башкара.

**Сатучы апа**

Гөлбану уенын да уйнап китик инде

**"Гөлбану" уены**

Балалар түгәрәкләнеп, кулга-кул тотынып басалар. Уртада бер бала калдырыла. Түгәрәктәгеләр бер якка хәрәкәт итеп җырлыйлар:

Син уртада, без кырыйда

Әйләнәбез, Гөлбану.

Син нишләсәң, ни кылансаң.

Шуны эшләргә могу.

Җыр туктагач, уртадагы бала берәр хәрәкәт ясый, түгәрәктәгеләр шуны кабатлый. Әгәр бу хәрәкәтне дөрес ясамаучылар булса, аның берәр әйберен алалар.

Такмак әйтәләр (бию хәрәкәте күрсәтә,балалр бииләр)

***Розалина:*** Җитәр җитәр уздырдың

Бигрәк тузан туздырдын

Аягыңны шакылдатып

Колагымны тондырдын

***Зөлфәт***

Әбиемнен кәҗәсе,

Бакчада кәбестәдә.

Биемәгәч тә, җырламагач,

Без монда нәмәстәгә

**Сатучы апа**

Такмакларыгыз кызык булды.

Балалар,бүгенге базардан сез нәрсә алдыгыз,күрсәтегез әле. (*балалар күрсәтә)*Әйдәгез,уеныбызны җыр белән тәмамлыйк. *(балалар түгәрәккә басалар,әйләнеп җырлыйлар)*

**Камилә**. Әйдә, дуслар, җырлыйк әле

Уйнаган гармуннарда.

Ал чәчәк күк яшик әле

Туган якларыбызда..

Базарга бардык без

Күп нәрсә алдык без,

Җырладык та,биедек тә,

Күңелебезне ачтык без.

Алай итәргә кирәк,

Болай итәргә кирәк,

Кунакларга урын биреп,

Кайтып китәргә кирәк.



Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы

Мүлмә гомуми урта белем мәктәбе" гомуми белем

учреждениесе тәрбиячесе

**Шәмсиева Лилия Гаптелфәт кызы**

***"Исемең матур кемнәр куйган?"***

***Кыз бала исеме***
***йолдыз балкышына охшасын,***
***назлы гөлчәчәктәй нәфис булсын.***
***Ир-ат исеме кылычлар чыңлавын хәтерләтсен,***
***аның мәгънәсендә гакыл***
***гәүдәләнсен.***
***Рәсүл Гамзатов.***

**Максатлар:**

- Сәнгәть әсәрләренең төп кыйммәтен, әһәмиятен һәм мәгънәсен аңлауга, кабул итүгә алшартлар булдыру:
- Балада үз халкының гореф – гадәтләрен, йолаларын һәм мәдәниятенә карата уңай хисләр, мөнәсәбәтләр формалаштыру.

**Бурычлар:**

- Балаларны исем кушу йоласы белән таныштыру.
- Балада татар халкының гореф- гәдәтләренә кызыксыну уяту.
- Милләт тойгысы һәм милли горурлык хисе тәрбияләү.
- Буыннар бәйләнеше, исемнәр, аларның килеп чыгышы, мәгънәсе турында күзаллауларын тирәнәйтү;
- Гаиләң белән горурлану хисләре, өлкәннәргә ихтирам, хөрмәт тәрбияләү;

*Сәхнә авыл өе күренеше итеп, милли татар чигүләре белән бизәлгән.*

*Уртада өстәл, уң якта бала бишеге эленеп тора. Йортта зур бәйрәмгә әзерлек бара. Талгын гына көй яңгырый. Кушымта өлеше җырланганда ана бишек янына чыгып утыра. Арттан алып баручы сөйли:*

**А.Б.** Яхшы исем кыйммәт барыннан да,

Аннан туры дусны күрмисең;

Безнең хакта мәңге ядкарь саклап

Картаймыйча яши һәр исем!

Җиргә кеше туа, ул әлегә бик көчсез, иң аянычы – ул үзе теләгән исемне дә сорап ала алмый. Бу бик җаваплы, мөһим эшне баланың әти-әнисе үз өстенә ала. Сабыйга исем кушалар, ә исем бит ул гомерлеккә!

- Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар,балалар! Без бүген сезнең игътибарыгызга бәбигә исем кушу йоласын сәхнәләштереп күрсәтербез.

- Бала туды. Дөньяга яңа кеше килде. Аңа кушу өчен исем кирәк. Матур исем, мәгънәле исем, зәвыклы исем – кыскасы әйбәт исем. Татар халкының дистәләрдән артык гасырларны эченә алган тоташ буыннар чылбарыннан гыйбарәт милли исемнәр тезмәсен алга таба дәвам итәрлек исем, халык рухын саклый торган милли исем кирәк.

*(Җыр тәмамлангач өйгә яшь ананың каенанасы, абыйсы белән килендәше керә.)*

**1 КЫЗ (КИЛЕНДӘШ):** Исәнме, килендәшем. Исән-сау кайттыгызмы?

**КАЕНАНА**: Күрим әле оныгымны,

Карап туймаслык бала.

Улым, килен котлыйм Сезне

Күз тимәсен Сөбеханалла.

**АНА :** Әйдәгез, кадерле кунаклар, рэхим итегез, түрдэн узыгыз.

**ӘТИСЕ:** Бүген households бәйрәм булыр

Исем кушарбыз уйлап.

Яхшы исем, матур исем

Мәгънәсе булыр чынлап.

***(Кунаклар керә, кунаклар арасындагы бер малай исәнләшә)***

**КУНАК 1** : Әссәләмәгәләйкүүүүүм!

Исәнмесез –саумысез

Бәби күрергә килдек без,

Нигә каршы алмыйсыз?

**КУНАК 2:** Күчтәнәчләр алып килдек,

Барыгызга күп итеп.

Баллысын да, татлысын да

Озын юлларны үтеп. **(Анага күчтәнәч тапшыра)**

**КУНАК 3:** Күз тимәскә миләш тегеп,

Күлмәк бүләк итәрбез.

Сау –сәламәт бала булып,

Үскәнен дә күтәрбез.

**(Анага күчтәнәч тапшыра)**

**КУНАК 4** : Күчтәнәчне е е е е е е җәлләмәдек,

Алып килдек мул итеп.

Бәбине күрсәтсеннәр дип,

Аналарына – чите е е е к.

**(Анага күчтәнәч тапшыра)**

**МАЛАЙ (АБЫЙСЫ):** Энекешкә исем кушабыз бүген. Ләкин әлегә исем сайламадык, бик матур исем кирәк булыр инде безнең энекәшкә.

**(балалар түгәрәкләп басалар)**

**ӘТИСЕ БАЛАНЫҢ:** (санамыш әйтә)

Карга, чыпчык,

Син кал да,

Ә син чык!

***Уртага бер баланы чыгара, бала уйланып тора да:***Айсылу!

**Балалар**: Кит әле, безнең бәби бит малай!

**ӘТИСЕ: тагын саный:**

Карга, чыпчык,

Син кал да,

Ә син чык!

**2нче бала:** Мин таптым, мин таптым. АЛМАЗ булсын!

**Бергәләшеп**: Булсын, булсын, бик күркәм,

Туры килсен үзенә.

Бай күңелле малай булып,

Үссен безнең кечкенә!

**КИЛЕНДӘШ:** Мулла абзый килгәнче,

Бала уянып җиткәнче

Кызык итик тик тормыйк,

Җырлы уеннар уйныйк.

*(Балалар, кулга-кул тотынышып,парлап түгәрәк ясыйлар.)*

***"Капкалы" уены***

**АБЫЙСЫ:** Исем таптык бик матурны

Уянды балабыз да.

Мулла абзый да килә әнә

Төренеп чыпанына.

***(Балалар тезелеп утыралар)***

**МУЛЛА:** ***(исәнләшә)***

Әссәләмәгәләйкүм!

Хәерле көн сезләргә.

Исем кушу йоласын

Башлап җибәрик, әйдә.

**ӘТИСЕ:** әйдә, рәхим итегез.

***(Хәзрәт балага исем куша.)***

**Ана**:Куштык сиңа сайлап матур исем

Җисемеңә туры килсен ул,

Милләтеңнең бер мирасы итеп,

Әткәң – әнкәң биргән исем ул.

***<u>(Балага бишек җыры җырлана) кунаклар бәхет телиләр</u>***

Әлли-бәлли итәр бу,

Мәдрәсәгә китәр бу,

Тырышып сабак укыгач,

Галим булып җитәр бу.

Йокла, улым , йом күзең,

Йом, йом күзең, йолдызым,

Кичтән йокың кала да,

Еглап үтә көндезең.

**А.Б (әкрен генэ сөйли )**

Үз милләте көен ишетеп үссә

Халык хәтерен саклар буыннар.

Тарихлардан килгән гореф-гадәт,

Туган  телен көйли бу җырлар.

**АНА:** Ә хәзер барыгызны да, кунаклар, аш бүлмәсенә бәби ашына чакырам. Әйдәгез, рәхим итегез.

**А.Б.**  Саклыйк буыннарга рухи хәзинәне,

Бишек җыры-күңел көзгесе.

Киләчәктә шәхес булыр өчен

Тәүге адым,яшәү өлгесе.

... Бала язмышы әти – әни кулында. Һәр бала үз милләтенең вәкиле булып үсә. Бездә дә күбрәк дини тәрбиягә өстенлек бирелә башлады. Бу балага дини эчтәлекле гарәп исемнәре кушуда чагыла. Үзебезнең милли исемнәребез юкка чыкмасыннар . Аларны кире кайтарабыз, гарәп теленнән дә матур мәгьнәле исемнәр сайлыйбыз. Шунда гына -Тәрбиябез милли дә, дини дә була.

Татар шагыйрьләре һәм язучыларыбыз мәкаләләрдә, шигырьләрендә, милли мәгарифнең, татар халкының әдәбиятыбызда, мәдәниятебездә, тәнкыйт-тәрбиябезнең сыйфаты мәсьәләләрен күтәрәләр, бөтен җаннары – тәннәре белән татар милләтен саклап калу өчен тырышалар.

Вакыт бара,чаба....Яңадан-яңа буыннар җиргә килә тора.Буыннарны онытмыйк,һәрчак истә тотык.Узебезнен фольклор кичәсен шундый сүзләр белән тәмамлыйсым килә:”Исем –ул синең тормышың,юлыңнан күтәреп барган үз байрагың”. Бу сүзләрне беркайчан да онытмагыз! Үз исемегезне горур йөртегез, аңа тап төшермәгез!



Татарстан Республикасы Биектау муниципал районы Хәй Вахит исемендәге “Мәмдәл гомуми урта белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе”

Рәхимова Гөлинә Рәис кызы

***Хуш киләсең , Нәүрүз!***

**Максат:**Балаларны татар халкының милли бәйрәмнәре һәм культуралары белән таныштыру. Балаларда бәйрәмгә карата уңай тәэсирләр калдыру. Татар халкының милли уеннары һәм бию элементлары белән таныштыру.

Залда милли көй яңгырый.Сәхнә яшел агачлар ,чәчәкләр белән матур итеп бизәлгән.Арткы планга “Әй син,Нәүрүз чибәре,язлар белән кил әле!”дигән язу эленгән.

**Алып баручы:**Төрки бабаларыбызның онытыла барган изге бәйрәмнәре ,аларның гореф-гадәтләре,ниһаять ,безнең көннәргә әйләнеп кайта башлады.Көннең төнне куып җиткән вакытында ерак бабаларыбыз Язны Нәүрүзбикәне каршылаганнар.Кешеләр матур теләкләрен аңа әйтеп калырга тырышканнар.Өйдән өйгә кереп ,теләк теләп ,сый-нигъмәт җыеп йөргәннәр.Хөрмәтле кунаклар ,балалар без дә бүген Язны-Нәүрүзбикәне каршы алырга җыелдык.Ә ул безгә килеп җиткәнче, җырлап-уйнап алыйк.

**“Яз җитә “җыры башкарыла.**

**1 бала.**Хуш киләсең,гүзәл Нәүрүз!
Язгы яңа елыбыз.
Яңа елда туры булсын,
Нурлы булсын юлыбыз!
Еракларга яңгырасын
Бүген дәртле җырыбыз.

**2 бала**.Елгада бозлар кузгалды
Елмая ,көлә кояш.
Урамнар буйлап атлый,
Ямьле һәм күңелле яз.

**3 бала.**Кояшлы көннәре белән
Ямьле яз килеп җитте.
Бу җырны безгә бәйрәмгә
Ямьле яз бүләк итте.
**4бала.**Әй яз-матур,яз матур
Хуш киләсең ,уз бире.
Кунак булып килер дип
Күптән көттек без сине.
**5 бала**.Әй дускайлар,дускайлар
Җитте бит Нәүрүз айлар.
Эшегезне ташлагыз,
Бәйрәмгә ашыгыгыз!
**“Нәүрүз килә” җыры башкарыла.**
**Уен “йөзек салыш”**
(Башына сары такыя кигән ,яшел күлмәктән Нэүрүз һәм чәчәк тотып бала керә.)
**Нәүрүз:**Агымсулар кичтем мин ,
Сезгә килдем мин.
Нәүрүз әйтеп үттем мин,
Нәүрүз мөбарәк булсын!
**Бала.** Нәүрүз безгә үзе килгән
Чәчәкләр алып килгән.
Нинди чәчәкләр дисәгез?
Умырзаялар белән!
**Умырзаялар (кызлар)биюе башкарыла.**
(Серле буран тавышлы көй яңгырый,кыш бабай керә)
**Кыш бабай**:Исәнмесез балалар!!!Мине сагынып көттегезме?(як-ягына каранып).Ә сезнең чыршыгыз кая соң?Әллә чыршы бизәргә оныттыгызмы?
**Алып баручы:**Бабакай нинди чыршы турында сөйлисең син?Яңа ел күптән үтте бит инде.Ә без бүген Нәүрүз бәйрәменә җыелдык.Менә Нәүрүзбикәбез үзе дә безнең белән.

**Нәүрүз:**Мин дусларым сезне сагынып килдем,

Теләкләрем ихлас күңелдән.

Юлыгызга якты бәхет юрап,

Яз гөлләре булып сибелгән.

Яр буенда әнә ут чәчәкләр-

Учлап кояш сипкән шикелле.

Алар минем сезне сагынуымнан

Шытып чыккан гөлләр бит инде.

**Кыш бабай**:Ничек инде,сез язны каршы алырга җыелдыгыз?!Әнә бит карагыз бөтен дөнья әле ап-актан!

**Алып баручы:**Бабакай,без синең ап-ак карларыңны ,салкын кышларыңны бик яраттык.Әммә ләкин син арыгансыңдыр,сиңа ял итәргә вакыт җитте.Синең урыныңа ямьле ,матур яз килер.

**Кыш бабай:**Ничек алай?Туктагыз әле,туктагыз!Мин бит әле китмәгән,китәргә дә җыенмыйм.Көч сынашмыйча ,тартышмыйча Язга –Нәүрүзбикәгә  урын бирү юк.

**Нәүрүз:**Бөтен шартларыңа да күнәм.

**Кыш бабай:**Беренче шартым тыңла:

Менә кашык,менә күкәй,

Тот кулыңа чибәркәй.

Син дә йөгер,мин дә калмам.!(узышылар)

Икенче шартым:

Икебезгә бер урындык,

Әйләнәбез тирәли.

Кем беренче утырачак

Шул җиңүче әлләли!

**Алып баручы**:балалар Нәүрүзбикәгә көч биреп торабызмы?

(балалар җаваплары)

**Уен барышы бию көе яңгырый.**

**Кыш бабай:**Өченче шартым Нәүрүзбикә тыңла.

Бие,бие чибәркәй ,

Мине узалмассың син.

Син яшь ,мин карт булсам да,

Биюдә  калышмам мин.

(Кыш бабай белән Нәүрүз бииләр.Кыш бабай хәлдән таеп егыла)

**Кыш бабай:**Уф арыдым,сусадым

Харап булдым ,җиңелдем.

Эредем бит ,эредем

Яз алдында хур булдым.

**Алып баручы:**Әйдәгез балалар ,Кыш бабайга булышыйк.Барыбыз бергә өрик әле,җилләндерик үзен.(өрәләр,җилләндерәләр)

**Кыш бабай:**Кызым,Нәүрүз,бик булдыклы,зирәк,акыллы,уңган икәнсең.Инде мин тыныч күңел белән сиңа үземнең тәхетемне калдырам.Ә мин көч җыеп ,икенче елга сезгә кабаттан әйләнеп килермен.Имин яшәгез ,бәхетле булыгыз бабалар!!!Сау булыгыз!

(Барысы бергә :Сау бул Кыш бабай)

**Алып баручы:**Салкын кышны яз җиңде,

Моны барчагыз күрде.

Кулга кул тотынышып

Без бәйрәм итик инде!

**Җыр.**

**Нәүрүз:**Кадерле балалар,кунаклар!Минем сезгә бер үтенечем бар:"Табигатьне саклагыз,елгаларның суы саекмасын,урманнардан киек кошлар китмәсен,зәңгәр күгебезне болыт капламасын, ә үләннәр гел яшел булсыннар.

**Җырлы-биюле уен.**

**Нәүрүз** :Җырладык та,биек тә,уеннар да уйнадык.Инде мине башка балалар бакчасында көтә торганнардыр.

Язлар ,җәйләр имин килсен,

Кук йөзе аяз булсын.

Барчабызга сәламәтлек,

Бәхетләр алып килсен!Сау булыгыз!!!

**Алып баручы:**

Нәүрүз котлы булсын!

Тормыш түгәрәк булсын,

Мал –туарыбыз артсын,

Игеннәребез уңсын,

Күкәй кебек тук булсын,

Нәүрүз котлы булсын!

Елларыбыз тыныч торсын,

Күкләребез аяз булсын,

Изге догаларыбыздан аермасын,

Мәңге шат яшик дуслар!!!

Барыбызга да яңа бәхетле тормыш алып килә торган Яз булсын!Хушыгыз ,сау саләмәт булыгыз.

(муз астында чыгалар)



Татарстан Респуликасы Биектау районының мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе “Чыршы“Салават купере” балалар бакчасы тәрбиячесе

**Галиуллина Алсу Мөнир кызы**

***Бездә бүген Нардуган***

**Максат:** Балаларны татар халкының милли бәйрәме «Нардуган» белән таныштыру.

**Бурычлары:**

1. Балаларга татар халкының тормышы, көнкүреше,бәйрәмнәре һәм гореф-гадәтләре турында мәгълүматләр бирү.

2. Балаларның бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү, үз фикерләрен тулы итеп әйттерүгә ирешү, милли бәйрәмнәргә, гореф-гадәтләргә карата кызыксынучанлыгын арттыру.

3. Балаларга рухи-әхлакый тәрбия нигезләре бирү һәм татар халкының милли бәйрәмнәренә, гореф-гадәтләренә карата соклану хисе тәрбияләү.

**Залның бизәлеше:** Авыл урамы, авыл өе күренеше, учак макеты.

**Балалар белән алдан эшләнгән эш:** Балалар белән халык авыз иҗаты әсәрләрен, татар халык җырларын, уеннарын, биюләрен өйрәнү. Балаларга милли бәйрәмнәр турында сөйләү.

**Катнашалар:** Алып баручы, әби, бабай, Нардуган ана, Нардуган ата.

**Алып баручы:**

Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар! Татар халкында милли бәйрәмнәр күп. Аларның кайберләре телдән-телгә күчеп безнең көннәргә кадәр килеп җиткән, кайберләре, кызганычка каршы, бөтенләй онытылып юкка чыккан. Ә бит борынгы әби -бабаларыбызның рухи хәзинәсе булган милли бәйрәмнәребезнең балалар тәрбияләүдә әһәмияте чиксез зур. Шуны истә тотып, бүген сезнең игътибарыгызга «Нардуган»бәйрәмен тәкъдим итәргә булдык. Нардуган – ул кышкы бәйрәм. Татар халкы яши торган кайбер төбәкләрдә борынгы заманнарда ук Яңа ел көннәрен Нардуган вакыты дип йөрткәннәр. Гадәттә, ул 22 нче декабрь – кышкы торгынлык көне. Бу – елда иң кыска көн. Кышкы кояш торгынлыгын борынгы халыклар кояшның “үлеп кабат терелүе” яки “яңадан тууы” рәвешендә күзаллаганнар һәм аны ел саен бик зурлап тантаналы төстә билгеләп үткәннәр. Мондый календарь бәйрәм татарларда “Нардуган” дип йөртелгән. Аның атамасы монголча “нар” (кояш) һәм татарча “туу” сүзләреннән ясалган дип аңлату бар. Димәк, нардуган, “кояш туган” дигән сүз була. Нардуган бәйрәме декабрь ахырыннан – гыйнвар башына кадәр дәвам иткән. Кешеләр төрле киемнәр, битлекләр кигәннәр. Алар бәйрәм белән котлаганнар, изге теләкләр теләгәннәр. Яшьләр Нардуган уеннары уйнаганнар. Бакчабыз балалары катнашында “Нардуган” бәйрәменә рәхим итегез!

*(Авыл урамындагы капка күренеше, балалар капканы ачып керәләр, (мәктәпкә әзерлек төркеменнән ике егет, ике кыз )* **“Шома бас” көенә “Сәләмләү биюе”***н биешәр, калганнар кул чабып торалар. Бию беткәч йорт ишеген шакыйлар).*

**Айзат:** Әби-бабай, өйдәме сез? Саумысыз?

**Әби:** *(Ишекне ачып)*Сау, балакайларым. Керегез, түрдән узыгыз.

*( Сәхнәдә авыл өе эче сурәтләнгән макет, әзерләнгән табын. Балалар керәләр, битлекләрен киеп, шигырьләрен сөйлиләр).*

**Айсинә**

Нардуганыгыз нар булсын,
Эче тулы нур булсын.
Нардуган җырын кем җырласа,
Шул бик бәхетле булсын.

**Гөлназ**

Нардуганым нарына,
Бакма кеше ярына.
Кеше яры яр булмас,
Үз ярыңа тиң булмас.

**Мәликә**

Нардуганым нар булсын,
Эче – тышы нур булсын.
Нардуган башы кемгә тияр,
Ул бик бәхетле булсын.

**Бабай:** Һай, рәхмәт, балалар. Теләгән теләкләрегез мең кат үзегезгә кайтсын. Исән-имин йөрегез, балакайлар. Нардуганыбыз котлы булсын!

*(Балалар рәхмәт әйтеп, чыгып китәләр.Әби белән бабай балаларны озаталар. Өйнең эчке күренеше алына, авыл урамы күренеше: берничә йорт. Салмак кына сихри көй уйный, Нардуган Ана белән Нардуган ата керә).*

**Нардуган Ана***:* Исәнмесез, балалар.(*Балалар исәнләшәләр).* -Балалар, ә сез кышны яратасызмы?

**Балалар :** -Әйе.

**Нардуган ата**: -Әйе, йомшак ап-ак карлы кышны кем генә яратмый икән? Әйдәгез әле  кыш турындагы шигырьләрегезне сөйләп күрсәтегез әле.

**1.** "**Ак кыш**"(Роберт Миңнуллин, "Балачак аланы" 497 бит).

**Ясминә**

Яратам мин ап-ак төсне.
Бөтен дөнья ап- ак төсле:
Куяннар да ак тун кигән,
Каеннар да ак туннан.
Бүреккә дә,керфеккә дә,
Борынга да ак кар кунган.

**Айзилә**

Биек булып, ап-ак булып,
Урамга ак кар яуган.
Көне буе шау-гөр килеп
Шуабыз шул ак таудан.
Шундый якты,шундый нурлы-
Ап-ак була белә шулай
Безнең туган як кына.

**2.Айназ  "Буран"(**Гомәр Толымбай, "Балачак аланы" 122 бит).

Урамда буран,
Мин өйдә торам.
Тәрәзә аша
Тик авыз ерам.
Әй, җил выжылдый,
Буран дуылдый.

Ачулы песи
Кебек мырылдый.
Җиңдем, ди, бугай,
Дуланып шулай.
Әй бичаракай,
Кыланма болай.

**3.Гөлназ  "Салкын, саф һава"**(Әминә Бикчәнтәева, "Балачак аланы" 80 бит).

Салкын,саф һава,
Йомшак кар ява.
Урамга чыксан,
Битләр кызара.

Кар бөртекләре
Өстеңә куна,
Үзләре матур
Һәм салкын була.

**Нардуган Ана**: - Рәхмәт балалар. Балалар, бәйрәм булгач, нигә безгә борынгыдан калган  татар халык уеннарын искә төшермәскә? Әйдәгез әле, кечкенәләрне бирегә чакырыйк, нинди уеннар белгәннәрен карап үтик.

**Нардуган**

*Бер бала уртага чыга. Башка балалар аның тирәсендә бер түгәрәк ясап, кулга-кул тотынышып, нардуган җырын җырлап әйләнәләр:*

Син уртада, без кырыйда,

Әйләнәбез, нардуган,

Син нишләсең, ни кылансаң,

Мин дә шуны булдырам!

*Җыр беткәндә, уртадагы бала нинди дә булса бер хәрәкәт ясый, түгәрәктәге балалар шул хәрәкәтне кабатларга тиешләр. Кем шуны булдыра алмый, уртадагы бала үз урынына аны чыгара да, уен баштагыча дәвам итә.*

**Нардуган ата: “Түбәтәй” уенын уйныйк**

*Балалр түгәрәкләнеп басалар. Түбәндәге җырны җырлый-җырлый,түбәтәйне бар-берсенә бирәләр:*

Түбәтәеңне кигәнсең,

Бик ераклардан килгәнсең,

Төскә матурлыгың белән

Шаккатырыйм, дигәнсең.

Кушымта:

Түп – түп-түбәтәй,

Түбәтәең укалы.

Чиккән матур түбәтәең

Менә кемдә тукталды.

*Җыр ахырында түбәтәй кемдә калса, шуңа җәза бирелә (бии, җырлый, әтәч булып кычкыра һ. б.). Уен шулай дәвам итә.*

**Нардуган ана:  “Чума үрдәк, чума каз”уенын да уйнап алыйк.**

*Уйнаучылар кара-каршы ике рәт булып тезеләләр, парлашып кулга — кул тотыналар. Рәт башында  бер ялгыз уенчы басып тора. Балалар барысы бергә җырлыйлар:*

Чума үрдәк, чума каз,

Тирән күлне ярата ул, ярата.

(бала исеме) үзенә иптәш эзли,

Белмим, кемне ярата шул, ярата.

(бала исеме) ярата шул, ярата.

*Уйнаучылар, җыр ритмына туры китереп, хәрәкәтләнеп торалар. Ялгыз бала, рәт арасыннан узып, үзенә бер иптәш сайлый һәм аны җитәкләп ахырга барып баса. Үз парыннан аерылган уйнаучы рәт башына китә. Уен шулай дәвам итә.*

*(Сәхнә утрасына учак макеты куела).*

*Барлык төркем балалары белән учак тирәли җырлы – биюле уен* ***«Төймә»***

*Балалар, түбәндәге сүзләрне җырлап, түгәрәктә йөриләр һәм, туктап, кушымтасында бииләр.*

Яңгыр ява сибәләп,
Төймә-төймә төймәләп.
Кушымта:
Их, төймә, төймә, төймә,
Төймә була егерме.
Бергә җырлыйк, бергә уйныйк,
Бергә яшәү күңелле.
Җепкә тезгән төймә кебек,
Без дә яшик бергәләп.

**Алып баручы:** Ә хәзер, балалар, әйдәгез әле парлашып учак аша сикерик, күңел ачыйк! (*Флюра Хөрмәтованың – "Татар халык бию"е музыкасы куела).*

*(Балалар парлашып учак (макет) аша сикерәләр).*

**Нардуган ата:** И балакайлар, шундый күңелле булды бәйрәмегез. Рәхмәтләребез сезгә мең кат сәламәтлек, бәхет булып әйләнеп кайтсыннар.

**Нардуган ана**: Иң элек үзегезнең кем икәнегезне онытмагыз, әби-балаларны, әти-әниләрегезне, өлкәннәрне хөрмәт итегез. Милләтегезне хурламагыз, телегезне онытмагыз! Табигатебезгә карата мәрхәмәтле булыгыз!

**Алып баручы**: Рәхмәт сезгә ,кунаклар. (*Балалар белән бергә)* Сау булыгыз.

МБМББУ “ТР Биектау районы Ташлы Кавал
“Кояшкай” балалар бакчасы”
Iнче квалификацион категорияле тәрбияче
**Гыйлаҗиева Эльза Габделхак кызы**

***«Авылларда каз өмәсе гөрли»***

**Максат:** Балаларның татар халык йолалары, элекке гореф-гадәтләре, уеннары,аларның үзенчәлекләре, кагыйдәләре белән якыннан таныштыру һәм бәйрәмнәре турында белемнәрен арттыру.

**Бурычлар:**

**1.Белем бирү (укыту) бурычлары:**

-балаларны татар халык милли бәйрәмнәренең берсе – “Каз өмәсе” бәйрәме белән таныштыру;

-сүз байлыгын тулыландыру һәм активлаштыру;

-бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

**2.Үсеш бурычлары:**

-музыкаль-театральләштерелгән чара аша балаларда татар телендә ирекле аралашу күнекмәләрен үстерергә ярдәм итү;

-балаларның иҗади активлыгын үстерү.

**3.Тәрбия бурычлары:**

-балаларда патриотлык һәм Ватанга мәхәббәт хисләре тәрбияләү;

- балаларда татар халкының мәдәни мирасын саклап калу һәм арттыру омтылышлары формалаштыру;

-балаларда милли тәҗрибәгә шәхси мөнәсәбәтләре нигезендә карашларын формалаштыру.

**Бәйрәм үткәрү урынын җиһазлау:**

-авыл өе күренеше: өстәл (өстәлгә чигүле ашъяулык ябылган; өстәл өстенә милли ризыклар куелган);

-агач озын урындыклар;

-карават (борынгыча җыелып куелган, мендәрләр өстендә япмалар);

-мич (мичтә чуен);
- комган;
- каз түшкәләре (ясалма);
-табаклар;
-зур казан;
-бизәкле чиләкләр һәм көянтәләр;
-гармун;
- парлы каз канатлары (чын);
- май канаты (каз каурыеннан);
-чигүле сөлгеләр;
-зәңгәр җәймә (күл өчен)

**Катнашучылар:**

-кызлар һәм малайлар милли киемнәрдән;
-әби, бабай милли киемнәрдән (әти-әниләр арасыннан сайлана);
-алып баручы (тәрбияче) милли киемнән.

**Әзерлек эше:**

-балалар белән "Каз өмәсе" бәйрәме турында әңгәмә уздыру;
-каз өмәсе турында рәсемнәр һәм видеолар карау;
-шигырьләр, җырлар, биюләр, сценарий сүзләрен өйрәнү.
-әти-әниләр белән өйне җиһазлау һәм милли ризыклар әзерләү.

**Бәйрәм барышы:**

(Әкрен генә татар халык җыры «Каз канаты»ның көе яңгырый. Кызлар керәләр дә озын урындыкларга төзелешеп утыралар. Тәрбияче (алып баручы) чыга һәм шигырь укый)

**Алып баручы (тәрбияче):**

Көзге байлык!
Көзге муллык!
Авылда каз өмәсе!
Яше-карты, бала-чага –
Шау-гөр килә һәммәсе! (Кереп китә)

**Әби:** (үз-үзенә сөйләнеп керә) И-и-и, ничек күңелле! Авылыбызда каз өмәләре гөрләп тора. Минем дә казларым бик-бик күп булды. Өмәгә кызлар чакырдым әле. Безнең авыл кызлары бик уңганнар. Килеп җитсәләр, җин сызганып,эшкә тотынырбыз,боерган булса.

**Кызлар:** (бергә) Исәнме, Сания әби-и! Без килдек!

**Сания әби:** (куркып китә) Чү!И-и-и, рәхмәт яугыры! Килеп тә җиттегезмени, кызла-а-ар?!

**Беренче кыз:** Шундый матур иртәдә йоклап ятып булмый инде, әбекәй! Син үзең дә, әнә ,барысын әзерләп куйгансың. Казан астына да яктыңмы?

**Сания әби:** Әйе шул, кызлар, суым хәзер кайнап чыга. Исмәгыйль бабагыз казларны алып кергәнче, балакайларым, мин сезгә үземнең яшь чакларымдагы каз өмәсе ничек үткәнен сөйлим. Без яшь чакта каз өмәләре бик күңелле уза иде. Яз җитеп, бәбкә үләне үсеп чыккач, болын өстен каз бәбкәләре басып алыр иде. Шул бәбкәләр бөртек чәпләп, яшел үлән ашап, җәй буена матурланып үсәрләр иде. Барлык авыл казлары бәбкәләре белән инешләрдә, күлләрдә коенып, зифа казлар булып җитешерләр иде. Ә көз җиткәч, җирләр туңдыргач, беренче карлар яугач, авылда каз өмәләре гөрли башлый иде. Җиткән кызлар өйдән өйгә йөреп, хәтта күрше авылга барып та каз йолкышырлар, казларны су буена төшеп юарлар иде. Каз өмәсендәге җыр, бию, уен-көлке күп булыр иде. Андагы күңеллелек, сөйләп аңлата торган түгел! Кечрәк балалар канат-каурый сыдырырлар иде. Мичтә каз ите белән бәлеш пешеп, тәмле ис чыгарып утырыр иде.

**Икенче кыз:**И-и-и, Сания әби, бигрәк матур сөйлисең! Хәтта, каз бәлешен дә ашаган кебек булдык! <u>(Кызлар көлешәләр)</u>

**Исмәгыйль бабай:** (Казлар тотып керә) Безнең уңган күрше кызлары кереп тә җиткәннәр, рәхмәт яугыры! Менә сезгә казлар, жырлый-жырлый, армыйча эшләгез. <u>(Чыгып китә)</u>

**Сания әби**: Балакайларым, каз йолку тәртибен беләсезме, онытмадыгызмы?

**Өченче кыз**: Үзем сөйлим, үзем! (Бер кыз бала сөйли) Иң элек муеннарын җеп

белән бәйләргә кирәк, каннары тамып, каурыйларны, мамыкны пычратмасын өчен.

**Дүртенче кыз:** (Дәвам итә) култык астыннан канатларын йолкып алыйк. Аннары яндырырбыз.

**Бишенче кыз:** Алар җидәү була һәм аларны хәрәм канаты,- дип йөртәләр, шуңа күрә ул каурыйларны яндыралар.

**Алтынчы кыз:** Менә казлар да һәм кызлар да әзер, пешекләп, йолка башларбыз. (Кызлар көлешәләр)

**Сания әби**: Бигрәк акыллы инде үзегез, күз тимәсен!

Кая әле, кызларым, һәрберегезгә каз бирәм, йолка башлагыз.

(Кызлар казлар йолкып утыралар һүм чираттан шигырь укыйлар)

**Беренче кыз:**

Казларыгыз бигрәк матур,

Таза булып үскәннәр.

Ә йоннары, каурыйлары

Мамыкланып беткәннәр.

**Икенче кыз:**

Сания әби иртә-кичен

Нык карады аларны.

Тилгәннәрдән, каргалардан

Көне буе саклады.

**Өченче кыз:**

Үсә төшкәч, су буйларын

Бигрәк якын иттеләр.

Күрше казлар белән бергә

Дуслашып та киттеләр.

**Дүртенче кыз:**

Һәркем белә,

Каз ярата елганы.

Йөзә дә ул, чума да ул,

Су үстерә бит аны.

**Бишенче кыз:**

Су коенып, үлән ашап,

Матур булып үскәннәр!

Сания әби казлары

Симерешеп беткәннәр!

(Кызлар көлешеләр)

**Алтынчы кыз:**

Сания әби казларыннан

Бәлешләр пешерәдер.

Авыз итсәң, һичшиксез,

Төшләреңә керәдер!

**Сания әби:** Бигрәк тә җор телле инде үзегез, кызлар! Картым, ал әле гармуныңны, кызлар жырлый-жырлый эшләсеннәр.

(Исмәгыйль бабай гармунын ала да татар халык җырын "Каз канаты" н уйный, кызлар җырлый)

**Татар халык җыры: "Каз канаты"**

**Исмәгыйль бабай***:* (кызлар янына килеп) Карчык, кара әле, бу кызлар, җырлый-җырлый, казларны йолкып та бетергәннәр. Ничек шәп эшлиләр, күз тимәсен!

**Сания әби:** Әйе, кызларның куллары кулга йокмый, бик өлгерләр. Бар картым, бар, казан астына тагын ягып җибәр, баш-аякларын пешекләрбез.

(Исмәгыйль бабай чыгып китә)

**Сания әби:** Балалар, казларның мамыгын аерым, каурыйларын аерым салыгыз. Аллаһы боерса, быел каз мамыгыннан мендәр ясыйм. Исмәгыйль бабагыз яңа, йомшак мендәр сорый. (Барысы да көлешәләр). Каз мамыгыннан гына торган мендәр… Аңа яту белән эреп китәсең инде. Без кияүгә чыкканда әти-әниләр бирнәгә ястыкны каз мамыгыннан гына ясыйлар иде. Хәзер андый зур ястыклар

юк инде... Шушы каз мамыкларыннан җыйнак кына ике мендәр ясыйм, алла боерса.

Кызлар, йолкып бетергән казларны әнә теге өстәлгә куярсыз. Үзем эчләрен алып, эшкәртеп бетерермен.

**Исмәгыйль бабай:** (Гармун тотып керә). Әйдәгез әле, кызлар, тагын берәр җыр җырлап алыгыз.

<u>(Урам якта капка тавышы ишетелә. Бер-бер артлы малайлар керәләр)</u>

**Беренче малай:**

Шыгыр-шыгыр капканы
Шыгырдатмый япмабыз.
Каз өмәсе булган җирдән,
Беребез дә калмабыз.

**Икенче малай:** Исәнмесез, барыгыз! Бездән сәлам алыгыз.

**Өченче малай:** Сәлам Сания әбигә;

**Дүртенче малай:** Сәлам Исмәгыйль бабайга;

**Бишенче малай:** Сәлам матур кызларга;

**Алтынчы малай:** Өмә күрке – казларга. <u>(Көлешәләр)</u>

**Исмәгыйль бабай:** Ай-һай телгә оста икәнсез!

**Беренче кыз:** Мин бит күрше егетләрен үзем чакырган идем. Онытмаганнар, рәхмәт, килгәннәр. Кызлар, әйдәгез, казларны монда куйыйк. Сания әби эчләрен алганчы, уйнап-җырлап алыйк.

<u>(Казларны өстәлгә, урындыкларын ян-якка алып куялар. Малайлар, кызлар кара-каршы басалар, җырлыйлар)</u>

**Татар халык җыры: “Дүдәк-дүдәк”**

**Бию: “Парлаштык”** (Күмәк парлы бию башкарыла)

**Сания әби:** Балакайларым, казлар әзер, барыгыз, су буена төшеп чайкап менегез.

**Кызлар бергә:**Ярый, ярый!

<u>(Казларны көянтәләргә элеп күтәрәләр, малайлар булышалар. Кызлар түгәрәккә басалар,“Су буена төшәләр”)</u>

**Җыр: “Каз өмәсе “ (Илфат Дәүләтшин көе,Шәмсия  Җиһангирова сүзләре)**

(Кызлар түгәрәк буенча бии-бии йөри. Идәнгә зәңгәр төстә  җәймә җәелә (Күл). Килеп җиткәч, кызлар каз чайкыйлар)

**Икенче малай:**

Каз чайкыйлар безнең кызлар,

Куллары эшкә ята.

Мактаудан башка бер сүз юк

Бу кызларга карата.

(Кызлар туңдыра башлады бит эле, биеп алыйк булмаса, - диешәләр. Казларны бәке читенә куеп бииләр).

**Бию: “Каз канаты”(** татар халык җыры «Каз канаты» көенә)

(Кызлар пар канатлар тотып бииләр)

**Беренче кыз:** Казларыбыз да чистарды, кызлар. Җылынып та алдык. Әйдәгез, кайтабыз.

(Казларны алып түгәрәккә басалар. “Каз өмәсе” көе астында кайталар)

**Исмәгыйль бабай:** Карчыгым, безнең өмәчеләребез кайтып киләләр түгелме? Әйдә, капканы ачыйк.

(Әби белән бабай капкаларны ачалар)

**Икенче кыз:** Әбекәй, казларыңның эшен бетердек, чистарттык, бәкедә чайкадык.

**Исмәгыйль бабай:** Кайтып та җиттегезмени, балакайларым?! Кая казларыгызны алып куйыйм әле. Бигрәк уңган балалар булдыгыз! Рәхмәт яусын сезгә!

**Сания әби:** (казларны карап). Бәракалла, күр әле, бигрәк симез булганнар. Тынычлык, иминлек белән ашарга насыйп итсен инде Ходай. Бигрәк булган кызлар инде үзегез, күз тимәсен! Мин әле коймакларымны да пешереп бетермәдем.

**Өченче кыз:** Борчылма, Сания әби, без уйный торабыз.

**Уен: “Канат сыдыру”**

(Табакларга канат каурыйлары салынган, һәрбер кыз табакны ала һәм утыра.)

**Өченче кыз:** Әйдәгез әле, кем остарак сыдырыр икән?!

(Малайлар,кызлар такмаклар җырлый-җырлый эшлиләр)

**Өченче малай:**

Каурый сибәм су юлына,
Ишле булсын казыгыз.
Өмәләрдә эш күрсәтеп,
Җырлап-биеп алыгыз.

**Дүртенче малай:**

Бии-уйный сылу кызлар,
Чыңлый чулпы төймәсе.
Борынгыдан килгән йола-
Татарның каз өмәсе.

**Дүртенче малай:**

Шаулап, үтә, гөрләп үтә
Каз өмәсе авылда
Казлар белән аерлышу
Шатлыклы да, авыр да.

**Бишенче малай:**

Кумәк хезмәт, уен-көлке
Була каз өмәсендә.
Кызлар-егетләр жыела
Зур шатлык һәммәсенә!

**Алтынчы малай:**

Каз канатлары йолкасыз,
Йолкып ни майтарасыз?
Бу өйләрдә җырлап-көлеп,
Кемнәрне юатасыз?

**Кызлар бергә:**

Каз канатларын йолкабыз,

Йолкып, эш майтарабыз.
Җырлап-көлеп, уйнап-биеп,
Күңелне юатабыз.

**Беренче малай:**

Каз канатларын алырсыз,
Сыдырып-сыдырып салырсыз.
Бик авырсыз, бик сабырсыз,
Ахры, ятка калырсыз.

**Кызлар бергә:**

Каз канатларын алырбыз,
Сыдырып-сыдырып салырбыз.
Сабыр төбе – сары алтын,
Үз теләгәнгә барырбыз.

**Дүртенче кыз:** Кызлар,канатларны сыдырып та бетердек бит!

**Бишенче кыз:** Сания әби, менә сиңа коймак майларга, май канаты да булды.

<u>(Май канаты бирә)</u>

**Сания әби:** Рәхмәт яусын! Хәзер –хәзер коймакларым да пешә, каз мае белән майлыйм.

**Алтынчы кыз:** Әйдәгез, табышмаклар әйтешәбез. Без әйтәбез, ә малайлар җавапларын әйтсеннәр.

**Уен: “Табышмаклар әйтешү”**

**Беренче кыз:** Суда йөзә, бик күп илләрне гизә. Ул нәрсә?

**Беренче малай:** Каз, үрдәк.

**Икенче кыз:** Соскы борын-бакылдык,
Күп сөйләшә такылдык.

**Икенче малай:** Үрдәк.

**Өченче кыз:** Башы тарак, койрыгы урак,
Кычкыртып баргысын, уята барысын.

**Өченче малай:** Әтәч.

**Дүртенче кыз:** Мич тулы пәрәмәч, уртасында бер калач.

**Дүртенче малай:** Күк, ай, йолдызлар.

**Бишенче кыз:** Ач, дисәң, ачыла; яп, дисәң, ябыла.

**Бишенче малай:** Авыз.

**Алтынчы кыз:** Яратканга да ябышкан, яратмаганга да ябышкан. (Исем)

**Алтынчы малай**: (җавапны белми)

**Кызлар:**Белмиләр, белмиләр! Җәза бирәбез. Ата каз кебек биеп күрсәтсеннәр. Әтәч булып кычкырсыннар.

<u>(Малайлар бергәләп җаза үтиләр)</u>

**Беренче кыз**: (җилкенеп, дәртләнеп). Их, менә ичмасам, бу —бәйрәм! Мондый бәйрәм булганда, биемичә, җырламыйча ничек түзәргә кирәк. Әйдәгез, биибез!

**Бию: “Сөлге белән бию”**

**Уенлы җыр: “Чума үрдәк, чума каз” (Татар халык җыры һәм уены)**

Уйнаучылар кара-каршы ике рәт булып төзеләләр, парлашып кулга-кул тотыналар. Рәт башында бер ялгыз уенчы басып тора. Балалар барысы бергә җырлыйлар:

Чума үрдәк, чума каз,
Тирән күлне ярата ул, ярата.
Гүзәл үзенә иптәш эзли,
Белмим, кемне ярата шул, ярата.
Илмирны ярата шул, ярата.

Уйнаучылар, җыр ритмына туры китереп, хәрәкәтләнеп торалар. Ялгыз бала (Гүзәл), рәт арасыннан узып, үзенә бер иптәш сайлый һәм аны (Илмирны) җитәкләп ахырга барып баса. Үз парыннан аерылган уйнаучы рәт башына китә. (Уен шулай дәвам итә)

**Исмәгыйль бабай**: Карчыккаем, коймагыңны пешереп бетердеңме? Әйдә, яшь чакларны искә төшереп, без дә балалар белән уйнап алыйк.

**Сания әби:** (Коймаклар күтәреп чыга һәм өстәл өстенә куя). Яшь чакларны искә төшерик дисеңме, карткаем? Ярар, ярар, уйныйк! Нәрсә уйныйбыз?

**Икенче кыз:** Әйдәгез, “Базарлы” уйныйбыз.

<u>(“Базарлы” уены уйныйлар)</u>

**Уен: “Базарлы яки канат сату уены”**

Балалар кара-каршы басалар, бер якта кызлар,кулларына канат тотканнар, икенче якта егетләр. Такмаклар әйтә-әйтә, кызлар каз канатларын саталар, егетләр сатып алалар.

**Беренче кыз:**

Канат сатам, канат сатам

Ап-агын сайлап, карап.

Кемгә кирәк, алыгыз

Ничек акча ягыгыз?

(Малайлар канатларны карыйлар).

**Беренче малай:** Канатыгыз кыйммәтме?

**Икенче кыз:** Канатыбыз бер алтын.

**Икенче малай:** Кыйммәт икән: бер алтын!

**Малайлар бергә:** Канатлар сездә калсын.

**Өченче кыз:**

Егет саран булмасын,

Акча җәлләп тормасын.

**Өченче малай:**

Әйдә, сезнеңчә булсын.

Акчабыз да юк-югын.

**Дүртенче кыз:**

Ник аптырап торасыз!

Җырлап, түләп алырсыз!

(Парлашып эскәмиягә барып утыралар)

(Малайлар җырлый)

**Җыр:** “**Аккош йөзә, дәрья гизә”(**Татар халык көе, Мидхәт Миншин сүзләре)

**Бишенче кыз:**

Канат сату - кызык уен

Каз өмәсендә була.

Таныштыра, дуслаштыра

Яшьләрне иске йола.

**Алтынчы кыз:** Әйдәгез, биеп алабыз.

**Бию: "Бас, кызым,Әпипә"** (Татар халык җыры)

**Сания әби:** Балакайларым, әйдәгез, коймаклар суынып бетә. каз майларына манып, коймак ашыйк, чәй эчик әле.

<u>(Барысы да өстәл артына утыралар. Мактый-мактый коймак ашап, чәй эчәләр)</u>

**Беренче кыз:**

Гөрләп үтте, шаулап үтте
Авылда каз өмәсе.
Бу айларны, бу көннәрне
Көтеп ала һәммәсе.

**Беренче малай:**

Менә шулай каз өмәсен
Татарда үткәргәннәр.
Ә яшь кызлар күңел биреп
Бу эшкә өйрәнгәннәр.

**Икенче кыз:**

Каз өмәсе-иске йола,
Ул безне дуслаштыра.
Матурлыкны күңелләрдә
Мирас итеп калдыра.

**Алып баручы (тәрбияче):** Каз өмәсе азагына да якынлашты. Казларыгыз күп булсын. Йортларыгызда бәрәкәт артсын, тынычлык һәм дуслык булсын. Бәйрәм күренеше сезнең күңелләргә дәрт өстәсен!



Саба муниципаль районы “Олы Кибәче “Күбәләк” балалар бакчасы” тәрбиячесе

**Гайфуллина Ләйлә Фәнил кызы**

***“Карга боткасы”***

**Максат:** 1. Балаларны ата-бабаларыбызның милли бәйрәме, аның тарихы һәм халык тормышында әһәмияте белән таныштыру.

2. Борынгы гореф-гадәтләргә, канатлы дусларга, туган ягыбыз табигатенә сакчыл, кайгыртучан караш, ихтирамлылык, мәрхәмәтлелек тәрбияләү.

3. Хәтер, игътибарлылыкны үстерү.

**Бурычлар:** 1. Балаларның төрле жанрдагы музыкаль әсәрләрнең эчтәлеген аңлау сәләтен үстерүне дәвам итү.

2. Бәйрәмне әзерләүдә һәм үткәрүдә балаларның катнашу активлыгын үстерү.

3. Шигырьләрне сәнгатьле итеп сөйли белү күнекмәләрен камилләштерү, рольләрне башкару осталыкларын үстерүне дәвам итү.

4.Татар халкының милли бәйрәмнәре турында балаларның белемнәрен киңәйтү.Балаларда бәйрәм хисе, күңел күтәренкелеге,үзара дусларча мөнәсәбәт булдыру.

**Җиһазлар**: стенада язгы көн сүрәтләнгән табигать күренеше, агачлар, казан,самовар, чокырлар.

**Методик алымнар:** әңгәмә, уеннар, сәхнәләштерү.

**Бәйрәм барышы:**

<u>(татарча көй яңгырый)</u>

**Алып баручы:** Хәерле көннәр балалар! Сез ни өчен әлеге залга җыелдыгыз ? Әллә берәр бәйрәм булуы көтеләме?

**1 нче бала:** Боз һәм кар эреде,
Сулар йөгерде,

Егълап елгалар,

Яшьләр түгелде.

**2 нче бала:** Көннәр озая,

Төннәр кыскара.

Бу кайсы вакыт? —

Иә, әйтеп кара.

**Балалар:**(бергә) Яз килә! Яз килә!

**Җыр:** “Яз җитә” Ф.Кәрим сүзләре, Җ.Фәйзи музыкасы.

**3 нче бала:** Яз бәйрәме килгәнне

Бар халыклар күрсеннәр.

Менә нинди матур бәйрәм,

Нурлы бәйрәм дисеннәр.

**4 нче бала:** Карагыз әле, кара,

Карга очып бара.

Сез беләсезме, дусларым,

Ул да бит сөйләшә ала.

Музыка астында 2 карга очып керә.

**1нче карга** : Җылы илләрдән очабыз ,

Очабыз сезнең янга.

Сәлам, сәлам, балалар,

Кайтып җиттек туган якка.

**2 нче карга:** Канат очларына тагып,

Яхшы хәбәр алып килдек.

Матур язлар алып килдек,

Күңелле җәйләр китердек.

**Җыр:** “Кошлар килде” Г.Латыйп сүзләре,Ш.Мәҗитов көе.

**Алып баручы:** Менә, балалар, каргалар да килеп җитте. Аларга да күңелле булсын ,бер уйнап-җырлап алыйк әле.

**5 нче бала:** Хуш киләсез, үтегез,

Түрдән рәхим итегез.

Бездә бүген зур бәйрәм,

Уйныйбыз әйлән-бәйлән.

Кулны кулга алышып,

Кошлар кебек сайрашып,

Уйнасак шулай бергә,

Күңелсез булмас бердә.

**“Капкалы”** уены.

**Алып баручы:** Әйдәгез, балалар, каргалар килү хөрмәтенә “Карга баткасы” пешерәбез. Аның өчен безгә өйдән-өйгә кереп сый-нигъмәт, ярмалар җыярга кирәк булачак.

**Балалар:** (бергә) Әйдәгез!Әйдә!

**Алып баручы:** Ә сез бу бәйрәмнең ни өчен “Карга боткасы” дип йөртелгәнен беләсезме соң? (җаваплар тыңланыла).

**Алып баручы:** Әйдәгез , мин сезне, бу бәйрәмнең тарихы белән таныштырам. Ә сез игътибар белән тыңлап, исегездә калдырып барыгыз! (Балалар экран аша презентация белән танышып бара).

Борын-борын заманда кешеләр нилектән яз булганын белмәгәннәр.Алар язны кара каргалар алып килә, дип уйлаганнар.Шуңа күрә,кара каргаларны зурлап каршылаганнар,бәйрәм ясаганнар.Аны “Карга боткасы” дип атаганнар.

Бу көнне балалар матур итеп киенгәннәр, йомырка җыйганнар.Хуҗаларга рәхмәт әйтеп, изге теләкләр теләгәннәр,халыкны бәйрәмгә чакырганнар. Шулай авылны урап үткәннән соң ,ярма,май,сөт алып,табигатьнең иң күркәм җиренә - кардан ачыла башлаган су буйларына,ялан-кырларга яки тау битләренә җыелганнар.

Учак тергезеп,казан асканнар,ботка пешергәннәр. Ботка пешкәнче, төрле уеннар уйнаганнар,җырлар җырлаганнар,такмаклар әйтешкәннәр.Аннан соң,бергәләп ботка ашаганнар.

**Алып баручы:** Әйдәгез, дусларым, без дә өйләргә барыйк, дусларны чакырыйк,сый-хөрмәт җыйыйк.

**Балалар:** Әйдәгез,әйдәгез!

(музыка астында атлап баралар, ишегалдына килеп җитәләр. Эскәмиядә 2 әби утыра)

**6нчы бала:** Өйдәме түтәй?

Җәтрәк бир күкәй.

Бирсәң безгә өч күкәй,

Тавыгың салыр йөз күкәй.

Май кирәк,ярма кирәк,

Карга туена бар да кирәк.

**7нче бала:** Шикәр кирәк, тоз кирәк,
Карга туена бар да кирәк.
Тагын булса, он чыгар,
Пешерербез без чумар.

**1 нче әби:** Исәнмесез балалар! Хәзинәдәниләр булса, барын да бирербез.

**2 нче әби:** Мәгез, үскәннәрем, рәхим итегез. Каргалар да безнең сыйдан авыз итсеннәр.( Ярма,он, тоз, йомырка бирәләр)

**8 нче бала:** Ал да итәрбез әле,
Гөл дә итәрбез әле.
Матур биюләр биеп
Бәйрәм итәрбез әле.

**(бергәләшеп ,татарча көйгә бииләр)**

**9 нчы бала:** Сый җитәрлек булды,карга боткасын пешерергә кай тирәгә барыйк икән?

**10 нчы бала:** Чыпчык чыбыгым, ди,
Карга каеным, ди.
Киттек каенлыкка.

**Балалар:** (бергә) Әйдә әбекәйләр безнең белән!Бергә ботка пешербез.Уеннар уйнап, җырлар җырлап ,күңел ачырбыз.

(музыка астында агачлар янына киләләр. Казан асылган. Җиргә япма ябылган.

Аның өстендә самовар, чокырлар, тәлинкәләр тора)

**11 нче бала**:  И әбекәй,әбекәй,

Пешер безгә тәмлекәй.

Пешер безгә ботка да,

Пешер бераз әлбә дә.

**12 нче бала:** Тагын булсын күкәй,

Шикәр белән тәмле чәй.

Рәхмәт әйтеп,әбекәй,

Без итәрбез чәбәкәй.

**1 нче әби:** Булыр,балалар,бары да булыр.

Карга килер – казан асар,

Торна килер – тоз салыр,

Саескан килер – салма салыр,

Песнәк килер – пешерер,

Чыпчык килер – тикшерер,

Карга ашап бетерер.

Кап та коп.(Көлешәләр.)

**13 нче бала:** Карга әйтә:карр,карр.

Мичтә бәлеш бар,бар!

Мичтән бәлеш алыр идем,

Өйдә кунак бар,бар!

**14 нче бала:** Карга әйтә:карр,карр,

Нәни чеби бар,бар!

Берсен алып китәр, идем,

Караучысы бар,бар!


**Алып баручы:** Балалар,кошлар безнең дусларыбыз. Алар табигатькә ,кешеләргә зур файда китерәләр, корткыч кортларны, бөҗәкләрне юк итәләр. Шулай булгач, безгә кошларны рәнҗетмәскә, күчмә кошлар өчен оялар әзерләп куярга кирәк. Билгеле, сез аларны әзерләп куйгансыздыр.

**Алып баручы:** Яз хәбәрчеләре – кара каргалар белән тагын кайсы кошлар кайттылар? (балалар саныйлар).

**1 нче әби:** Балалар мин сезгә табышмаклар әйтәм, сүзнең нинди кошлар турында барганлыгын белерсезме икән? <u>(дөрес җаваплар әйтелгәч, кошлар рәсеме экранда күрсәтелә)</u>

| | |
|---|---|
| **1 табышмак.** Канатларын җәя итеп,<br>Ук шикелле оча ул.<br>Өчып барган җирдән генә,<br>Бөҗәкләрне тота ул.<br>Үреп ясый оясын,<br>Кәрзиндер дип торасың. **(Карлыгач)** |  |

| | |
|---|---|
| **2 табышмак.** Яздан башлап җәйгә кадәр,<br>Иген үскән кырларда<br>Бер өзлексез җырлап тора,<br>Җырлар җыры булганга.<br>Осталыкка ише юк<br>Аны сөймәс кеше юк. **(Тургай)** |  |

| | |
|---|---|
| **3 табышмак.** “Тук та тук!”- килгән тавышны<br>Туктап тыңлап торасың:<br>“Бармы әллә урманда,-дип<br>Морзе телеграфы”. **(Тукран)** |  |

| | |
|---|---|
| **4 табышмак.** Килсә әгәр гомереңнең<br>Озынлыгын беләсең.<br>“Минем гомер ничә ел?- дип<br>Сорау гына бирәсең. **(Күке)** |  |

| | |
|---|---|
| **5 табышмак.** Ялтыравык әйберләрне<br>Ташый ул оясына.<br>“Карак” дигән яман аты<br>Чыккандыр менә шуңа. **(Саескан)** |  |

**Алып баручы:**Әфәрин балалар! Канатлы дусларны рәнҗетмик!Алар безнең якта рәхәтләнеп яшәсеннәр, ишәйсеннәр, матур итеп сайрашсыннар.

**Җыр:** “Сыерчык” Г.Лотфи сүзләре, И.Шәмсетдинов көе.

**2 нче әби:** Ишетәм, ишетәм, табышмаклар беләсез икән, ә хәзер мәкальләрне белүегезне тикшереп карыйк әле. (Әби мәкальнең башын әйтә, балалар тәмамларга тиеш була)

Язгы көн ел туйдыра.

Яңгыр яуса – җиргә май.

Эш эшкә өйрәтә.

Эш беткәч - уйнарга ярый.

Бүгенге эшне иртәгәгә калдырма.

Агачны кем утырта – җимеш шуныкы.

Эше каты – икмәге татлы.

Кем эшләми – шул ашамый.

**1 нче әби:** Булдырдыгыз, балалар. Аякларыгыз өшемиме, бер биеп тә алыгыз инде.

**Бию:** “Күбәләкләр”.

**2 нче әби**: Балалар без ботканы пешерергә куйыйк, ә сез — күңел ача торыгыз. Рәхәтләнеп бер уйнап алыгыз.

**1.Җырлы –биюле уен** “Чума үрдәк, чума каз”.

**2. Уен** “Чүлмәк ватыш”.

**3. Уен** “Түбәтәй”.

**4. Уен** “Капчыклар киеп йөгерү”.

**1 нче әби:** Кунаклар, уеннарыгыздан туктап торыгыз, ботка пеште. Әйдәгез , табынга рәхим итегез. Өстәл артына утырыгыз.

**2 нче әби:** Менә монысы -Җир анага.

Җир атасы-җирән сакал.

Җир анасы- асыл бикә.

Түбәсенә туклыгың бир,

Тамырына ныклыгың бир.

Ил өстенә муллыгың бир,

Ил эчендәбезгә дә бир. (Савытка ботка сала)

**1 нче әби:**Менә монысы -суга,

Су иясе тотмасын. (Савытка ботка сала)

**2 нче әби:** Менә монысы күккә,

Яңгыр бирсен.

Кояшлы, җылы көннәр булсын!

Илгә туклык, гаиләгә иминлек килсен! (Савытка ботка сала)

**1 нче әби:** Монысы – каргаларга,

Канат очларында

Язны алып килсен өчен! (Савытка ботка сала)

**Карга:** Карр, карр, тәмле ботка бар, бар,

Әйбәт дуслар бар, бар.

**1 нче әби:** Ә калганы сезгә, кунаклар. Утырышыгыз! Сыйланыгыз! Муллык килсен! Бәхет килсен!

**2 нче әби:** Балалар сау-сәламәт үсегез, тәүфыйклы булыгыз.

(Балалар ашыйлар, рәхмәт әйтәләр)

**Алып баручы:** Хөрмәтле дуслар! Язгы бәйрәмнәрнең берсе – “Карга боткасы” бәйрәме ахырына якынлашып килә. Әйдәгез, бергәләп язларның мул

булуын, иген-ашлыкның күп булуын, дөньялар тыныч булуын телик!

Жырлый-җырлый, бии-бии,
Бәйрәм итик гел бергә.
Язлар килсен мул булып,
Иген уңсын кыр тулып.
Дуслар булсын һәр җирдә,
Тынычлык булсын һәр илдә.
Әйе шул, шулай шул,
Тынычлык булсын илдә.

**Җыр:** “Гүзәл туган ягыбыз” А.Минһаҗев сүзләре, Ә.Һадиева көе.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль бюджеттагы гомуми белем учреждениесе
Иске Икшермә “Кояшкай”балалар бакчасы тәрбиячесе
**Хәмидуллина Ләйлә Фәнис кызы**

## *“Гаилә бәйрәме”*

**Зал бәйрәмчә бизәлә**. Түрдәге стенага “Безнең гаилә – тату гаилә ” дип язылган плакат эленә. Катнашучы гаиләләр санынча өстәлләр куела, ә өстәлләрдә – гаиләләрнең эмблемасы һәм исем – фамилияләре язылган табличкалар. Балалар һәм кунаклар залга кергәндә “Тәфтиләү” көе яңгырап тора.

**Максат.**Балаларда үз халкыңның гореф – гадәтләре, йолалары турында күзаллау булдыру. Милли бәйрәмнәр аша үткән, хәзерге һәм киләчәк буыннар арасында  җанлы һәм ныклы элемтә урнаштыру.

Катнаш төркемдә бәйрәм кичәсе.

**1 нче бала.** Исәнмесез диеп сүз башлыймын,
Танышулар шулай башлана.
Исәнмесез диеп сүз башласам,

Бәхетем арта,күңел шатлана.

**2 нче бала.** Исәнмесез,кадерле кунаклар!

Менә сездә килеп җиткәнсез,

Безнең бакчабызның шау тормышын

Күреп китик әле,-дигәнсез.

**3 нче бала.** Яшәгез сез гел муллыкта.

Гел тыныч булсын галәм.

Сөекле кунакларыбызга

Ялкынлы...

**Балалар** (бергә).Кайнар сәлам!

Алып баручы:Хәерле кич,балалар!Хәерле кич,хөрмәтле әти-әниләр!

Бүген без "Гаилә бәйрәме"нә,әтиләрне 23 февраль Ватанны саклаучылар коне белән котларга,әниләрне 8 март халыкара хатын –кызлар көне белән котларга җыелдык.

1. Шатлыклар күңелебездә,
   Ал кояш күгебездә.
   Рәхәтләнеп бәйрәм итик-
   Гаилә бәйрәме бездә.
2. Бу кичәбез гөрләп үтсен,
   Истә калсын гомергә.
   Бәйрәмнәрсез яшәп була
   Әнисез яшәп булмый..
3. Бәйрәмсез бик куңелсез бит
   Күңелсездер сезгә дә.
   Бәйрәмнәр кирәк безгә дә
   Бәйрәмнәр кирәк сезгә дә,
   Кирәк һәммәбезгә дә.
4. Бәйрәмнәр кирәк әтигә!
   Бәйрәмнәр кирәк әнигә!

Бабай белән әбигә!

Ә шулай да,ә шулай да

Иң шәп бэйрәм –балачак!

*Җыр: " Әйлән-бәйлән"*

**Алып баручы:** Гаилә!Никадәр шатлык,никадәр тантана бу сүздә!Ә нәрсә соң ул гаилә? Ул нәрсәдән башлана?Нигә шулхәтле кадерле,якын сүз ул?Гаилә-ул җылы учак.Гаилә никадәр нык икәне,аннан бөркелгән җылылык та шулкадәр көчле була.Гаилә ул –тормышның нигезе. Әтиләр!Әти!Әтием!Ул гаилә башлыгы ,үзе ягымлы,үзе җитди,узе тырыш,үзе булган, балаларның бәхете,гаилә иминлеге өчен ару-талуны белми,көнне-төнгә ялгап,барлык көчен куя.Кыскасы,гаилә өчен ул төп терәк.Сезгә һәрчак бүгенгедәй үрнәк булуны,сәламәт яшәүне,бәхеткә ирешүне,тынычлык,гаиләгездә аңлашу һәм мәхәббәт телибез .

1.Әниләрне – ин кадерле дибез

Әтиләрсез яшәп буламы?

Таба алмам алмаштырыр кеше

Әйләнсәм дә бөтен дөньяны.

2."Балам",-диеп дәшүе дә бит,

Җылы сала җанга ,күңелгә .

Кайгыртуың өчен рәхмәт эти,

Шулай булсын иде гомергә.

3. Синең белән эти горурланам

Син бит минем иң зур терәгем

Авыр тормыш юлын җиңеләйтеп

Озак яшә шушы сина теләгем.

4.Әти янымда булганда

Бернәрсәдән курыкмыйм

Аның сүзе-миңа закон

Әтине мин гел мактыйм.

5. Уйнап-көлеп елмаерга

Кызык уйлап чыгарырга.

Китап укырга бергәләп,

Сабый җанлы әти кирәк.

6.Яңа һөнәр өйрәнгәндә

Акыллы киңәш бирергә.

Эшне эшләргә бергәләп,

Алтын куллы әти кирәк.

7.Әтиләр илнең терәге

Гаиләнең йорәге.

Авырлыкларга бирешми

Әтиләрнең йөрәге.

8. Әти булганда рәхәт,

Ул –безгә бик зур терәк.

Гаиләбез башлыгы ул

Барыбызга бик кирәк.

9.Иң кадерле,иң хөрмәтле-

Булсын җирдә әтиләр!

Әтиләрне кадерләсәң

Тыныч булыр илләр.

*Җыр:"Солдатта булган диләр"*

Алып баручы: Көннең яктылыгы кояшта,

Күкнең матурлыгы-йолдызларда,

Җирнең гүзәллеге –хатын кызларда!-дип язган шагыйрьләребез әниләребез турында.Җир йөзен бизәп торучы гүзәл затлар,сезне 8 Март бәйрәме белән тәбриклим!Яз сулышы гаиләләрегезгә муллык,күңелләрегезгә сабырлык,тәннәрегезгә саулык китерсен.Ходай сезне үз рәхим- шәфкатеннән ташламасын,теләкләрегезне тормышка ашырырга ярдәм итсен,өстәлләрегез мул,аш-суларыгыз тәмле,көннрегез ямьле булсын.

1. Иң-иң сабыр,иң-иң тыйнак,

   Иң ягымлы кешеләр.

Иң сөйкемле,иң кадерле.

Алар безнең әниләр!

2.Әни сүзе-иң бөек сүз .

Юк аңа һичбер алмаш.

Иң-иң әйбәт кешеләрдә дә

Әни кебек була алмас!

3.Бүген-әниләр  бәйрәме ,

Бүген җирдә тантана.

Кояш шуңа көлә буген ,

Гөлләр шуңа  шатлана.

4.Әниләрнең бәйрәменә

Куана шулай алар.

Әниләрне котлый бүген

Җирдә барлык балалар.

5.Миндә котлыйм,энием,сине.

Теләгем бар минем дә:

Мәңге шулай йолдыз кебек,

Балкы күңел күгемдә!

*Җыр: “Рәхмәт әнием”*

II өлеш.Концерт номерлары.

Рус халык биюе

Җыр  “Әтиемә”

Җыр “Мин әнигә булышам”

Моряклар биюе.

Чабата биюе.

Шигырь “Әниләр бәйрәмендә”

Җыр “Солдат булам”,”Солдатлар”.

Зонтиклар белән бию.

Бию “Барбарики”

III өлеш (Әти-әниләр өчен уеннар)

Хәрәкәттә-бәрәкәт,
Тәнгә керә көч һәм дәрт.
Тәнгә-сихәт,җанга-рәхәт
Хәрәкәттә мең рәхмәт.

Уеннар:

1 уен: ”Йомгакны кем тизрәк чорный”(Әниләр уң кул белән чорный,этиләр сул кул белән җепне тотып тора)

2 уен: “Тәмле” (Әниләр мандаринны әрчи,этиләр ашаталар)

3 уен: “Кем зирәк?” (сорауларга җавап бирү)

4 уен: “Без артислар” (“Шалкан” һәм “Йомры икмәк” әкиятләрен заманча сәхнәләштерү.)

5 уен “Җырлы- биюле уен”(Берәр уен уйнап күрсәтергә)

6 уен: “Шигырь сөйләү “ (Бер кеше башлый бер кеше дәвам итә)

7 уен “Уйлап тап” (хәрефләр бутап бирелгән  сүзне дөрес төзергә тиешләр)

8 уен:”Ягымлы сүзләр (Чәчәк таҗына  ягымлы сүзләр  язып өзеп ташлау)

9 уен:”Иҗади эш  (Дәфтәр битендә төшеп  калган сүзләрне  куеп шигырьне  дөресләп язу)

10 уен: “Туп йөртъ” аяк белән тупны тәгәрәтеп йөреп килү.

Алып баручы: Хөрмәтле,әти- әниләр,бүгенге бәйрәмгә килгәнегез,күңелле  итеп уеннарда катнашканыгыз  өчен зур рәхмәт сезгә.



Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе Иләбәр “Умырзая” балалар бакчасы тәрбиячесе

**Вахитова Энҗе Габделбәр кызы**

***Серле сандык.***

**Максат:** татар милли киемнәрендәге бизәкләр турында балаларның күзаллауларын тирәнәйтү.

**Бурычлар:**

1. Балаларда татар милли киемнәренә кызыксыну тәрбияләү. Үз эшләренә карап сөенү хисе тәрбияләү.

2. Балаларны татар бизәкләре белән таныштыру. Милли киемнәрнең исемнәрен, бизәлешләрен сөйләмдә кулланырга өйрәнү. Бизәк төзергә өйрәнү.

3. Лалә чәчәген, яфраклар ябыштыру ысулларын ныгыту.

**Җиһазлау:** сандык, түбәтәй, алъяпкыч, читек, милли киемдәге курчаклар, калфак, ноутбук, проектор, мольберт, җилем, салфетка, татар бизәкләрен слайдларда күрсәтү.

**Сүзлек өстендә эш:** Алъяпкыч, түбәтәй, читек, калфак, орнамент, лалә чәчәге.

**Шөгыль барышы.**

**Тәрбияче**: Балалар, хәерле иртә! Ничек кәефләрегез?

Кояшлы иртә кебек,
Тукай телен, татар телен
Өйрәнергә дип килдек.

Балалар, әйдәгез сезнең белән танышыйк әле. Мин Энҗе Габделбәр кызы булам. Ә сезнең исемегез ничек?

*(Каяндыр музыка тавышы ишетелә)*

-Балалар,тыңлагыз әле, ниндидер җыр тавышы ишетелә бит. Сез дә ишетәсезме? Ә кайдан килә икән соң бу тавыш?

**Балалар җаваплары**. *(Тәрбияче сандык янына килә.)* Балалар, шушы сандыктан ишетелә ахры бу матур җыр. (*Сандыкны балалар каршысына алып*

*килә.)* Чынлап та сандыкта кемнәрдер җырлый. Ә үзләре бик матур җырлыйлар. Нәрсә турында бу җыр?

**Балалар. -**Калфак, кәләпүш турында.

**Тәрбияче**. -Әйе, балалар. Әйдәгез, кемнәр җырлаганын шушы сандыкны ачып белик әле.

*(Тәрбияче сандыкны ача .Милли киемнән киенгән курчакларны ала*)

**Тәрбияче**. -Менә кемнәр икән ул. Безгә кунакка татар кызы һәм татар малае килгән. Балалар, ничек уйлыйсыз, аларның исемнәре ничек икән? Әйдәгез, үзләреннән сорап карыйк әле.

-Сезнең исемегез ничек?

-Гөлбикә, Гомәр.

-Гөлбикә, Гомәр - татар кызы һәм малае. Аларның милли киемнәрен карагыз әле. Гөлбикә озын итәкле күлмәк кигән. Башында калфак. Элек-электән, татар халкы матурлыкка омтылган. Матурлап киемнәр тегеп, аларга матур бизәкләр ясап, чигеп киенгәннәр, аякларында матур итеп бизәлгән читекләр, ир кешеләрнең башларында чигелгән түбәтәйләр, ә хатын кызларда – калфаклар булган. Менә Гөлбикә дә шул калфакларның берсен кигән. Ягез әле балалар, калфак сүзен бергәләп әйтеп карыйк. (*Балалар кабатлыйлар.)*

-Гөлбикә белән Гомәр безне карап-сынап утырсыннар әле.(Утыртып кую)

**Тәрбияче**. Афәрин, балалар. *(Тәрбияче сандыкка карый).* Балалар, безнең әби-бабайларыбыз бизәкле киемнәр киергә яратканнар: алъпкычы, калфагы, читеге, беләзеге-йөзеге дисеңме – болар барысы да милли хәзинә асылташлары. Гөлбикә дә сандыкка салып тагын башка милли киемнәрне дә алып килгән икән бит әле. Балалар, бу нәрсә икән?

**Балалар** : Алъяпкыч.

*(Балалар кабатлыйлар.)*

***Тәрбияче****:-* Алъяпкычны бер матур кызга кидертик әле. Раян, хәзер безгә санамыш ярдәмендә бер кызны сайларга булыш әле.

**Санамыш**. **Чәйнеккә акча салдым**

**Ничә булды, 100 булды.**

**Әтәлчек, мәтәлчек**

**Сиңа туры килде, чык! (**Кызга алъяпкычны кидертү)

-Әле калфагы да бар.

**Тәрбияче**. Әйдәгез, балалар сандыкны безгә тагы кем ачар икән? Балалар, ә менә монысы нәрсә? Кем белә?

**Балалар**: -Читек.

**Тәрбияче**: -Әйдәгез бергәләп әйтеп карыйк әле.*(Балалар кабатлыйлар.)*

-Читекне кайларда күргәнегез бар?

Читекне кызлар да, малайлар да кигәннәр. Бик матур, уңайлы, чигелгән аяк киеме ул. Балалар бу читек сезгә зуррак булыр, әйдәгез үзем киеп карыйм әле, миңа ярамый микән? Ярый икән.

**Тәрбияче**: -Балалар, ә менә монысы нәрсә икән?( Түбәтәй күрсәтелә.)

**Балалар**. -Түбәтәй.

**Тәрбияче**. Әйе, бу - түбәтәй, ир–атларның баш киеме. Күрәсезме, ул алтын җеп белән тегелгән. Әйдәгез, без дә түбәтәй киеп, бер уен уйнап алыйк әле.

***“Түбәтәйле” уены.***

Балалар түгәрәккә басалар. Түбәндәге җырны җырлый-җырлый, түбәтәйне бар-берсенә бирәләр. Җыр ахырында түбәтәй кемдә калса, шуңа җәза бирелә (Мәкаль, шигырь, бию).

*Түбәтәйнең иң матурын кигәнсез,*

*Бик ераклардан кунакка килгәнсез,*

*Эшкә батыр, төскә матур икәнсез,*

*Тирә- юньне соклandырыйм дигәнсез.*

*Кушымта:*

*Түп – түп –түп-түгәрәк  түбәтәй,*

*Түбәтәең энҗеләрдән укалы.*

*Түбәтәең менә кемдә тукталды.*

Түбәтәй кемдә кала – шул бала уртага чыгып: йә җырлый, йә шигырь сөйли, йә бии. (Мәсәлән, син нишлисең? – дип сорала. Мин биим). Уен берничә мәртәбә кабатлана.

Тәрбияче: Булдырдыгыз, балалар! -Безнең сандыкта тагы нәрсә бар икән? (Лэпбук) Балалар бу лэпбукта бик күп төрле уеннар бар.

**Уен**. Әйдәгез, менә бу уенны сезнең белән уйнап карыйк әле. Монда төрле милләт вәкилләренең костюмнары һәм баш киемнәре. Менә бу малайга татар халык киемен кидертеп, баш киемен дөрес итеп сайлап кидертик әле. Бу уенны кызларга тапшырам. Ә малайларга “Бизәкне җый” уены. Төрле бизәкләр арасыннан татар халкының милли бизәген җыеп бирегез әле.

-Балалар, без караган киемнәр барысы да матур итеп бизәлгән. Бу бизәкләр татар халык бизәкләре –орнаментлар дип атала.

Әйдәгез, бу сүзне бергәләп әйтеп карыйк әле.

*(Балалар кабатлыйлар.)*

-Балалар слайдка карыйк әле. Татар орнаментларын истә калдырыйк. Ниндиләре бар икән, исемнәрен истә калдырыйк.(Слайдларны карау)

-Ә менә сезнең дә шушы орнаментлар белән берәр кием бизәп карыйсыгыз киләме? Монда сандык төбендә бизәлмәгән алъяпкычлар бар. Хәзер шушы алъяпкычларны Гөлбикәгәгә татар орнаментлары белән матурлап бизәп бирәбез. Эш барышын аңлату, кагыйдәләрне искә төшерү.

*Балалар алъяпкычларны бизиләр.(ябыштыралар). Эш барышында күзәтеп йөрү, үзенчәлеклене хуплау, иң матур бизәкләрне башкаларга күрсәтеп мактау.*

**Тәрбияче**. Гөлбикә белән Гомәрне балалар үзебезнең группага алып кайтабызмы әллә? *Балалар җаваплары.*

**Тәрбияче**: Балалар, Гөлбикә дә дә сезгә тәмле күчтәнәч алып килгән. Нинди күчтәнәч икән ул, ничек уйлыйсыз? Бу-татар милли ризыгы - чәк-чәк. Тәмле итеп чәй эчәрбез, балалар.

Рефлексия. –Балалар, сез бүген нәрсәләр турында таныштыгыз, нинди белемнәр алдыгыз? Барыгыз да булдырдыгыз, афәрин балалар!(Җыр белән төгәлләү)

Энже мәрҗән калфагым.

Дәү әнием энже калфак

Бүләк итте үземә,

Энже калфак, үзе ап-ак,

Бик килешә йөземә.

Энже-мәрҗән калфагыма

Йөрим сөенеп кенә,

Сәхнәләргә чыгып лсырлыйм,

Калфаклар киеп кенә.

Әй калфагым, калфагым,

Калфаклар кияр чагым.

Күңелемә ямь бирүче

Нур булды шул калфагым.

Көзгеләргә күзем салсам

Хәйран калам үзем дә:

Җем-җем энҗе-мәрҗәннәрнең

Нуры уйный йөземдә.

Калфагымның матурлыгын

Һәммәсе дә күрсеннәр.

Энҗе калфак кигән кыз ул —

Татар кызы, дисеннәр.



Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы

3 нче номерлы балалар бакчасы тәрбиячесе

**Хаматгалимова Йолдыз Тәбрис кызы**

**Зурлар төркеме өчен “Акча кайдан килеп чыккан?”**

*Төп сүзләр: тәңкә, тиен, доллар,евро, рубл,банкнота.*

***Максат:*** Тәңкә, акча берәмлекләре һәм саклыкка җыелган акча белән таныштыру.Акчаны саклап тотарга өйрәтү.

**Бурычлар:** Балаларны күзәтергә, чагыштырырга, анализларга, нәтиҗә ясарга, күмәк эш итәргә өйрәтү.

Балаларның логик фикерләвен, күзәтүчәнлеген, кызыксыну һәм танып- белү сәләтләрен үстерү.

Балаларда бердәмлек, дуслык, кешеләргә хөрмәт хисе, тормышка мәхәббәт, әйләнә тирәгә сакчыл караш тәрбияләү.

***Тәрбияче балалар белән керә.***

- Балалар, бүген иртән эшкә килгәндә ишек төбендә ниндидер акча янчыгы таптым. Сез белмисезме, кем югалтты икән*? (Кошелекны ачып карый, хатны укый).*

- Менә кызык! Менә кемнең акча янчыгы икән бу? Балалар, биремнәрне чишәргә сез әзерме? *(Әзер).*

-Алайса башлыйбыз! Беренче бирем “Акчалар” диеп атала. Кибеттән товар сатып алыр өчен нәрсә эшләргә кирәк? *(Түләргә).*

- Ә нәрсә белән түләргә кирәк? *(Акча белән).*

- Дөрес, ә сез беләсезме акча кайдан килеп чыккан? Булган шундый вакыт, кешеләр акчаның ни икәнен белмәгәннәр. Үз куллары белән ризык, өй кирәк-яраклары әзерләгәннәр, балык тотканнар, ауга чыкканнар, җир сөреп төрле ярмалар үстергәннәр. Башта кешеләр бер-берсе белән шул товарларны

алыштырганнар, ә соңыннан акча уйлап тапканнар. Иң кулае, тимер акча диеп уйлаганнар алар. Кайсыгыз белә, тимер акча башкача ничек атала? *(Тәңкә).*

- Дөрес. Акча тимер генә булмый, кәгазь акчалар да була.Аларны ничек атыйлар? *(Банкноталар).*

-Бик дөрес. Һәр илнең үз акчасы була. Америкада – доллар, Франция һәм Германиядә – евро, ә бездә, Россиядә - рубль  диеп атала. Безнең Гном-эконом да сезгә шундый бирем биргән. Өстәлдә төрле ил акчалары ята, шулар арасыннан безнең илнекен аерып алуыгызны сорый ул.

- Булдырдыгыз! Ә хәзер сезнең белән әкият уйнап китик әле. Мин сезгә сораулар бирәм, ә сез дөрес  сорауга җавапны өстәлдән табып алып бирергә тиеш буласыз.

1. Шарик, песи Матроскин һәм дядя Федор сыер сатып алыр өчен кайдан акча алганнар? *(Хәзинә тапканнар)*

2. Кайсы әкият герое карт әбинең барлык теләкләрен дә үтәгән? *(Алтын балык).*

3. Кайсы әкият герое алтын күкәй салган? *(Чуар тавык)*

4. Кайсы әкият герое тәңкә тапкан һәм базарга барып күптөрле товар сатып алган үзенең туган көненә? *(Муха-цокотуха).*

- Бик дөрес  балалар! Арыгансыздыр, әйдәгез бергәләп ял итеп алыйк әле.

- Без әле бераз арыдык.

Ял итәргә уйладык.

Башны иябез алга

Ә аннары – артка.

Уңга, сулга борабыз

Аннан карап торабыз.

Иң өсләрен сикертәбез.

Кулларны биетәбез.

Бер алга бер артка сузып

Күңелле ял итәбез.

- Киләсе уеныбыз “Сатып  алам” диеп атала. Мин сезгә сүзләр әйтәм, әгәр аны акчага сатып алып була икән – чәбәк-чәбәк итәбез. Акчага сатып алып булмаса

– тыпырдыйбыз. (*Өй,әни, кояш, сөт, сәламәтлек, бәхет, конфетлар, планета, өстәл, велосипед*)

-Әлбәттә, энине, кояшны, сәламәтлекне, планетаны акчага сатып алып булмый. Балалар, сез барыгыз да беләсездер, акчаны кайларда саклыйлар? *(Банк, карта, кошелек)*

- Мин сезгә үзегезгә акча янчыгы ясарга тәгъдим итәм. *Балалар белән бергәләп кәгазьдән (оригами техникасы) акча янчыклары ясау.*

- Менә нинди матур акча янчыклары килеп чыкты безнең. Булдырдыгыз! Гном-эконом да сезгә ниндидер хәзинә калдырган, әйдәгез бергәләп карыйк әле *(Гном-эконом бүләк итеп калдырган алтын тәңкәләрне балаларга өләшү).*

МҮМБУ Түбән Кама шәһәре

“Гомуми үстерешле “Умырзая”балалар бакчасы” тәрбиячесе

**Сәхәбиева Гөлүсә Җәмил кызы**

***«Лего-мульфильм»***

**Эшчәнлек төре:** Оештырылган белем бирү эшчәнлеге

**Эшчәнлеккә кертелгән белем бирү өлкәләре:** Танып белү

**Максат:**

Балаларның «Өч аю» экияте геройларын LEGO конструкторы детальләреннән конструкцияләргә сәләтен үстерү.

**Бурычлар:**

- балаларда схема буенча әти аю, әни аю һәм аларның балалары кечкенә аюны төзүне ныгыту;

-балаларны аю моделен мөстәкыйль өйрәнүгә кызыксыну уяту;

-балаларда конструктордан экиятнең катлаулы булмаган сюжетын төзүне формалаштыру;

-коллектив эшне оештыра белүне камилләштерү;

-баланың иҗади сәләтләрен үстерү;

-сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү;

-образлы фикерләүне камилләштерү;

-бер-береңә ярдәм итәргә омтылу, пөхтәлек тәрбияләү;

-балаларның «Өч аю» рус халык әкияте турында белемнәрен ныгыту.

**Методик алымнар:** Күрсәтү, уеннар уйнау, әңгәмә,сөләү, сорауларга җавап бирү.

**Җиһазлау:** Телефон, өстәл планшеты, лего- конструктор, схемалар.

**Алдан үткәрелгән эш:** Матур әдәбият уку, иллюстрацияләр карау, «Өч аю» әкиятен искә төшерү, әңгәмәләр.

**Эшчәнлек барышы:**

Тәрбияче: Хәерле көн, балалар! Бүген шундый могҗизалы көн, кәефем дә бик яхшы. Ә сезнеке ничек?

Балалар: Бик яхшы.

Тәрбияче: Балалар, әйтегезче , бүген атнаның нинди көне?

Балалар: Бүген дүшәмбе.

Тәрбияче: Календаребездан карап алыйк әле, нинди бирем булыр микән бүгенге көнгә. Балалар, узган атнада без кемне командир итеп сайлап куйган идек әле, искә төшерик?

Балалар: Амиләне сайладык.

Тәрбияче: Димәк, QR ны Амилә ача.

(QR ачыла, лего- конструктор чыга)

Тәрбияче: Эхә, монда бик кызыклы бирем икән бит. Легодан әкият персонажларын ясарга тәкъдим ителгән. Минемчә, бу эш бик тә кызыклы. Бу эшне башкарабызмы?

Балалар: Әлбәттә.

Тәрбияче: Балалар, сезгә парлашырга кирәк булачак. Үзегезгә ошаган конвертны алып, өстәлләр артына басарга. Игътибарлы булырга кирәк. Өстәлнең үс төсе барлыгын истән чыгармагыз, балалар.

Күрәм командалар үз урыннарын таптылар. Димәк эшебезне башлыйбыз.

(Балаларның схема буенча әкият геройларын мөстәкыйль төзүе)

Тәрбияче: Кайсы команда эшен бетерде, урнаштыра барабыз. Игътибар белән карагыз әле, балалар, бу нинди әкияттән?

Балалар: Өч аю.

Тәрбияче: Әйе, бик, дөрес. Ә кем язган ул әкиятне?

Балалар: Лев Николаевич Толстой.

Тәрбияче: Миңа бик кызык, балалар, бу төзелешләр белән нәрсә эшли алабыз? Нинди тәкъдимнәр әйтә аласыз?

Балалар: Уйнарга, мультфильм төшерергә була һ.б.

Тәрбияче: Бигрәк кызык тәкъдимнәр, миңа бик ошый! Ә бит, мультфильмны төшергәндә һәркем ниндидер роль башкара. Кемнәр нинди роль башкаруын карточкалардан беләбез. Рәхим итеп карточкалар алабыз.

Тәрбияче: Менә хәзер, мультфильмны төшерә башлыйбыз.

(Мультфильм төшерү)

Тәрбияче: Менә хәзер үзебезнең эшебезне карасак та була. Телисезме?

Балалар: Әйе, бик тә телибез.

(Балаларның мультфильм карау)

Тәрбияче: Балалар, менә нинди зур эш башкардык без, әйме? Нинди авырлыклар булды?

Балалар: Аюларны төзергә, мультфильм төшерергә һ.б.

Тәрбияче: Минемчә, сезгә бүгенге бирем бик ошады. Ә менә, миңа сез бик ошадыгыз!Рәхмәт сезгә!Сау-сәламәт булыгыз!

Балалар: Саубулыгыз!

Менә шуның белән эшчәнлегебез тәмам.



Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы

Теләче 3нче номерлы балалар бакчасы мәктәпкәчә

белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

тәрбиячесе

**Ибрагимова Айгөл Рафаэль кызы**

***“Әкият аланында”***

Сторителлинг алымын кулланып зурлар төркемендә сөйләм үсеше буенча ачык шөгыль

Шөгыльнең технологик картасы

Шөгыль төре: сөйләм үсеше

Методик алымнар һәм чаралар:сүзле уен, хәрәкәтле уеннар, сөенеч мизгеле, сорау бирү, мактау, бәяләү.

Оештыру формасы: төркемчә (подгрупповая)

Интеграль белем бирү өлкәләре: Танып белү үсеше, социаль- коммуникатив үсеш, физик үсеш, сөйләм үсеше.

Максат: Матур әдәбиятка, әкиятләргә кызыксыну уяту. Әкиятләрнең эчтәлеге буенча белемнәрен ныгыту.

Сторителлинг алымын кулланып балаларның коммуникатив сыйфатларын үстерү, диалогик сөйләмне камилләштерү.

**Бурычлар:**

**Үстерү бурычы:**

- игътибарны, фикерләүне, күзаллауны , бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

**Белем бирү бурычы:**

- балаларның кыргый һәм йорт хайваннары турындагы белемнәрен ныгыту,
- сенсор сәләтләрен, предметларны тану мөмкинлекләрен ныгыту,

**Тәрбия бурычы:**

- әкият персонажларына карата яхшы мөнәсәбәт тәрбияләү,
- матур әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү.

**Көтелгән нәтиҗәләр:** -Балаларның сөйләм үсеше белемнәрен киңәйтү, әкиятләргә кызыксынуны арттыру.

-Укыган әсәрләрне истә калдырдыру (тыңлыйлар, карыйлар, сөйлиләр.)

-Ышанычны аклау, сүз тыңлау, җаваплылык тою, тырышлык , дус-туганлык кебек хис-тойгылар тәрбияләүне дәвам иттерү.

**Күрсәтмә материаллар:** Сәяхәт картасы, тылсымлы елга (зәңгәр материал),күпер ,тылсымлы таяк, рәсемле шакмаклар, аланлык һәм тылсымлы келәм, интерактив такта презентация.

Эшчәнлек төзелеше:

1. Келәмгә утыру,әкият иленә очу.
2. Сөенеч мизгеле ( сюрприз моменты) : Карта барлыкка килә.
3. Дидактик уен: “Яраткан әкиятеңне әйт”.
4. Елга аша чыгу.
5. Сүзле уен: “Без барабыз-барабыз”.
6. Дидактик уен: “Әкиятнең исемен әйт”(**интерактив** такта буенча).
7. Физкультминутка «Кар атышып уйныйбыз».
8. Сөенеч мизгеле ( сюрприз моменты) .Тоемлау тартмасы.
9. Әкият төзү.
10. Дидактик уен: “Кайсы герой артык” (интерактив такта буенча).
11. Сүзле уен : “Без барабыз барабыз”.
12. Елга аша чыгу.
13. Келәмгә утыру,төркемгә кайту.

**Эшчәнлек барышы:**

| № | Шөгыль этаплары | Тәрбияче эшчәнлеге | Балалар эшчәнлеге | Вакыт | Көтелгән нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|---|---|
| | Кереш өлеш | – Балалар, кәефләрегез ничек?<br>– Әйдәгез әле, | Кояшлы иртә кебек. Учларыннан | 1мин. | Балалар шөгыльгә уен белән |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | эшчәнлегебезне башлаганчы, кәефләребезне күтәреп, кояш нурлары белән уйнап алыйк.<br>Кояш җылысын учыбызга җыябыз.<br>Битләребезне җылытабыз.<br>Күзләребезне, чәчебездән сыпырабыз.<br>Үзебезне яратабыз.<br>Бер-беребезгә елмаябыз.<br>Үзебезнең яхшы кәефебез белән уртаклашабыз. | өреп очыралар. | | бик иркен кереп киттеләр. |
| | Балаларда уенга кызыксыну уяту | Ерак таулар,елга-күлләр һәм куе урманнар артында бер бик зур ил бар,аның исеме –Балачак. Ул илдә Җир шарындагы барлык балаларда булганнар, сезнең әти-әниләрегездә ,әби-бабайларыгызда кечкенә чакларында булганнар.Балачак илендә алар үзләренең дуслары-әкиятләр белән танышканнар.<br>Әкият өйрәтә безне<br>Батыр,тырыш булырга.<br>Әдәплелек сыйфатларын<br>Үзеңдә булдырырга.<br>Матурлыкка,дөреслеккә<br>Өйрәтә ул әкият.<br>Усаллыкны, явызлыкны<br>Фаш итә ул әкият.<br>Балалар ә сез әкиятләр яратасызмы?(балалар җавабы)<br>Әйе чыннанда сез әкиятләрне бик яратып тыңлыйсыз һәм карыйсыз,ә кайвакыт үзегездә уйлап чыгарасыз. | Балалар җавап бирәләр | 1 мин. | Балалар кызыксынып шөгыльдә катнашалар. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Бүген мин сезгә шул әкият иленә сәяхәткә барарга тәгъдим итәм. | | | |
| | Проблемадан чыгу юлы | Ул илгә машина беләндә барып булмый,пороходта да йөзеп барып булмый,ракета белән дә очып барып булмый. Ләкин анда күзалдына китереп,үзең уйлап чыгарып,могҗизалы әкият канатларында гына эләгеп була.<br> Әйдәгез басыгыз,минем артымнан кабатлагыз.<br>Без бастык түгәрәккә(түгәрәкә басып)<br>Бергәләшеп уйнарбыз<br>(кулга кул тотынышып)<br>Әкияти илгә барырбыз,<br>Һәм урманны карарбыз.<br>*Тыныч көй.*<br>*Тылсымлы көй.* | Балалар түгәрәккә басалар.<br><br>Күзләрне<br><br>йомып,келәмгә утыралар. | 3мин. | Балалар шөгыль барышында үзләрен бик иркен тоталар. |
| | Сөенеч мизгеле (сюрприз моменты) | *Төркемдә әкияти карта барлыкка килә.*<br>Балалар карагыз әле!Нәрсә икән бу? Бу бит әкияти илнең картасы. Карта ярдәмендә нишләп була балалар?Бик дөрес әйтәсез.Аның ярдәмендә сәяхәткә барып була.Картага күз салыйк әле балалар.Иң беренче безнең юлыбызда тылсымлы елга.Аның аркылы чыгарга кирәк,моның өчен безгә “Тылсымлы таяк” уенын уйнап яраткан әкият исемнәрен әйтергә кирәк,шул вакытта гына | Балалар җавабы.<br><br>Балалар яраткан әкият исемнәрен атыйлар. | 6 мин. | Балалар шөгыль барышында үзләрен бик иркен тоталар. Сорауларга дөрес җавап бирәләр. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | елга аша чыгып булачак.Тылсымлы таякны бер-беребезгә биреп,яраткан әкият исемнәрен атарга кирәк булачак.<br>Афәрин балалар. Әйдәгез күперне игътибарлы гына чыгабыз.<br>*1 нче слайд:* Урман рәсеме.<br>Балалар менә без сезнең белән тылсымлы урманга килеп җиттек. Әйдәгез әле урман аланлыгына утырышыйк әле.(идәндә утыргычлар)<br>Әйдәгез балалар әкияттән өзек тыңлап,дөрес җавап эзлик.<br>*2 нче слайд*<br>1.Тиен дустым, барсана, кызларыма әйтсәнә, хәлемне белергә килсеннәрче... *(балалар җавабыннан соң)* (“Өч кыз”).<br>*3 нче слайд*<br>2.Бармагымны Былтыр кысты,Былтыр кысты... *(балалар җавабыннан соң)* (“Шурәле”).<br>*4 нче слайд*<br>3.Әй юләр,юләр, үз шәүләңнән үзең куркасын ич... *(балалар җавабыннан соң)* (“Бикбатыр белән Биккуркак”).<br>*5нче слайд*<br>4.Куянга бер кишер,бер кәбестә, бер чөгендер, бер кыяр биргән... *(балалар җавабыннан соң)(*“Аю | Балалар елганы чыгалар.<br><br>Балалар җавабы<br><br>Балалар җавабы<br><br>Балалар җавабы<br><br>Балалар җавабы<br><br>Балалар | | Балалар әкият белән бик якын таныш. Экрандагы биремнәргә дөрес җавап бирәләр. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Әппәс”).<br>*6 нчы слайд*<br>5.Әби аларны ашатырга тотынса, “җимне миңа әзрәк бирдең”, “ник минем өлешемә кердең?” дип кычкырыша башлыйлар икән...<br>*(балалар җавабыннан соң)* (“Чукмар белән Тукмар”).<br>Афәрин балалар.Әйдәгез бергәләшеп ял итеп алабыз.<br>Йомшак карны алабыз,<br>Аннан туплар ясыйбыз,<br>Кар атышып уйныйбыз,<br>Бик күңелле яшибез... | җавабы<br><br>Балалар белән берлектә физминут күнегүләрен кабатлау<br><br>Балалар җавабы. | | |
| | | Юлыбызны дәвам итәбез биремнәрне үти барабыз. Балалар карагыз әле бу ни? Нәрсә яшерелгән икән?(куе зәңгәр келәм астында тоемлау тартмасы яшерелгән). | Балалар җавабы. | | |
| | | Тарма икән бу,әмма гади тармага гына ошамаган эчендә ни бар икән балалар? Сәмирә кулыңны кертеп кара эле,нәрсә тоясың,нәрсә бар? (шакмак) (бер ничә балага тәгъдим итү). | Балалар җавабы.<br><br>Балалар җавабы. | | |
| | | Балалар ә хәзер һәр берегез чиратлашып , берешәр шакмак алып, шакмакта нинди рәсем тошерелгән әйтеп бирегез. Балалар безгә шакмактагы рәсемнәр ярдәмендә әкият төзергә кирәк булачак.<br>(Сторителлинг алымын | Балалар җавабы. | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | кулланып шакмаклар ярдәмендә әкият төзү). Нинди әкият килеп чыкты? Шакмаклар ярдәмендә төзелгән әкиятебез “Аю Әппәс” әкияте булып чыкты,афәрин балалар. | | | |
| | Теманы кабатлау | Безгә кайтыр юлга чыкканчы алдагы биремне үтәргә кирәк.Мин сезгә әкият геройларын күрсәтәм, сез нинди әкияттән икәнен белеп, артык рәсемне атарга тиеш буласыз. (Экран белән эш).<br>*7 нче слайд.*<br>“Өч кыз” әкияте (артык рәсем- аю)<br>*8нче слайд*<br>“Шүрәле” әкияте(артык рәсем- кыз)<br>*9нчы слайд*<br>“Бикбатыр белән Биккуркак” әкияте(артык рәсем- тавык)<br>*10 нче слайд*<br>“Аю Әппәс” әкияте(артык рәсем- төлке)<br>*11 нче слайд*<br>“Чукмар белән Тукмар” әкияте(артык рәсем- каз) | Балалар җавабы<br><br>Балалар җавабы<br><br>Балалар җавабы<br><br>Балалар җавабы<br><br>Балалар җавабы | 5мин. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Үзконтр оль һәм үзанализ | Ә хәзер безгә тылсымлы келәм янына эләгергә кирәк,моның өчен иң элек елга аша чыгарга кирәк. (Елга аша чыгу)<br>Менә келәм янына килеп тә җиттек. Балалар без кая сәяхәт итәргә бардык? Сезгә әкияти илдә ошадымы? Сәяхәтебез турында кемнәргә сөйләрсез икән? | Балалар җавабы | 2 мин. | |
| | Анализ | Ә хәзер безгә төркемгә кайтыр вакыт җиткән ,әйдәгез тылсымлы келәмгә басыйк һәм минем арттан тылсымлы сүзләрне кабатлыйк.<br>Бер-ике-өй-дүрт-биш (бармакларын бөгеп)<br>Без бастык түгәрәккә(түгәрәкә басып)<br>Әкият белән саубуллашабыз (кулга кул тотынышып)<br>Һәм төркемгә кайтабыз<br>*Тыныч көй.*<br>*Тылсымлы көй.* | Балалар түгәрәккә басалар<br><br>Күзләрне йомып,келәм гә утыралар. | 1 мин. | Балаларга шөгыль барышы бик ошады, әкияткә, сторителли нг алымы буенча шакмаклар ярдәмендә әкият төзүгә кызыксыну уятылды. |

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Коркачык “Черемушка” балалар бакчасы мәктәпкәчә муниципаль бюджет учреждениесе беренче категорияле тәрбиячесе

**Ибраһимова Лилия Әсхәт кызы**

***“Татар милли ризыклары”***

*(зурлар төркемендә сөйләм телен үстерү)*

**Максат:**Балаларны татар халык милли ризыклары белән таныштыруны дәвам итү.

**Бурычлар:**

1.Татар халык ашлары исемнәрен әйтә белү истә калдыру

2.Яңа сүзләрне сөйләмгә кертү,балаларның бәйләнешле сөйләмнәрен үстерү.

3.Татар милли ризыкларына кызыксыну тудыру.

**Җиһазлар:**Ноутбок,проектор,картиналар,милли ризык муляжлары,фотолар,самовар,туп.

**Тәрбияче:**Хәерле көн балалар,әйдәгез әле бер-беребезгә хәерле көннәр теләп шөгелебезне башлыйк.

Хәерле көн сина,

Хәерле көн миңа,

Хәерле көн сезгә,

Хәерле көн безгә.

Балалар, мин сезгә Шәүкәт Галиевның “Кунаклар” шигырень укып китәсем килә.Ә сез экранга карап таныш рәсемнәрнең исемнәрен әйтеп барсагыз яхшы булыр иде.Карыйбызмы?(тәрбияче укый,балалар экранга карап милли ризыкларның исемен кабатлыйлар)

1нче слайд.Без әзерлибез табын

Китереп бөтен ягын .

2нче слайд.Уртага куйдык чәчәк

3нче слайд.Чәчәк янына чәкчәк

4нче слайд.Бавырсак һәм кош теле

5нче слайд.Ризыклар төрле-төрле

Сумса,бәлеш, өчпочмак

6нчы слайд.Гөбәдия һәм коймак

Һәркемгә чыгар өлеш

7нче слайд.Бар кыстыбый һәм бәлеш

8нче слайд.Җитешегез кунаклар,

Кыстатмагыз кунаклар.

9нчы слайд.Өйгә кайтып китәргә

Ашыкмагыз кунаклар.

**Тәрбияче:**Балалар,шигырьдә гөбәдия,чәкәк,кош теле,пәрәмәч ,бәлеш нинди ризыклар икән?(балалар сөйли)

**Тәрбияче:**Дөрес, ә нинди милләтнеке икән алар?

**Балалар:**Бу ризыклар -татар халык ризыклары.

**Тәрбияче:**Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре,киемнәре булган кебек үзенен ризыклары да бар дип сөйләшкән идек үткән шөгелебездә.Бүген дә татар халык ашлары турында сөйләшүебезне дәвам итәрбез. Элек-электән үк әбиләребез,әниләребез,татар хатын кызлары аш-суга бик оста булганнар.Нинди генә ризыклар пешермәгәннәр.Балалар,тактабызда нинди рәсем икән.(балалар рәсемгә карап җавап бирәләр)

**Тәрбияче:**Әйе, тактада өстәл рәсеме сүрәтләнгән.Өстәлне икенче төрле табын дип атыйлар.Анда татар халык ашлары куелган.Бу табында нинди милли ризыклар бар икән,балалар? (балалар җавабы)

**Тәрбияче:** Ә нигә өчпочмакны “өчпочмак“ дип әйтәләр?

**Балалар:** Чөнки өч почмагы бар.

**Тәрбияче:** Бәлеш белән өчпочмак ничек аерыла?

**Балалар:** Өчпочмакның өч почмагы бар, ә бәлеш – түгәрәк.

**Тәрбияче:**Сез чәкчәк яратысызмы?(балалар җавабы)

Чыннан да чәкчәкне барыбыз да ярата, ул һәр бәйрәмнең (туй, туган көн һ.б.) түрендә, ул бик тәмле, ә шулай да ул файдалымы?

**Балалар:** Әйе.

**Тәрбияче:** Ни өчен файдалы?

**Балалар:** Чирләгәндә баллы чәкчәк белән чәй эчәләр.

**Тәрбияче:** Ә күп ашасаң, файдалымы?

**Балалар:** Юк.

**Тәрбияче:** Ни өчен файдалы түгел дип уйлыйсың, Зәлия?

**Зәлия:** Күп ашасаң, тешне сызлата, кулга буяла.

**Тәрбияче**:Ә менә бу ризык нәрсә икән соң?Без бүген татар халкының тагын бер ризыгы белән танышып китәрбез.Бу балалар талкыш кәләвә.(рәсемен күрсәтә).Талкыш кәләвәне ашаганыгыз бармы?(балалар җавабы)Талкыш кәләвә бик авыр ясала. Талкыш кәләвә әлбәгә баллы катнашма кушып ясала. Әлбә - татарларда электән билгеле – аны сары майга он салып пешерәләр. Ә кәләвә килеп чыксын дисәң, аерым савытта су, шикәр комы һәм балны куерганчы кайнатып, әлбәгә кушасың. Һәм, барлыкка килгән шушы баллы камырны нәзек җепселләр барлыкка килгәнче бертуктамый ян-якка тартырга кирәк. Әзер булгач, талкыш кәләвәне чынаяк кебек берәр савытка тутырып, формага китерәсең дә, суыткычка куясың.Әйдәгез шушы туп ярдәмендә талкыш кәләвә татлы дип кабатлыйк әле.(балалар туп белән сүзләр кабатлыйлар)

**Тәрбияче:**(ишектән елаган тавыш ишетелә) Ишетәсезме,балалар ,ниндидер тавыш ишетелә.

*(елап Шәвәли керә)*

**Шәвәли:**Исәнмесез...

**Балалар:**Исәнмесез.

**Тәрбияче:**Кем син,нәрсә булды,ник елыйсың?

**Шәвәли:**Мин Шәвәли шук малай,үткен малай булсам да,бүген бер нәрсә дә аңламавымны белдем.(елап сөйли)

**Тәрбияче:** Шәвәли,нәрсәне аңламадың?

**Шәвәли:**Мәктәптә укытучым табышмаклар һәм рәсемнәр биргән иде.Табышмакларның җавабын нинди рәсемгә туры килгәнен әйтергә иде. Ә мин белмәдем,укытучым өйдә җавапларын табып килергә кушты.Хәзер кемнән генә сорыйм икән дип аптырап йөрим.Шуңа кәефем дә китте.

**Тәрбияче:**Безнең балалар табышмаклар чишәргә яраталар.Балалар,Шәвәлигә әллә без ярдәм итәбезме?

**Балалар:** Әйдәгез ярдәм итәбез.(Шәвәли сумкасыннан табышмаклар ала,балалар табышмаклар чишәләр,туры килгән рәсемнәрне сайлап алалар.)

Йомырка белән онны
Бутап камыр басканнар.
Бәрәңге, ит, тоз салып,
Почмаклар ясаганнар. (Өчпочмак)
Утырсам да мин менә
Тыйнак кына, тик кенә.
Эчем тулы ит кенә,
Май белән, дөге белән. (Бәлеш)
Чыж иттереп саласың,
Бик тиз генә аласың.
Балга манып кабасың.
Ул нәрсә? (Коймак)
Камыр эчендә бәрәңге
Йә, уйлап кара әле. (Кыстыбый)
Иттән генә торам мин
Майга чумып чыгам мин. (Пәрәмәч)
Вак-вак кына итеп кисеп,
Өяләр аны таудай!
Чак-чак кына алып, өзеп
Аша, дустым, син шулай. (Чәк-чәк)

**Тәрбияче:**Булдырдыгыз ,балалар.

**Шәвәли:**Ә сумкада тагын менә бу калган икән.Менә бу нәрсә?

**Балалар:**Самовар.

**Шәвәли:**Ә аның белән нәрсә эшлиләр?(балалар аңлаталар)

**Тәрбияче:**Уңган балалар икәнсез.Аргансыздыр,әллә уйнап ял итеп алыйкмы?

**Балалар:**Әйдәгез уйныйбыз.

**Тәрбияче:**Ярар,әйдәгез,Самовар уенын уйныйк.(Самовар уенын уйныйлар,бер бала самовар булып уртага баса ,калган балалар милли ризык муляжлары тотып,җыр җырлап самовар тирәсендә әйләнәләр,җыр беткәч уртадагы бала берсен сайлап ала.Нинди милли ризык икәнен әйтергә тиеш. )

Там,там,тамчы там

Тамуыңны яратам,

Там,там,тамчы там

Тамуыңны яратам,

Самовардан тәмле итеп

Чәй эчәргә яратам

**Шәвәли:** Балалар, сез бик тапкыр,акыллы,җитез икәнсез. Сезгә бик зур рәхмәт.Мин мәктәпкә барып табышмакларның җавапларын әйтим әле.Дусларыма да сезнең турында сөйләрмен,бик зур рәхмәт сезгә сау булыгыз.*(Шәвәли рәсемнәрне алып чыгып китә)*

**Тәрбияче:**Балалар сез әниләрегез белән милли ризык пешереп фотога төшкән идегез бит әле.Шуны безгә  дә күрсәтеп сөйләп үтмәссез микән?(балалар фотоларны тотып сөйлиләр)

**Тәрбияче:**Булдырдыгыз балалар.Балалар,табын артында,өстәл янында утыруның үзенең әдәпләре бар.Менә Гәйшәнең дәү әнисе безгә видеоязма аша киңәшләрен биргән.Карап,тыңлап үтәбезме?(балалар видеоязманы карыйлар)

**Тәрбияче:** Балалар, без сезнең белән нәрсә турында сөйләштек?

Бүгенге көнебез сезгә ошадымы? Нәрсәсе күбрәк ошады?(балалар сөйли)

Шулай итеп шөгелебез ахырына якынлашты,сау булыгыз.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Салавыч балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең югары квалификацион категорияле тәрбиячеләре

**Закирова Чулпан Габделбәр кызы**

**Мөхәммәдиева Энҗе Рафис кызы**

***“Татар халкынның борынгыдан килгән урманчылык касепләре”***

**Этабы:** Гомүмиләштерү.

**Максат**: Клуб сәгате методикасын кулланып балаларның урманчылык касепләре турында алган белемнәрен камилләштерү (уен формасында)

**Үстерү бурыч:** Логик фикер йөртү сәләтен үстерү, күргән, кызыксындырган әйберләрен тотып карау, иснәп карау, эшләп карау юлы белән иҗади хыял сәләтләрен үстерү, балаларның иҗадыйлыгын үстерү.

**Тәрбия бирү бурычы:**Урманчылык кәсепләренә карата мәхәббәт , табигать байлыкларына карата сак караш тәрбияләү,мәрхәмәтлелек , ярдәмчеллек, бердәмлек сыйфатлары тәрбияләү.

**Белем бирү бурычлары**:Урман һәм аның байлыклары турындагы белемнәрен системалаштыру, тирәнәйтү.

**Төп белем бирү өлкәсе:** танып белү үсеше.

**Интеграль белем бирү өлкәләре**:Социаль-коммуникатив үсеш, сөйләм үсеше, сәнгати-эстетик үсеш, физик үсеш.

**Методик алымнар һәм чаралар:** клуб сәгате методик алымы, уен, сорау-җавап, табышмаклар,мәкалләр, биремнәр.

**Җиһазлар**: Эшчәнлек алдан әзерләп куйган тукталышларда үтә. Зал тукталышларга бүленгән. Беренче тукталыш- урман аланы, икенче тукталыш-ак әби өе, өченче тукталыш- урманчы, дүртенче тукталыш- остаханә итеп ясалган.

**Сүзлек өстендә эш**: Сукыр кычыткан, чебен гөмбәсе, keләймә, табигатьне саклау турындагы закон, такта ышкысы, Иван-чәй.

**Алдан үткәрелгән эш**:”Урман һәм аның байлыклары турында, урман белән бәйле борынгы кәсепләр турында әңгәмә уздыру картиналар карау.

**Кереш өлеш:**

Балаларның алдан ук нәрсә белән кызыксынганын ачыклау.

**Төп өлеш:**

**I тукталык.**

**Тәрбияче**:-Балалалр, күңелле булсын очен нинди матур аланлык әзерләдем сезгә. Кошлар сайрый, агачлар шаулый . Карагыз әле, нинди матурлык.



Шушындый матур аланлыкларны  нинди җирләрдә күргәнегез бар?

Балалар: Урманда

Тәрбияче: Ә ни очен урман, урман дип атала икән балалар?

Балалар: ......

(йөткергән тавыш ишетелә)

Тәрбияче: Абау, кайсыгыз йөткерә? (эзлим)

Балалар:  Гөлнур апа ул

Тәрбияче:  Балалар, Гөлнур апага тизрәк терелсен өчен булышырга кирәк. Алайса ул иртәгә безнең янга бакчага килә дә алмас. Ничек итеп булышырбыз икән инде? Кем белә?

Балалар: Укол кадарга кирәк, дару эчәргә кирәк, ятып торырга кирәк.

Гөлнур апа: Ай, балалар, мин уколдан бик куркам, дару да эчергә яратмыйм, ятып та торасым килми бит. Нишлик икән? (уйланып тора) Әәә, белдем, искә төште, урман кырыенда ак әби яши, ул авыруны үләннәр белән дәвалый. Әйдәгез, мин сезне ак әби янына алып барам. Ак әбидән дәваланыр өчен үләннәр дә алып кайтырмын.

Бергәләп ак әби янына китәләр. (Ак әбинен өй эчендә миллекләр, үләннәр

эленеп тора) Балалалрны Ак әби каршы ала.
Гөлнур: Әбекәй авырып киттем бит әле. Дәваланырга дип килдем. Бу юлы үзем генә түгел балалар белән килдем. Аларның да сине күрәселәре килде.



**Икенче тукталыш**

Ак әби : Исәнннәрмесез, оланнарым. Исән-сау килеп җиттегезме?
Тәрбияче: Әбекәй, без суык тигәндә сарымсак, суган, лимонның файдасын күрәбез. Ә менә урманның файдасын, үләннәр белән дәвалануның файдасы турында бик аз беләбез икән. Безгә дә үләннәр турында сөйләп кит әле.
Ак әби: Сөйлим, балалар, ник белгәннне сөйләмәскә ди. Сөйлим. Менә болары төрле дару үләннәре кушып ясалган миллекләр. Шушы миллек белән мунчада парланып чабынып җибәрсәң иллә дә рәхәт була, тәннәр язылып, сихәтләнеп китә.  Менә болары дару үләннәре (дару үләннәре тутырган савытларны күрсәтә) Сары, зәңгәр мәтрүшкә, ромашка, юкә чәчәге, үги ана яфрагы....
Ромашка тамак, эч авыруларын, һәм яраларны дәвалаганда ярдәм итә.Үги ана яфрагын эч авыртканда, салкын тигәндә төнәтеп эчәләр. Сары мәтрүшкәне ашказаны авыруларыннан эчәләр. Пешүләрдән, стоматит авыруларыннан файдаланалар. Бака яфрагыннан ясалган сыек ботканы төрле яраларга ягып бәйләп куялар. Төнәтмәсен бронхит, астма, туберкулез авыруларыннан файдаланалар.
Балалар, урманда бик күп агачлар да үсә. Алар турында да күп итеп сөйләргә була. Тик мин бу эшне урманчыга, урман хуҗасына тапшырыйм әле. Ул бу өлкәдә күбрәк белә. Менә шушы юл белән китик әле. Ул шунда агачларны карап йөридер.

Тәрбияче: Рәхмәт, әбекәй. Без синең янында бик күп файдалы үләннәр хакында белдек. Менә хәзер гел, гел авырып тормабыз инде. Үләннәр белән дәваланырбыз.

Юлны дәвам итәбез. Урман аланына килеп чыгабыз. Анда урманчы каршы ала.

**Өченче тукталыш**



Урманчы: Исәнмесез, балалар.

Балалар: Исәнмесез.

Урманчы: Балалар, якынырак килегез әле. Менә монда килеп утырыгыз әле. Коверыгыз да нинди йомшак, нәкъ чирәм шикелле, ә менә бу йомшак мендәрчекләрне агач төпләре шикелле хис итегез. Минем урманымда бик күп агачлар үсә. Әйдәгез әле, бергәләп презентация карап китик әле. (Бергәләп презентация карыйбыз)

Урманчы: Сез нинди агачлар беләсез?

Балалар : Каен, усак, юкә, чыршы, нарат...

Урманчы: Балалар, урман кешеләргә ни өчен кирәк икән?

Балалар: Чиста һава өчен, матурлык өчен, агачтан өйләр салыр өчен.

Урманчы: Әйе, балалар, агачтан өй салыр өчен агачны бик озак еллар үстерергә кирәк. Агачны орлыктан утырталар, аннан кәлшә үсеп чыга, кәлшәне аерым утыртып карап торалар, тернәкләнеп киткәч кенә агач булып үсә башлый. Өй сала торган агач 60-70 ел үскән булырга тиеш. Урманда саф һава, рәхәтләнеп ял итәсең, кошлар тавышын тыңлыйсың, яшел төс күзләргә файдалы, яшәр өчен көч туплыйсың. Урман –безнең байлыгыбыз. Безгә ул байлыкны кадерләп сакларга кирәк. Балалар, карагыз әле, минем кулымда нәрсә күрәсез?

Балалар: Кызыл китап.

Урманчы: Ул ни өчен кызыл төстә икән?

Балалар: Кызыл төс - тыючы төс, тукта, тыел дип әйтә.

Урманчы: Бик дөрес. Бу китапка бик аз калып баручы үсемлекләр, хайваннар кертелгән. Без кызыл китапка кертелгән тереклек ияләрен сакларга бурычлы. Кешеләр “Кызыл китапка” кергән хайваннарны, үсемлекләрне генә түгел, ә бөтен тирә-яктагы табигатьне, елгаларны, күлләрне, урманнарны сакларга тиеш. Чөнки без шул һаваны сулап яшибез. Табигатьне саклау турында закон бар, аны бозарга бер кемнең дә хакы юк. Бу законны олылар да, балалар да үтәргә тиеш. Балалар, сез дә, без дә табигатьне сакларга тиеш. Ә сезнең табигатьне саклау буенча ниләр эшләгәнегез бар?

Балалар: Агачлар утырттык...

Урманчы: бик дөрес. Менә балалар узган ел сез дә без биргән кәлшәләрне утыртып бик зур яхшылык эшләдегез. Менә ул агачлар да матур булып үсеп киткәннәр. Зур үскәч “без утырткан агачлар ”- дип горурланып йөрерсез. Табигатькә, кешелек дөньясына бик зур файда, яхшылык эшләдегез. Үсеп өлгергәч шул агачларны кисеп алып, эшкәртеп кулланышка кирәкле, файдалы әйберләр ясарлар.

Тәрбияче: Без бик кирәкле эш эшләгәнбез. Без булдырабыз.

Мәсәлән: сыерчык оясы, урындык, такта ясарлар. Балалар, мин бу юлы да буш кул белән килмәдем. Сезгә агач орлыклары әзер булган, өлгергән күркәләр алып килдем. Үзегез шушы күркә кабырчыклары астыннан орлыкларны җыеп алырсыз да аерым савытларга утыртып куярсыз. Су сибеп, карап торсагыз, орлыктан кечкенә кәлшәләр тишелеп чыгар. Яз көне шул кәлшәләрне тышка утыртырсыз. Зур, биек агачлар булып үсәрләр.

Тәрбияче: Рәхмәт сезгә. Әлбәттә, без бу орлыклардан агачлар үстерергә сүз бирәбез. Шулай бит, балалар?

Урманчы: Балалар, мин сезгә бүләк итеп урман, андагы үсемлекләр, агачлар, хайван, җәнлекләр турында видеоролик та алып килдем. Тәрбияче апагыз белән карарсыз. Ә хәзер, әйдәгез, балалар, мин сезне агач эшкәртү мастерскоена алып

барыйм әле.

(Балалар белән юлны алга таба дәвам итәбез. Мастерской тукталышына килеп җитәбез. Фәрит абый каршы ала).

**Дүртенче тукталыш.**

Кул эшләре остасы:

Исәнмесез, балалар.

Балалар:

Фәрит абый: Яхшы, балалар. Үзегезнең кәефләрегез ничек соң?

Фәрит абый: Менә балалар кайчан гына минем зур  мастерскоемда очрашкан идек. Бу юлы сезгә кунакка үзем килеп чыктым әле. Сезнең белән күрешүемә мин бик шат. Сезгә мин үземнең кечкенә мастерскоемны гына алып килдем. Чөнки монда сез күргән зур, зур станоклар сыймас иде. Сез аларның барысын да күрдегез, тотып карадыгыз, эшләп тә карадыгыз әле. Мин сезнең белән бергә булган презентацияне алып килдем (презентация карау). Сезгә ошадымы миндә кунакта?

Фәрит абый: Менә мин монда такта ышкылау өчен ышкы алып килдем (тактаны ышкылап күрсәтә) Күрәсезме, нинди шома, матур булып кала безнең такта. Шушы такталардан матур урындыклар, сыннар,сыерчык оялары, савытлар ясарга була. Менә мин сезгә күрсәтер очен  шушы тактаны эшкәртеп ясаган эшләнмәләремне алып килдем. Менә монысы чүкеч белән кадак. Егетләр сезнең барыгызның да кадак кагып караганыгыз бар инде, шулай бит.

Балалар:

Фәрит абый: балалар менә мин урманга баргач, җирдә нинди табигый материал күрәм, барысын да җыя барам. Мастерскойга кайткач шулардан матур әйберләр ясыйм. Менә сезгә дә урманнан җыеп кайткан күркәләремне алып килдем әле. Үзегезгә ошаган берәр нәрсә ясарсыз. Сезгә бүләк итәм.

**Мөстәкыйль эшчәнлек**

Кул эшләре башкару пунктына кайтып,  урман байлыкларыннан үзләре теләгән кул эшләре башкару**.**

**Йомгаклау өлеше.**

Балалар, без бүген нәрсә турында сөйләштек?

Урманчылык белән бәйле нинди кәсепләр турында сөйләштек?



Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының

“Кече Рәс “Дуслык” балалар бакчасы”

мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе”

I категорияле тәрбияче

**Әхмәтханова Гөлсинә Камил кызы**

Һәр миллэт үз җирлегендә барлыкка килгән һәм буыннан-буынга күчә торган гореф-гадәтләрен, кешеләрнең яшәү рәвешләрен, үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен, карашларын, зәвыкларын сакларга омтылган.

Балаларга белем һәм тәрбия бирүдәге минем максатларымның берсе: халкыбызның йола, гореф – гадәт, милли бәйрәмнәрен өйрәнү һәм ерак бабаларыбыздан безгә мирас булып калган шушы рухи байлыкларыбызны саклап киләчәк яшь буынга җиткерү.

Менә бу урак ( кулыма чын урак тотып, балаларга күрсәтәм) – безнең әби бабаларыбызның эш коралы. Шушы кечкенә генә урак бөтен гаиләне туендырган, ачлыктан саклап калган.

Элек игеннәр өлгерүен, уракка төшәргә вакыт җиткәнме, юкмы икәнен авылның өлкән тәҗрибәле картларыннан сорашып, белешеп торганнар.

Урак өсте башлануның үз ырымы да булган. Кулы җиңел кеше беренче басуга барып, уракны башлап җибәрергә тиеш булган. Аны уңганрак кешегә әйтеп, я кич атна , я базар көнне башлап җибәрә торган булганнар.

Авыл халкы кояш чykканнан алып батканчыга кадәр җиң сызганып басуда эшләгән, иген иккән.

(Кулыма тастымалга куелган кара ипи алам). Менә бу кара икмәк маңгай тирен агызып, авыр кул хезмәте белән башкарылган хезмәт җимеше.

Әнгам Атнабаевның “ Кара икмәк” шигырен сөйлим.

Әнкәй миңа кара икмәк, чәйнәп,
Имезлеккә салып биргән дә,
Үзе киткән урак урырга…
Елаганмын,
ләкин чыдаганмын –
Икмәк белән була торырга.



Кара икмәк бәләкәйдән таныш,
Беләм аның кыйммәт икәнен,
Бер телеме өчен
кешеләрнең
Таңга кадәр чират көткәнен.

Кара икмәк зур мәсьәлә булган:
Йөз граммлап аны бүлгәннәр,
Кош теледәй шул граммнар өчен
Сугышканнар,
хәтта үлгәннәр…

Шул чакларны онытабыз бугай,
Әйтерсең лә, күктән төшкәнбез.
Беребез дә күктән төшмәгәнбез,
Кара икмәк ашап үскәнбез.

Ул вакытлар мәңге кире кайтмас,
Без ашыйбыз хәзер калачын,

Тик калачның тәмен белер өчен
Онытмаек аның карасын.

Онытмаек
җәйге чилләләрдә
Җиң сызганып кемнәр иккәнен,
Онытмаек бәрәкәтле җирнең –
Кара җирнең кара икмәген!

Икмәк – туклык, сәламәтлек, хезмәт, шатлык нигезе, муллык билгесе.

Шундый заман булган: әби – бабаларыбыз иген иккән, бер түтәрәм җирендә сука белән җәфа чиккән, чабагачы белән ашлык суккан, урак урып, аркасына бөкре чыккан. Бу эш коралларын безнең балаларыбыз музейларда гына күрә ала.Басуларда хәзер көчле техникалар гөрли.

Хәзер башка заманда яшибез.Әмма икмәк элеккечә кадерле. Кулымдагы икмәктән дә бөек нәрсә юк минем өчен.



Казан шәһәре Совет районынын «402 нче катнаш төрдәге балалар
бакчасы» муниципаль автономияле мәктпәкәчә белем бирү учреждениясе югары категорияле тәрбиячесе
Хасанова Рания Илсур кызы

**Эссе "Кем ул тәрбияче?"**

"Балалар яхшы булсын өчен, аларны бәхетле итәргә кирәк, "- дигән язучы Оскар Уайльд. Дөрестән дә, баланы кем бәхетле итә? Әти-әнисе, туганнары, дуслары, уенчыклары... Ә иң күп вакытын бала кем белән үткәрә?. Билгеле, тәрбияче белән. Димәк, иң беренче чиратта балага бәхет бүләк итүче - ул аның

тәрбиячесе икән. Бала кайчан бәхетле? Аны аңлаучы, яклаучы, кайгыртучы, аның белән уйнаучы, барлык вакытын, көчен, сабырлыгын, белемен, мәхәббәтен бирүче кеше гел янында булганда сабый бәхетле. Димәк, тәрбияче – ул Һөнәр генә түгел, ә тормыш рәвеше икән. Һәр кеше дә тәрбияче була алмый, минемчә. Ә кем соң ул тәрбияче? Бүген мин шул сорауга җавап эзләп карыйм. Чөнки мин – тәрбияче.

Тәрбияче – күп курлы шәхес, күпкырлы талант иясе. Моны бер генә уку йортында да өйрәтмиләр. Тәрбияче булу өчен балалар арасында тормыш мәктәбе узарга кирәк, нарасыйлар үзләре сине тәрбиялиләр. “Тәрбияче тәрбияләнүчене кем итеп үстерергә теләсә, үзе дә шундый булырга тиеш,” дигән Владимир Иванович Далж. Кем ул тәрбияче? Кем ул мин?

Беренче чиратта, тәрбияче – ул артистка! Тормыштагы хәлләрне онытып, бернигә дә карамый гел шат күңелле, көләч йөзле, ярдәмчел, матур, күркәм булу – минем һөнәремнең мөһим шарты. Кичә тылсымчы булсам, бүген куян ролен уйныйм, иртәгә светофор булам. Балалар белән елыйм, уйныйм, көләм.

Мин – бала! Үзенең бала чагын хәтерләмәгән, хыял дөньясында яшәмәгән, фантазиясе булмаган кеше тәрбияче була алмый. Дөньяга балалар күзе аша караган, алар дөньясын аңлаган чиста күңелле кеше генә балалар янәшәсендә булырга лаек!

Мин- психолог! Минем төркемдә төрле холыклы, бер-берсенә охшамаган балалар тәрбияләнә. Алар төрле: тыңлаучан яки иркә, үткен яки оялчан, аралашучан яки үз өченә бикләнгән, тел бистәсе яки аз сүзле. Аларның барсының да күңеленә ачкыч таба белергә кирәк. Моның өчен балага дус булырга ,үпкәләтмәскә, алдамаска, үз көченә ышанырга кирәк.

Мин – татар! Әйе, милләтем буенча мин татар, Татарстанда яшим, татар балаларын тәрбиялим. Джон Локк “Балаларны дөрес тәрбияләүгә бөтен халыкның иминлеге бәйле.” дигән. Димәк, мин халкымның киләчәге өчен җаваплы. Үзенең гореф-гадәтләрен, үткәнен белгән шәхес кенә илне алга җибәрергә сәләтле. Ә мин шундый шәхес тәрбияләүче!

Мин – җырчы! Әйе, кечкенәдән үземчә генә җырлап йөрергә яраттым. Балаларга бишек җырлары, такмаклары, күмәк бәйрәм җырлары җырларга туры килә. Җырлап кына түгел, ул җырны балага өйрәтергә дә кирәк бит әле. Үзең белмәгәнне кешегә өйрәтеп булмый.

Мин – биюче! Әйе, балалар бакчасы шундый сихерле дөнья инде ул: Булмаган сәләтләрен дә ачыла. Һәр бәйрәм җырсыз-биюсез үтми, шулай булгач, биергә дә өйрәндем. Татарча да, русча да, аюча да, төлкечә дә бии беләм хәзер.

Мин – шагыйрә! Тәрбияче һөнәре – иҗади һөнәр.  Һәр көнебез планлаштырылган. Һәр яңа чараны уйлап чыгарырга, иҗат итәргә, шигырь дә язарга туры килә күп вакыт.

Мин- рәссам! Әйе, балачак дөньясы чуар , могҗизалы төрле төстә! Аны язып, әйтеп кенә бетереп булмый, күрсәтә дә белергә кирәк. Без, тәрбиячеләр, кәгазьдән дә, пластилиннан да, җептән дә – кул астындагы һәрнәсәдән матурлык тудыручылар.

Мин – остаз! Чөнки кечкенә дусларымны өйрәтәм, үрнәк күрсәтәм, әдәп -әхлак тәрбиялим, интеллектуаль сәләтләрен, сөйләм телләрен үстерәм.

Мин – әни! Әгәр әни булмасам, һәр баланы үзеңнекедәй якын күреп , яратып булмыйдыр ул. Минем тәрбияләнүчеләрем бәхетле, сәламәт, игелекле булсыннар иде. Мине хәтерләрендә иң яхшы , изге, кирәкле кеше итеп калдырсыннар иде дип хезмәт куям.

Ә барыннан да бигрәк мин – Кеше! Баларның хисләрен, кайгы-шатлыкларын үзе аркылы үткәрә алучы, аларның уңышлары өчен сөенүче гади кеше дә мин. Әйе, һәр кеше кебек мин дә арыйм, авырыйм, күңел төшенкелегенә бирeләм. Нәрсә генә кичерсәм дә, балалар һәм эш урыным – ул минем һөнәрем генә түгел, ул минем тормышымның асылы.

Тәрбияче булуым белән бәхетле мин! Төркемдәге һәр баланы бертигез күреп, аңа йөрәк җылысын биреп, бәхетле балачак, өметле киләчәк бүләк итү – тәрбия эшенең асылы дип саныйм. Күренекле мәгърифәтчебез Ризаэтдин Фәхретдин “Бала чактан алынган тәрбияне соңыннан  бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас” дип әйткән. Әгәрдә без үстергән, тәрбияләгән яшь буын йөзгә

кызыллык китермәслек, уңышлар казанырлык булса, илебезнең киләчәге дә өметле булыр. Сугышлар булмас, кан коелмас, гаделлек, тынычлык урнашыр, барыбыз да бәхетле булырбыз. Менә нинди олы һөнәр иясе икән ул – тәрбияче! Димәк, мин дөрес юл сайлаганмын.



Татарстан Республикасы муниципаль районының
“Биектау “Көнбагышкай” балалар бакчасы, мәктәпкәчә
белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе
тәрбиячесе

**Әхмәтова  Гүзалия Илгиз кызы**

***“ Тылсымлы тартма” дидактик уены***

**«Уен ул – балаларның рухи дөньясына җанлы агым**
**тамашасы үтеп керә торган, тирә-юнь**
**төшенчәләрен үз эченә алган олы якты тәрәзә.**
**Уен – кызыксынучанлыкка ут бирүче очкын»**
**В.А.Сухомлинский**

Мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләренең төп бурычы балаларны рухи яктан бай, физик яктан сәламәт итеп үстерү. Алар төрле юллар белән тормышка ашырыла. Ә шулар арасында иң әһәмиятлесе – уеннар.

Уен – ул бала эшчәнлегенең, тормышының аерылгысыз өлеше. Уеннар кешегә яшәве күңеллерәк булсын өчен кирәк. Җитез, өлгер, зирәк булып үсүе өчен төрле характердагы уеннар балалар тормышының аерылгысыз юлдашы булырга тиеш. Яшь буын тормышның төрле җайсызлыкларына бирешмәскә, уңышсызлыкларыннан җебеп төшмәскә тиеш дибез. Ә моңа яшьтән үк балаларның төрле уеннар уйнаулары аша ирешергә мөмкин.

Сезгә үзем ясаган дидактик уенның берсен тәкъдим итәсем килә.Бу “Тылсымлы тартма”күп функцияле .Барлык уен материаллары тартмаларда урнаштырылган. Бу уеннар урта төркемнән алып өлкән төркемгә кадәр кулланыла ала.

Уенның максаты: балаларга уеннар аша милли тәрбия бирү.

Уенның бурычлары:

Белем бирү:

-балаларда татар теле буенча УМК нигезендә сүзлек минимумын кулланып яшьтәшләре белән аралашуга кызыксыну уяту, уенга кызыксыну, дуслык, иптәшне тыңлый белү тәрбияләү.

-татар милли орнаменты белән таныштыру, балаларның игътибарын элементларның аермасына юнәлтү. Шаблоннар белән үрнәк ясарга өйрәтү. Балалар сойләм телен татар милли орнаменты исемнәре белән баету.

Үстерелешле: иҗади активлыкны, сәнгатьле зәвыкны үстерү, үз-үзеңне раслау ихтыяҗын саклау. Форма, төс, пропорция хисләрен үстерү, вак моториканы, күрү-мотор координацияләрен үстерү.



Тәрбияви: татар халык сәнгате белән кызыксыну уяту.

1.“**Татар милли киемнәрен бизәгез”**

Максат:балаларның милли костюм элементлары турында белемнэрен ныгыту, балаларны төсле шаблоннар ярдәмендә формаларда үз композицияләрен төзәргә өйрәтү

Уенда түбәтәй ,алъяпкыч,күлмәк,читек силуэты, Татар орнаменты элементлары -тюльпан,кыңгырау, яфраклар кулланыла.

Һәр уенчы бер силуэт ала һәм, татар орнаменты элементларын сайлап, аның өстенә үрнәк куя

**2. “Киселгән рәсемнәрдән үрнәк ясарга”**

Максат:балаларны татар орнаменты элементларының белемнәрен ныгытырга, иҗатны һәм фантазияне үстерергә өйрәтү, игътибар, тырышлыктәрбияләү.

Уен кагыйдәсе :үрнәкбуенчабизәкнеңөлешләрен табу.

**3. “Өстәмә рәсем табыгыз”**

Уен кагыйдәсе: Татар орнаменты арасында артык элемент табу һәмаңлатып бирү.

**4.“Пар табу һәм рәсемгә исем бирү”**

Максат:балаларны татар орнаменты элементларын табарга һәм атарга өйрэтергэ:тюлпан,кыңгырау,яфрак,алардан парлар төзергэ.

**5. ”Домино- милли бизәк”**

Уен кагыйдәсе:балалар чиратлап башка карточканың шул ук рәсеменә туры килгән нинди дә булса орнамент рәсеме белән карточкалар урнаштыралар .Беренче булып карточкаларын куйган кеше җиңүче була.

Дидактик уен балаларда халык орнаменты мотивлары буенча үрнәкләр төзү күнекмәләрен формалаштыра. Бу уен үткән материалны ныгытырга, хәтерне ,игътибарны, иҗатны һәм фантазияне үстерергә ярдәм итә ,тырышлык тәрбияли.



Әлеге уенны балалар бакчасы тәрбиячеләре, түгәрәк җитәкчеләре, өй шартларында әти-әниләр  уен буларак кына түгел, ә татар һәм рус телләренә өйрәтү, дөрес аралашу чарасы буларак шөгыль итеп тәкуллана ала.

Балаларны туган якның тарихына өйрәткәндә, без һәр баланың шәхесен үстерәбез, киләчәктә толерантлы халык Иясе булуына ышанабыз, чөнки үткән тарих нигезендә генә хәзергене, киләчәкне күзаллап була.

Балалар тиз үсә, ләкин алар балачактан нәрсә алырлар...

«Син олы илне искә төшермисең,
Йөргән, белгән, күргәнне,
Син шул Ватанны искә төшерәсең,
Кечкенә чактан күргәнне»

К.Симонов



Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү
учреждениясе Теләче 2 нче номерлы балалар бакчасы

югары  категорияле тәрбиячесе

**Йосыпова Гөлсинә Фәүхетдин кызы**

***Мини – музей “Татар өе”***

Элеккеге заманнарда, татар гаиләләре дүртпочмаклы йортта, бер бүлмәдә яшәгәннәр. Әлеге “Татар өе” мини-музеенда татар халкының, әби-бабаларыбызның, безгә мирас булып калган борынгы әйберләр тупланган. Бу мини-музейда сезне татар малае белән татар кызы каршы ала. Алар икесе дә татар халкының милли киемнәрен  кигәннәр. Мини музейда татарларның чәй табынына аерым игътибар бирелгән. Табын түренә самавыр һәм милли ризыклар куелган. Татар халкы сөтләп, баллап, каймак белән кайнар чәй эчәргә яраткан. Ашарга керосин салынган, керосинкаларда яки чуен белән мичтә пешергәннәр. Татар йортының диварлары, хатын-кызларыбызның үзләре чиккән тукыма сөлгеләре, кашакалары, карават, мендәр, өстәл япмалары, келәмнәр һәм тәрәзә пәрдәләре белән бизәлгән. Ә идәнгә тукылган келәмнәр җәелгән. Аларны каз канаты белән себереп чистартканнар.

Йорт уртасына зур сандык куелган. Сандык киемнәр кую өчен, әйберләрне саклау өчен генә түгел, ә җиһаз буларак та кулланылган, шуңа күрә өй эчендә берничә сандык куела торган булган. Урын-җир әйберләрен дә сандыкларга тутырып куя торган булганнар. Шулай ук, аларны балалар өчен ятак буларак та кулланганнар. Өлкәннәр үзләре чаршау белән бүленгән сәке өстендә йоклаганнар.

Татар халкында җиз савытлар да бик еш кулланылган. Мич кырына куелган җиз табакка, комганнан су агызып юынганнар. Татар халкы чисталыкны, пөхтәлекне бик тә яраткан.

**“Татар халкының яшәү рәвеше һәм көнкүреше”**

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар тирә-юньдәге чынбарлыкны эмоциональ кабул итә. Балада туган җиренә, торган урынга мәхәббәт хисләре уяна, туган иле белән горурлану хисләре туа. Балаларда татар халкының тарихын өйрәнү, көнкүреше, мәдәнияте, традицияләре белән танышу уен формасында аеруча уңышлы уза. Уеннарда балалар билгеле бер тарихи ситуацияләр белән яшиләр, көнкүрешне, яшәү рәвешен, һөнәрчелекне, халык сәнгатен өйрәнәләр. Уеннар аша, мәктәпкәчә яшьтәге балаларда киләчәккә - нигез салына. Туган халкының мәдәниятенә уңай, эмоциональ ныклы караш тәрбияләүдә дидактик уеннарның әһәмияте зур. Дидактик уеннар балаларны төрле авырлыкларны җиңеп чыгарга, дөрес һәм гадел, намуслы булырга өйрәтә. Нык ихтыяр көче үсти.

Балалар белән бу юнәлештә нәтиҗәле эшләү өчен балалар бакчасында “Татар өе” мини – музей кулланмасын эшләдем. Дидактик һәм рольле-сюжетлы уеннар вакытында тәрбиячеләргә шушы кулланманы кулланырга мөмкин.

Әлеге дидактик кулланма 3-7 яшьлек балалар индивидуаль, парлап яки төркемләп уйнау өчен ясалган. Бу уенның төп максаты әби-бабаларыбыздан калган йолаларны, гореф-гадәтләрне буыннан-буынга, балаларыбызга җиткерү, онытмау, аларның яшәеше белән таныштыру, туган халкына, теленә хөрмәт тәрбияләү. Элеккеге һәм хәзерге йортлар бизәлеше белән таныштыру, аларны чагыштыру, сүзлек запасын баету. Мәсәлән: ызба-йорт, ятак-сәке-карават, мич, җиһаз, табагач һ.б....

**“Татар өе” дидактик кулланмасы белән эшләгәндә кулланырга мөмкин булган уен вариантлары**

***<u>“Мич-ашатучы”</u>***




Балаларны йорт эче һәм андагы әйбер атамалары белән таныштыруны дәвам итү.

Мич-татар өендә иң зур роль уйнаган. Ул берничә төрле функция башкарган: мичтә ашарга пешергәннәр, кышка

җиләк-җимеш, гөмбә киптергәннәр, икмәк пешергәннәр, мич башында йоклаганнар, мич кырына җылыга утырып дәваланганнар, хәтта парлаганнар. Балаларны мич төзү үзенчәлекләре һәм мичче һөнәре белән танышытыру.

***“Әби сандыгы”***

Хатын-кыз һөнәрләре, кул эшләнмәләре, чигелгән салфеткалар, кашакалар, япмалар, тәрәзә пәрдәләре, сөлгеләр, татар халкының костюмнары, өй бизәкләре белән таныштыру.

Татар халкының милли баш, өс һәм аяк киеме ничек аталганын искә төшерү. Татар халык һөнәрчелеге һәм аларның көнкүреше турында белемнәрен ныгыту. Борынгы предметларга хөрмәт һәм сакчыл караш тәрбияләү. Балалар белән “Түбәтәй” уенын уйнау.

***“Самавыр янында утырыйк”***

Балаларны өйдәге савыт-саба атамалары белән таныштыруны дәвам итү. Самавырда ничек су кайнатканнарын аңлату. Балаларның сүзлек запасын баету: самавар, күмер, кайный. Балалар белән“Самавыр”татар халык уенын уйнау. Фикерләү сәләтен үстерү. Бер-берсенә карата җылы караш, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү.

***“Хуҗабикә ярдәмчеләре”***

Балаларны авыл йортындагы “кич утыру” йоласы белән таныштыру. Бу утырмага әзерлек турында күзаллау булдыру (йортны җыештыру һәм бәйрәмчә бизәү). Балаларны утырмадагы хатын-кызлар һәм ир-атларның эшләре белән таныштыру: хатын-кызлар чигү чикәннәр, тукыма тукыганнар, бәйләгәннәр, жеп эрләгәннәр. Ир-атлар чабата үргәннәр, агачтан савыт-саба кисеп ясаганнар. Балаларны фольклор белән таныштыруны дәвам итү, тарих белән кызыксыну уяту.

Уеннар: “Йомгакны кем тизрәк урый”, “Капкалы”, “Әбиемнең сандыгында ниләр бар?”

***“Татар халык курчагы“***

Традицион татар курчагы йон җепләрдән ясалган, күлмәкләрен шәригать кануннарына нигезләнеп теккәннәр.

Татар һәм башкорт халыкларында курчакларга исемнәр бирмәгәннәр, йөз чалымнарын ясамаганнар. Бу курчакларга йөз ясамау борынгы традицияләрне исәпкә алып эшләнелгән. Барлык татар-башкорт курчаклары бала үзенең хыялын эшкә җигеп һәм хыялындагы уенчыкны үзе ясый алсын өчен эшләнелгән.Элек рус авылларында боларга охшаш, йөзсез курчаклар-скруткалар ясаганнар.





Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча 1 нче балалар бакчасы" муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе тәрбиячесе

**Камалиева Гөлназ Рәис кызы**

***“Тылсымлы сандык”***

*“Бала чакта алган тәрбияне*

*сонрак бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас”.*

*Р. Фәхретдин*



**Белем бирү өлкәләре**:

- танып белү үсеше,
- социаль-коммуникатив үсеш,
- сөйләм үсеше
- сәнгати-эстетик үсеш.

**Максатчан төркем:** мәктәпкәчә яшьтәге балалар (5-7 яшь).

**Дидактик уен әсбабының актуальлеге**

*Бөек татар халкын, бай тарихын,*
*Гасырлардан килгән мирасын,*
*Калдырасы иде яшь буынга,*
*Һәрбер кеше барлап соклансын!*
*Гореф- гадәтләрне, җыр- биюне,*
*Сабан туен, Җыен, Нәүрүзен,*
*Белсен иде җирдә һәрбер бала*
*Әнисеннән алган үз телен!*
*Эльмира Зарипова*

Әлеге тема бүгенге көндә бик актуаль, чөнки үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк. Моның өчен һәр бала үз гаиләсенең, туган җиренең тарихын белергә, шуның аша халыкка якынаерга тиеш. Һәр милләт үз җирлегендә барлыкка килгән һәм буыннан-буынга күчә торган гореф-гадәтләрен, кешеләрнең яшәү рәвешләрен, үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен, карашларын, зәвыкларын сакларга омтылган.

Тормыш–көнкүрештә билгеле бер йолалар үтәү, гореф-гадәтләрне тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү барлык милләтләргә дә хас. Ул әлеге милләт мәдәниятенең мөһим бер өлеше булып исәпләнә. Гореф-гадәтләр борын-борыннан халык тарафыннан үтәлеп килә торган бәйрәмнәрне, йолаларны үз эченә ала. Билгеле бер йолаларның үтәлеп килүе җәмгыятьне дә тотрыклы итә, алардан башка халык тулы кыйммәтле тормыш белән яши алмый.
Кыскасы, безнең максатыбыз туган телебезне, тарихыбызны, рухи байлыкларыбызны, гореф-гадәтләребезне өйрәнеп, буыннар арасында ныклы бәйләнеш булдыру. Шушы бай мирасны балаларыбызга тапшырып калдыру.

Татарстан халыкларының үзара дус, тату яшәве – бөтендөнья өчен толерантлык үрнәге булып торуын да күрсәтә. Халыклар арасында дуслык бәйләнешләрен ныгытуда бәйрәмнәрнең роле зур, чөнки алар аша халыклар бер-берсенең мәдәниятен, яшәү рәвешен, гореф-гадәте, йолаларын өйрәнә һәм шулар аша бер-берсенә хөрмәт тәрбияли, үз итә, дуслыгын ныгыта. Бүгенге көндә милли бәйрәмнәребезне, йола, гореф-гадәтләребез яңадан торгызылып, яңартылып, заман төсмерләре биреп үткәрелә башлады. Аларны балалар белә, хөрмәт итә икән милләт яши, милләт яшәгәч, тел яши, ягъни тормыш дәвам итә.

**Максат:**

Балаларны милли-мәдәни рухта тәрбияләгәндә Идел буе халыкларының электән килгән гореф-гадәтләре , мәдәнияте белән кызыксынучы югары әхлаклы, һәрьяклап үсеш алган, иҗади шәхес тәрбияләү өчен шартлар тудыру.

**Бурычлар:**

- тәрбия традицияләренә нигезләнеп Идел буе халыкларының ел фасылларына бәйле гореф- гадәтләрен, бәйрәмнәрен белү, алар белән кызыксынуларын үстереп балаларга эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү;
- Идел буе халыкларының милли бәйрәмнәре, йола уеннары, гореф-гадәтләре аша балаларның аралашу, коммуникатив осталыгын, сөйләм телен үстерү.
- Төрле милләт халыкларына карата хөрмәт һәм ихтирам хисләре тәрбияләү.

**Дидактик уен әсбабына аннотация**

“Тылсымлы сандык” дидактик әсбабы белем бирү, үстерелешле һәм тәрбияви бурычларны үз эченә алган. Дидактик әһәмияте – баланы Идел буе халыкларының ел фасыллары белән бәйләнешле йола- бәйрәмнәре белән таныштыра. Әлеге уенда Арча районы җирлегендә гомер итүче татар, рус һәм мари халыкларының милли бәйрәмнәре урын алды (татар халык бәйрәмнәре –

Сабантуй, Нәүрүз, рус халык бәйрәме – май чабу, мари халык бәйрәме – Пеледыш Пайрем (Чәчәкләр бәйрәме). Эстетик әһәмияте – балада эстетик зәвык тәрбияләүдә мөһим роль уйный: сәнгать дөньясына, иҗадилыкка тарта, матурлыкны күрә белергә өйрәтә.

Кул чукларының моторикасын үстерергә дә ярдәм итә. Ябыштыручы вак элементлар ярдәмендә вак моторика камилләшә.

Әлеге дидактик әсбабның аерым бер үзенчәлеге булып аның күптөрле функцияле булуы, материалларның балалар өчен куркынычсыз булуында. Курчаклар йомшак тукымадан һәм фетрдан ясалган. Аларны юып, чистартып була. Балаларның теләге буенча уенчыклар, атрибутлар тулыландырылырга мөмкин (киләчәктә калган милләт халыкларының милли йола-бәйрәмнәрен эшләп кую планга кертелгән).

Дидактик әсбабны төрле белем бирү өлкәләрендә, шөгыльләрдә, шәхси эш вакытында, әти-әниләр белән өйдә дә, балаларның мөстәкыйль эшчәнлегендә, режим вакытларында да кулланып була. Сюрприз моменты өчен менә дигән атрибут булып тора.

Әлеге дидактик әсбабның куллану мөмкинлекләре дә күптөрле булырга мөмкин. Мәсәлән, балаларның мөстәкыйль уеннары вакытында аңа төркемдә аерым бер почмак табырга мөмкин, өстәл уены итеп кулланырга, яки күрше группага балалар белән тамаша күрсәтергә алып кереп була.

Ел фасыллары темаларын кабатлап, искә төшерү, ныгыту өчен дә бик уңайлы материал булып тора.

Дидактик әсбабтагы уеннарны, балаларның яшь үзенчәлекләренә карап, катлауландыру мөмкинчелеге дә бар.

**Төп дидактик уен “Милли бәйрәмнәр”**

*Максат:* балаларны Идел буе халыклары бәйрәмнәре белән таныштыруны дәвам итү,  халыкларның гореф – гадәтләренә, йолаларына хөрмәт, ихтирам тәрбияләү.

*Уен барышы*: балаларга ике янчык тәкъдим ителә. Берсендә ел фасыллары рәсемнәре, ә икенчесендә татар, рус һәм мари халкының милли орнамент рәсемнәре. Балалар ике янчыктан да берешәр рәсем тартып чыгаралар. Мәсәлән, мари халык милли орнаменты һәм җәй ел фасылы. Балаларга сорау бирелә:

- Җәй көне мари халкы нинди бәйрәм уздыра. (Чәчәкләр бәйрәме)
- Бу бәйрәм нәрсәне аңлата? (Яхшы уңыш җыеп алуны)

Балаларга сандыкның беренче өлешенә җәй ел фасылын төзергә, ә  сандыкның икенче өлешенә (аланлыкка) Чәчәкләр бәйрәмен ясарга тәкъдим ителә. Балалар тиешле атрибутлар, курчаклар ярдәмендә бәйрәмне төзеп күрсәтәләр. Милли уеннар, милли киемнәр, милли ашлар турында да сөйләргә мөмкин.

**Дидактик уен төрләре**

*Дидактик уен* **« Кайсы милләттән?»**

*Максат:* Идел буенда урнашкан республикалар һәм халкы белән таныштыру; Идел буе халыкларының милли киемнәре, гореф-гадәтләре турында мәгълүмәт бирү; сүз байлылыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

*Уен барышы:* балаларга төрле милләт киемнәреннән (безнең очракта – татар, рус, мари) курчаклар күрсәтелә. Балалар аларның кайсы милләттән икәнен танып белеп, кием өлешләрен атарга тиеш.

*Дидактик уен* **: “Ел фасыллары”**

*Максат:* балаларны ел фасыллары белән таныштыруны дәвам итү, табигать белән таныштыру. Туган як табигатенә сакчыл караш тәрбияләү. Балаларның сүзлек байлыгын арттыру.

*Уен барышы:* балалар янчыктан бер ел фасылы рәсемен тартып чыгаралар. Шул рәсем буенча ел фасылларының үзенчәлекләрен атыйлар һәм сандыкның алгы өлешенә ябыштыргычлар ярдәмендә өлешләрдән ел фасылы күренешен ясыйлар.

*Дидактик уен:* **“Серле янчык”**

*Максат*: предметларны бер-берсеннән аера белергә, чагыштыра белергә өйрәтү.Сүз байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләмне камилләштерү.

*Уен барышы:* балаларга серле янчыктан төрле предмет рәсемнәре алырга тәкъдим итеһлә (ел фасыллары, милли ризыклар һ.б.). Рәсемнәрне берләштерүче сүзне әйтеп, сыйфатлап әйтергә кирәк.

*Дидактик уен*: **«Милли киемнәре калейдоскобы»**

*Максат:* Идел буе халыкларының милли киемнәре турында белемнәрен ныгыту; сүз байлылыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

*Уен барышы:* балаларга төрле милләт киемнәреннән (безнең очракта – татар, рус, мари) курчаклар күрсәтелә. Балалар аларның кайсы милләттән икәнен танып белеп, кием өлешләрен атарга тиеш.

*Дидактик уен:* **“Милли ризыклар”**

Максат: татар халык ризыклары белән таныштырып китү. Камырдан пешкән ризыкларны бәйрәмнәрдә куллану. Җөмләләрне дөрес төзи белү.

*Уен барышы:* балаларга төрле милләт ризыклары (безнең очракта – татар, рус, мари) күрсәтелә. Балалар аларның кайсы милләтнең милли ризыгы икәнлеген икәнен танып белергә тиеш.

*Дидактик уен:* **“Бәйрәмгә өстәл әзерлибез”**

*Максат:* Уйлау-фикерләү сәләтен үстерү, зәвык тәрбияләү. Предметлы рәсемнәрне кирәгенчә сайлап алырга, аларга туры килүчеләрен дөрес итеп урнаштырырга өйрәтү.

*Уен барышы:* балаларның алдына төрле милли орнаментлы ашъяулыклар һәм милли ризыклар куелган. Балаларның төп бурычы милли ризыкларны тиешле

төрдәге  ашъяулыкларга туры китереп урнаштыру.



Сандыкның эчке ягы ике өлештән тора. Өске ягында йорт күренеше. Аның тирәсен ел фасылларына туры китереп,  табигать күренешләрен алыштырып була (предметлы рәсемнәр фетрдан ясалган, ябыштыргычлар ярдәмендә алыштырыла). Сандыкның икенче өлеше – аланлык, анда милли бәйрәм күренешләрен төзеп була.





**Өч төрле милләтне  чагылдырган курчаклар тукымадан ясалган.**





**Бәйрәмнәр өчен кирәк булган атрибутлар тукымалардан, агач материалыннан, фетрдан ясалган.**





**Нәүрүз бәйрәме күренеше.** **Май чабу (Масленица) бәйрәме күренеше.**



**Сабантуй бәйрәме күренеше**

МБМББҮ “Мамадыш шәһәре 4нче “Әкият” балалар бакчасы”
**Зиатдинова Фирдәния Хаҗип кызы,**
**Хисамова Алсу Марат кызы**

***«Айсылу белән Аленага кунакка”***
***интерактив мультимедия уены***
**(5-8 яшьлек балалар өчен татар һәм рус телләрендә тавыш яздыру ысулы белән эшләнгән дидактик уен)**

Әлеге дидактик уенның максаты - татар, рус халыкларының мәдәнияте турында күзаллауларны киңәйтү.

Уен төркем һәм шәхси дәресләр өчен билгеләнгән. Балалар бакчасы тәрбиячеләре тарафыннан гына түгел, ә башлангыч мәктәптә, өй шартларында һәм түгәрәк җитәкчеләре тарафыннан да кулланыла ала.

Татар һәм рус телләрендә яңгыраган дидактик уен татар һәм рус милләте мәдәнияте һәм гореф гадәтләре, көнкүреше һәм тарихи кыйммәтләре турында күзаллауны киңәйтергә ярдәм итәчәк.

Бала киемнәре, уенчыклар, орнаментлар, көнкүреш кирәк-яраклары, әкиятләр,музыкаль инструментлар, язучы-шагыйрьләр, милли ризыклар турында белемнәрен ныгыта.

Уен ике бүлектән тора. Һәр бүлектә түбәндәге темалар карала:

1. Татар һәм рус өе (бүлмәләр милли бизәлештә)
2. Татар һәм рус милли киемнәре .
3. Татар һәм рус милли аяк киемнәре.
4. Татар һәм рус милли баш киемнәре
5. Татар һәм рус милли ризыклары.
6. Татар һәм рус милли уенчыклар
7. Татар һәм рус милли орнаменты.
8. Татар һәм рус милли музыкаль инструментлары.
9. Татар һәм рус халык язучы-шагыйрьләре.
10. Әкиятләр.

**Беренче бүлек “Айсылу өе”.**



Татар милли киеменнән кыз кунакка чакыра. Өй эче милли бизәлгән, көнкүреш җиһазлары урнашкан. Курсор белән рәсемдәге бер предметка баскач (читек ,  сандык, гармун калфак , сөлге , Г.Тукай портреты , бэлеш , курчак ), уен барлыкка килә.

Мәсәлән: Гармунга баскач- музыкаль инструментла барлыкка килә Бала алдан инструментларның аталышын әйтә, кабаттан уен (“Нәрсә артык?”, “Тиешлесен тап”, “Формасы буенча тап”, “Тавышы буенча таны” һ.б.) тәкъдим ителә, биремнәр эшли.

«Читек»кә  басалар һәм тартма яисә киштәдә аяк киемнәре барлыкка килә “Парын тап”, “Нәрсә артык?” һ.б. уеннар тәкъдим ителә.

Бүлекләрдә икенче бүлеккә күчү өчен уң якта аскы өлештә сары эш кнопкалар кулланыла.

Тыңлар өчен микрофон тамгасына басарга кирәк. Сайланган билгеле уен тәмамлангач башбиткә “Айсылу өе”нә күчеп, икенче төр уенны сайлар өчен предметка курсорны юнәлтергә. Предметка баскач яңа уен ачыла.

**<u>Икенче бүлек “Алена өе”</u>**

<u>Для перехода к второму блоку («Дом Алены») нужно на картине «Дом Айсылу» нажать на кнопку со стрелкой с правой стороны в углу.</u>



Девочка в русской национальной одежде приглашает в русскую избу и предлагает игры. Нажимая на предметы (сундук , валенки ,

блины, балалайка , портрет А.Пушкина , кукла , кокошник , скатерть на столе ) появляются игры. В каждом виде по несколько видов игры. Например: Нажимаем на блинчики, выходят игры, такие как «Накрой стол из русских национальных блюд», «Дополни ряд»; нажимаем на скатерть - появляется игра по орнаменту русского народа такие как : «Дополни рисунок», «Раздели на группы» и.т.д. Ребенок называет, потом следующим слайдом появляется правильный рисунок - ответ и звук аплодисментов.

**Варианты игр:**

-«Что лишний?»

-«Подбери нужное»

-«Заполни квадраты»

- «Распредели по полкам»

- «Выбери игрушки»

- «Собери нужную одежду в сундук»

- «Собери татарскую национальную одежду»

- «Собери русскую национальную одежду»

- «Определи по форме»

- «Подбери головной убор»

-«Одень куклу»

-«Дополни ряд»

-«Найди вторую пару»

-«Дополни узоры»

-«Угадай узоры»

-«Раздели по группам»

-«Накрой на стол»

-«Угадай сказку»

-«Назови писателя»

-«Назови поэта»

- «Угадай автора сказки»

- « Какого предмета  не хватает?»

- «Угадай  инструмент по звуку»

- «Найди ошибку»  и т.д.

Мамадыш шәһәре 4 нче “Әкият” балалар бакчасы

югары квал. категорияле тәрбиячесе

**Мөхәммәтҗанова Резедә Сәлимҗан кызы**

***«Милләтләр дуслыгы» дидактик уены***




Әлеге дидактик уенның максаты - татар, рус, чуаш, башкорт, мордва милләтле халыкларның мәдәнияте турында күзаллауларны киңәйтү.

Уен төркем һәм шәхси дәресләр өчен билгеләнгән. Балалар бакчасы тәрбиячеләре тарафыннан гына түгел, ә башлангыч мәктәптә, өй шартларында һәм түгәрәк җитәкчеләре тарафыннан да кулланыла ала.

Татар һәм рус телләрендә яңгыраган дидактик уен татар һәм рус милләтле халыкларның мәдәнияте һәм традицияләре, мәдәни һәм тарихи кыйммәтләргә кушылу турында күзаллауны киңәйтергә ярдәм итәчәк. Бала таныша һәм кием һәм аяк киеме, баш киеме, уенчыклар, орнаментлар турында белемнәрен ныгыта.

Өйрәнелгән телдә сүз запасын арттыра, дөрес әйтелешне ныгыта һәм уен барышында бу белемнәрне активлаштыра. Уен предметларны аерым

элементларга бүлүгә генә түгел, ә аларның төп үзлеген бәяләргә, элементларның үзара нисбәтен билгеләргә, аларның мәгънәсен аңларга ярдәм итә. Уен комплекты түбәндәге темалардан тора:

1. Милли костюм буенча пар табыгыз.( уенда тәкъдим ителә: татар, рус, мордва һәм башкорт милли костюмнарындагы малай белән кызны парларга берләштерергә)

2. Кирәкле рәсемне сайлагыз. (рәсемне контур буенча сайларга тәкъдим ителә)

3. Татар милли киемнәрен җыегыз. (сандыкка татар милли киемен генә сайларга тәкъдим ителә)

4. Рус милли киемнәрен җыегыз (сандыкка рус милли киемнәрен генә сайларга тәкъдим ителә)

5. Татар милли орнаменты. (татар орнаментының кирәкле өлешен табып, үрнәкне тулысынча җыярга)

6. Рус милли орнаменты. (рус орнаментының кирәкле өлешен табу һәм үрнәкне тулысынча җыю)

7. Чуваш милли орнаменты. (чуаш орнаментының кирәкле өлешен табу һәм үрнәкне тулысынча җыю)

8. Башкорт милли орнаменты. (башкорт орнаментының кирәкле өлешен табып, үрнәкне тулысынча җыярга)

9. Мари милли орнаменты. (Мари орнаментының кирәкле өлешен табу һәм үрнәкне тулысынча җыю)

10. Татар һәм рус милли курчаклары. (курчакларны киштәләргә куегыз)

11. Баш киемен сайлагыз. (Рус кызына баш киеме сайларга)

12. "Нәрсә артык?"(Татар һәм рус баш киемнәре тәкъдим ителә, артык баш киеме сайларга кирәк)


13. "Киштәләргә урнаштыр". (тәкъдим ителгән дүрт әйбердән баш киемен сайлап, буш киштәләргә урнаштырырга кирәк).

14. "Икенче парны табыгыз." (татар һәм рус аяк киеме табарга тәкъдим ителә).

Җаваплар дөрес булган очракта рәсем автомат рәвештә тиешле урынга күчә.

Бала ялгыш җавап биргән очракта рәсемнәр урында кала



Татарстан республикасы Биектау муниципальрайонының
“Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы”
мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет
учреждениесе музыка җитәкчесе
**Сафиуллина Лилия Альберт кызы**

***«Татар халкының җырлы-биюле уеннары» китапчыгы***

**Уенның максаты:**

Балаларның туган телне өйрәнүдәге белемнәрен камилләштерү.

**Бурычлар:**

**Белем бирү:** татар халкының милли  уеннарын өйрәнү, халык бәйрәмнәре турында балаларның белемнәрен тирәнәйтү, уенда катнашу, бәйрәм шатлыгын башкалар белән уртаклашасы килү теләге булдыру;

**Үстерелешле:** балаларның логик фикерләвен, хәтерен,  үстерү, кул чукларын ныгыту;

**Тәрбия бирү:** милли һәм эстетик тәрбия бирү, үз халкыңа хөрмәт, ярату хисләре уяту;

**Социаль-коммуникатив:**сөйләм телен үстерү, балаларның үзара аралашуына, дустанә мөнәсәбәттә булуына, үзара һәм олы кеше белән киңәшеп, ярдәмләшеп уйнавына ирешү.

**Уен 4-7 яшьлек балалар өчен әзерләнде**

**Уен алдыннан башкарылган эш**: татар халкының җырлы- биюле уеннары, киемнәре, бәйрәмнәре турында әңгәмәләр алып бару, рәсемнәр карау, татар балалар фольклоры белән танышу, уеннарын өйрәнү.

**Кулланылган җиһазлар:** фетердан тегелгән китапчык, милли киемдәге фетрдан эшләнгән кнопка ярдәмендә беркетелгән егет һәм кыз курчаклар; китапта 8 милли җырлы-биюле уеннары ясалган.

**Уен барышы:**

Тәрбияче яки музыка җитәкчесе китапны келәмгә яки өстәлгә куя, үз янына түгәрәккә балаларны утырта. Иң башта балалар белән милли бәйрәмнәр: сабантуй, нардуган, карга боткасы, сөмбелә турында әңгәмә оештыра. Аннары татар халкының җырлы- биюле уеннары турында аңлатыла. Балалар китап битләрендәге курчактагы киемнең исемен әйтеп “малай” һәм “кыз” курчакның өстендәге күлмәк, алъяпкыч, читек, чалбар,камзул, түбәтәй, калфак, яулыкны өйрәнәләр, киемнәрнең бизәлешенә дә игътибар итәләр. Аннан соң бергәләп уеннарны карыйлар, курчаклар ярдәмендә өйрәнәләр. Тәрбияче яки музыка җитәкчесе уенны аңлаткач бергәләп әлеге татар халык җырлы-биюле уеннары уйнатыла.Китаптагы уеннарны карап балалар уйнарга теләгән уеннарын сайлыйлар.Балалар уеннарның сүзләрен өйрәнгәннән соң, курчакларны куеп, үзләре түгәрәктә җырлап, биеп башкаралар.

**“Наза”** балалар курчакларны алып парлаштырып, бер-бер артлы тезәләр. Бер курчак парсыз, ул уенчылыр каршысына чыгып баса. Балалар, җырлый-җырлый, баскан җирдә аякларын-кулларын хәрәкәтләндерәләр:

*Наза дигән кыз баланың*

*Бөрлегәне түгелгән;*

*"Наза" дигән уенны без*

*Уйныйбыз чын күңелдән.*

*Кушымта:*

*Наза, наза,*

*Наза матур кыз бала.*

*Наза тырыш, уңган бала,*

*Зирәк, акыллы бала.*

Кушымтаны җырлаганда, парсыз курчак каршыдагы уенчылар арасыннан биеп үтә,үзенә пар сайлый, һәм алар икенче башка барып басалар. Парсыз калган курчак уенны дәвам итә.

**“Айгыйдел”**

Балалар, курчакларны парлаштырып , бер- бер артлы басалар. Бер курчак парсыз кала, ул алга чыга. Кушымтаны җырлаганда, балалар курчакларының кулларын бер-берсенә тотынган килеш өскә күтәрәләр (күпер ясыйлар). Шул вакытта парсыз курчак күпер аркылы чыга һәм үзенә ошаган баланы сайлый. Уен дәвам итә.

*Агыйделнең суларында*

*Ак чиләгем күмелде.*

*Әйдә, дустым, безнең якка*

*Безнең яклар күңелле.*

*Кушымта:*

*Зәңгәр чәчәк жыя-җыя,*

*Зәңгәрләттем кулымны.*

*Бергә-бергә уйныйк әле,*

*Бир дускаем, кулыңны.*

**“Яулык алыш”**

Бу уен күбесенчә кыз курчаклар тарафыннан уйнала. Кызлар бер урынга түгәрәкләнеп басалар һәм бер кеше яулык җыючы итеп сайлап куялар. Ул уртага чыгып баса да:

*Талым, талым, талчыбык,*

*Уртасында бал чыбык,*

*Ал яулык, гөл яулык,*

*Бир син миңа бер яулык, -*

дип, такмаклый-такмаклый, барлык кызлардан да яулык җыеп чыга. Җыеп бетергәч, яулык хуҗаларына берәм-берәм җәза бирелә. Җәзадан соң уен тагын яңадан башлана.

**“Башмакчы”**

Балалар курчакларны түгәрәк ясап бастырылар. Санамыш ярдәмендә башмакчы сайлана.Ул, кулына бер башмак алып уртага баса.

Җырлый:

*Төрле һөнәр беләбез,*

*Матур итеп тегәбез;*

*Башмак башын чигәбез.*

Түгәрәк эчендәге курчак башмагын күрсәтеп җырлый:

*Кирәмиме, алмыйсыз,*

*Әллә киеп карыйсыз?*

Балалар аңа каршы, җыр җырлыйлар:

*Әй, башмакчы, башмакчы,*

*Үзең оста такмакчы.*

*Син җырлама такмагын,*

*Бир кияргә башмагын.*

Дип җырлап бетергәч, башмакчы ике курчак арасына башмагын куя һәм аларның иңнәренә кагыла. Ике курчак ике якка түгәрәк тирәли йөгереп китә.Кем беренче килеп җитә, шул башмакчы була. Уен яңадан башлана

**“Капкалы”**

курчакларны парлап җитәкләшеп зур түгәрәк ясап басалар.Парлар җитәклшкән килеш кулларын өскә күтәреп капка ясап торалар.Көй башлануга арадан бер пар үзе теләгән капкага керә, алар урынына баса, әлеге пар икенче капкага бара.Көй туктауга капкага керергә өлгерми калган пар җәза ала.

**“Бу дустың белән күреш”**

Балалар курчакларны алып, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар Һәм җырның эчтәлегенә әйтелгән хәрәкәтләрне ясап, "'Сандугач-күгәрчен " көенә җырлап әйләнәләр:

*Аякларың тыпырдат,*

*Куларыңны чәбәклә,*

*Бер монда, бер монда,*

*Кыен эш түгел бер дә.*
*Башың аска иеп ал,*
*Кул бармагың янап ал,*
*Бер монда, бер монда,*
*Кыен эш түгел бер дә.*
*Бу дустың белән күреш,*
*Бу дустың белән күреш,*
*Йә иптәш, йә, әйлән,*
*Бик кыен түгел бу эш.*

Жырга туры килгән хәрәкәтәр эшлиләр Уенда 5-6 бала катнаша ала. **“Нардуган”.**

Бер бала курсакны алып уртага чыгара. Башка балалар курчаклары белән аның тирәсендә бер түгәрәк ясап, кулга-кул тотынышып, нардуган җырын җырлап әйләнәләр:

*Син уртада, без кырыйда,*
*Әйләнәбез, нардуган,*
*Син нишләсең, ни кылансаң,*
*Мин дә шуны булдырам!*

Җыр беткәндә, уртадагы бала нинди дә булса бер хәрәкәт ясый, түгәрәктәге балалар шул хәрәкәтне кабатларга тиешләр. Кем шуны булдыра алмый, уртадагы бала курчагы белән үз урынына аны чыгара да, уен баштагыча дәвам итә.

Татарстан Республикасы Биектау районы “Сандугач” катнаш

төрдәге балалар бакчасы  мәктәпкәчә белем бирү муниципаль

бюджет учреждениесе татар теле тәрбиячесе

Шәйдуллина Ләйсән Рәфкат кызы

***“Тылсымлы божра”***



**“Тылсымлы божра” уены**

**Уенның максаты:**

Сөйләм телен үстерү. Татар халкының уеннары белән тирәнтен таныштыру, балаларда үз халкы белән горурлану хисе тәрбияләү.

**Бурычлар:** Милли тәрбия бирү, татар хакының милли киемнәре, ризыклары һәм милли бизәкләрен  өйрәтү.

Уен 5-7 яшьлек балалар  өчен.

**Әзерлек эше:** милли киемнәр, милли ашлар,бәйрәмнәр турында әңгәмәләр алып бару.

**Җиһазлар:** фанерадан ясалган божра, төрле биремнәр урнаштырылган 8 конверт.

**Уенның барышы:**

Тәрбияче фанерадан ясалган божраны өстәлгә куя,үз янына түгәрәккә балаларны бастыра.Тәрбияче иң элек божрага,аның бизәлешенә игътибар

юнәлтә. Боҗрага матур милли бизәкләр төшерелгән. Татар халкының милли бәйрәмнәренә, гореф гадәтләренә ,уен-йолаларына, музыка уен коралларына игътибар итик әле.

Татар халкы элек-электән үзенә генә хас булган өс киемнәре, милли ашлары,бизәнү әйберләре белән дан тоткан.

Эшчәнлек барышы:

Кереш өлеш.

Тәрбияче: Хәерле иртә,балалар!

Балалар: Хәерле иртә!

Тәрбияче: Кәефләрегез ничек?

Балалар: Әйбәт, рәхмәт!

Тәрбияче : Балалар, мин сезне бүген “Тылсымлы боҗра” уенын уйнарга чакырам. Ни өчен тылсымлы боҗра дип атала соң бу уен? Чөнки аның һәрбер өлешендә биремнәр бар.Нинди биремнәр икәнен беләсегез киләме?

Бергәләшеп без басыйк

Матур түгәрәк ясыйк

Берәр санамыш әйтеп

Уеныбызны башлыйк

Әке бәке кыек сәке, эремчек.Син калып тор, ә син чык.

Без хәзер барабанны әйләндерәбез,барабанның угы туктаган кесәдән биремне алабыз һәм укыйбыз.

**1.“Тизәйткечләр” уены.**

Уенның уйнау тәртибе:

Балалар белән тизәйткечләрне искә төшерү.

1. Мич башында биш мәче,биш мәченең биш башы.Биш мәченең биш башына ишелмәсен мич ташы.
2. Кара карга кунган карга, карга кунган ак карга.

**2 . “Милли киемнәргә бизәк төшер”уены**

Минем сезне иң киң кулланыла торган бизәкләр белән таныштырасым килә.

Тюльпан-лалә

Лист-яфрак

Колокольчик-кыңгырау

Гвоздика-канәфер чәчәге

Трехлистник- өч яфрак

Пион-чалмабаш

Шиповник-гөлҗимеш

Орнаментта ешрак һәм бигрәк тә яратып кулланыла торган ул лалә һәм кыңгырау чәчәге.Шулай ук чәчәк аткан һәм чәчәккә бөреләнгән килеш чалмабаш һәм канәфер чәчәгенең мотивы зур урын алып тора.Бизәкләрдә, бигрәк тә чигүдә, яфрак мотивларының формалары, төсмерләре күптөрле булуы гаҗәпкә калдыра.Әйдәгез алъяпкыч,түбәтәй, калфакларга бизәкләр төшерик әле.

**3. “Милли ашлар”**

Татар халкы элек-электән аш-су әзерләргә оста булган.Халык бик борынгы заманнардан үк иген иккән, шуңа күрә күбрәк арыш, бодай онынан төрле тәмле ризыклар пешергәннәр.Балалар, ә сез нинди татар халык ашларын беләсез? Әйдәгез бергәләп милли ризыкларны атап китик әле.

(Кыстыбый, өчпочмак,чәк-чәк,калҗа,гөбәдия)

Өсте такта, асты такта, уртасында боламык (Кыстыбый)

Эче өрелгән, якасы бөрелгән, сырлы кәләпүш кигән, табын түренә менгән (Бәлеш)

Тап табышмак: табага ябышмак (Коймак)

**4 . Татар халык уены “Зәңгәр чәчәк”**

Уйнау тәртибе

Балалар, кулга кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар.Бер бала чигүле кечкенә мендәр тотып,уртага чыгып баса.Балалар түгәрәк буенча җырлап әйләнәләр:

Юл читендә зәңгәр чәчәк
Якты нурлар тарата.
Безнең кызлар һәм малайлар
Зәңгәр чәчәк ярата.

Туктап биеп-җырлап торалар,ә уртадагы бала, мендәр тотып,түгәрәк буенча биеп йөри.

Якын дуслар арасыннан
Берсен сайлап ал әле.
Тезләнергә ипле булыр-
Мендәреңне сал әле.

Мендәр тоткан бала мендәрен бер бала алдына куя һәм, аңа тезләнеп, кулын бирә.Ул бала аның тирәли әйләнә, башкалар кул чабып торалар.Уен алга таба шулай дәвам итә.

**5.“ Мәкальләрне дәвам ит” уены**

Мәкальләр сөйләмне матур, тәэсирле итәләр һәм һәрвакыт үгет-нәсыйхәт, киңәш бирү максаты белән әйтеләләр.  Тәрбияче мәкальне  әйтә, ә балалар дәвам итергә тиешләр.

Кош - канаты белән, гаилә татулыгы белән көчле
Балалы кеше- бай кеше
Гаилә-бәхет ачкычы
Илнең күрке-тынычлык
Эш беткәч-уйнарга  да ярый
Икмәк- тормыш нигезе

**6. “Курчакны милли киемнәргә киендер”**

Максат: Милли киемнәр турында белемнәрен камилләштерү.

Уен барышы: Уенда 8 бала катнаша ала. Балаларга кәгазьдән ясалган малай һәм кыз рәсеме бирелә.Өстәлдә төрле милли киемнәр рәсеме. Балалар үз теләкләре буенча малай һәм кыз курчакларын киендерәләр.

**7. "Әби өендә кунакта"**

Максат: Татар өенең эчке бизәлеше белән таныштыруны дәвам итү, матурлыкны күрә белергә өйрәтү.

Җиһазлау: Татар өенең эчке күренеше сурәтләнгән зур рәсем, шундагы предметларның кечерәйтелгән рәсемнәре(мич, кашага, пәрдә, сандык, каба, кисәү һ.б)

Уен барышы: Тәрбияче зур рәсем буенча әңгәмә үткәрә, татар өе бизәлешенең үзенчәлекләренә игътибарларын юнәлтә. Балалар рәсемгә карап җиһазлар, йорт кирәк яракларын атарга тиешләр.

**8 "Татар халык биюе**" Балалар белән бергә күмәк татар халык биюе биибез



Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе Иләбәр "Умырзая" балалар бакчасы тәрбиячесе

**Гайнетдинова Миләүшә Алимасовна**

***"Татар халкының милли киемнәре"***




**Максат:** Бертөсле предметларны табу һәм аларның төп билгеләрен аерып алу, атау. Балаларның игтибарын, хәтерен, фикерләү, сөйләм телен үстерү. Бертөсле, бертөрле төшенчәләрне ныгыту. Балаларны татар халкының милли киемнәре белән якыннан таныштыру.

**Бурычлар:** Милли киемнәргә кызыксыну уяту, үзләренә генә хас булган үзенчәлекләрен ачыклау, төсләрнең берләшүенә игътибар итү, парларын табу.

**Җиһазлар:** Фоамираннан ясалган татар халык киемнәре һәм аларны тутырып кую өчен тартма.

**Уенда катнашалар:** Икенче кечкенәләр төркеме балалары һәм тәрбияче.

**Уен барышы**. Бу уенда 2-3 бала катнаша ала. Уенда катнашучы балалар белән киемнәрне карау, татар милли орнаментлары төшерелгән киемнәрне атау. Киемнәрнең һәрберсен өстәлгә урнаштырып бару. Киемнәрне атап бетергәннән соң балаларга киемнәрнең парларын табарга тәкъдим итү. Балалар шул рәвешле төсләрен туры китереп, киемнәрнең исемнәрен атап киемнәрнең парларын табарга тиешләр.





Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы ш.т. Байлар Сабасы гомуми үсеш бирүче төрдәге Саба 1 нче “Шатлык” балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем биру муниципаль бюджет учреждениесе тәрбиячесе

**Кәримуллина Гөлназ Сөләйман кызы**

***Мастер-класс “Энәсез пэчворк” (Кинусайго)***

**Максат**: төсле тукымалар кулланып, пеноплэкстан панно ясау; татар халкының милли киемнәре турында мәгълүмат бирү; милли киемнәребездә чәчәк һәм үсемлек мотивлары, орнамет турында төшенчә бирү; кинусайга техникасының барлыкка килү тарихы белән таныштыру.

**Бурычлар:**

**Белем бирүче:** төсле тукыма кулланып, пенопласттан панно ясау технологиясен өйрәнү;

**Үстерелешле:** иҗади фантазияне һәм уйлау сәләтен, логик фикерләүне, сөйләм телен үстерү;

**Тәрбияви:** мөстәкыйльлек, тырышлык, иҗади сәнгатькә кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү; милли мәдәнияткә ихтирам һәм мәхәббәт хисе тәрбияләү.

**Эш формасы:** төркемгә бүленеп.

**Методлар һәм алымнар:** сөйләү, демонстрация, күрсәтү, аңлату.

**Алдан эшләнгән эш:** кинусайга техникасын кулланып эшләнгән паннолар, чыршы уенчыгы, китап тышлыгы, татар милли үрнәкләре ясалган китаплар карау.

**Сүзлек өстендә эш:** пеноплекс, трикотаж тукыма, тукыманы кертү, кимано, эскиз, кинусайго.

**Җиһазлар һәм җайланмалар:** әзер эш үрнәкләре, кайчы, канцелярия пычагы, пластилин өчен стек, пеноплекс, төсле тукыма кисәкләре.

**Тарату материалы:** рәсем шаблоннары, кайчы, пластилин өчен стек, төсле тукыма кисәкләре, җилем, пеноплекс.

**Мастер-класс мәктәпкә әзерлек төркеме балаларына исәпләнгән.**

**Эшчәнлек барышы**

**I. Кереш өлеш.**

Тәрбияче: Исәнмесез балалар! Бүгенге шөгыльдә без тукыма кисәкләреннән эшләү иҗаты технологияләренең берсе белән танышачакбыз – пеноплекста тукыма кисәкләреннән панно эшләү. Минем уйлавымча, бу кызыклы эш, тегү осталыгын да таләп итми. Сезгә үз фантазиягезне кулланып ташландык материалга икенче тормыш бирү өчен уникаль мөмкинлек бирелә.

Оста куллы уңган хуҗабикәләр йортында әкренләп тукыма кисәкләре, йон йомгаклар, төсле җепләр, тасмалар җыела. Барлык тукыма кисәкләрен диярлек кул эшләре өчен кулланырга мөмкин. Төргәккә төрү материалын, мәсәлән, пенопластны кабатланмас кул эше булдыруда да кулланып була. Остабикә өчен бу зур хәзинә, һәм ул аны саклый, вакыт узу белән бу төрле материалдан матур һәм файдалы әйберләр булдыра алачагын белә. Пенопласттан аппликация техникасының ата-бабасы булып Япон сәнгате тора.

**II. Төп өлеш**

Япониянең мәдәнияте, сәнгате, традицияләре безне хәзер дә гаҗәпләндерүдән һәм сокланудан туктамый.

Уйлап табучан һәм матурлыкка искиткеч сизгер японнар нәрсә генә уйлап тапмаганнар! Гаҗәеп күренешләрнең берсе – тукыма кисәкләреннән картиналар-кинусайга дип атала.

Кинусайга ул - агач такталарда тукыма кисәкләрен кулланып аппликация ясау техникасы. Традицион рәвештә, Япон рәссамнары эскиз ясыйлар һәм аны агач такталарга күчерәләр, аларда уемнар ясыйлар. Картиналар ясауда иске кимоно кисәкләре кулланылган. Хәзерге вакытта техниканы гадиләштерә алдылар-агач такталарны төзелеш материалы пенопласт яки пеноплекс белән

алыштырдылар һәм бу техниканы - “Энәсез пэчворк” дип атыйлар. Бу башта тузган иске кимоноларны "утильләштерү" ысулы булган. Кимононың ефәге-кыйммәтле һәм матур тукыма, аңа “икенче тормыш” уйлап табарга теләгәннәр. Һәм уйлап тапканнар!

**Әңгәмә. “Татар милли киемнәре”.**

– Балалар, сез нинди киемнәрне беләсез, әйдәгез, искә төшерик әле (Балалар җаваплары тыңлана)

- Аларны кемнәр кия? Кайда, кайчан кияләр? (Һәр сорауга җаваплар тыңлана)

– Ә сезнең калфак, түбәтәй, читек сүзләрен ишеткәнегез бармы?

– Кемнең калфак, түбәтәй, читек күргәне, аларны кигәне бар?

– Рәхмәт, балалар, сезнең күпләрегез алар белән таныш инде, аларны безнең бәйрәмнәрдә киеп чыгыш ясаганыгыз да бар. Ә кемнәр белми, рәсемнәргә карагыз, хәтерләп калыгыз. (Слайдлар карау)

– Балалар, **калфак, түбәтәй** – аларны татар халкының милли баш киемнәре дип, ә **читек**не милли аяк киеме дип йөртәләр.

– Аларның нинди үзенчәлекләрен әйтергә була? (Алар бик матур, аларны татарлар кия, аларда төрле рәсемнәр, бизәкләр ясалган һ.б.)

– Бу рәсемнәрне, бизәкләрне икенче төрле орнамент диләр. Татар халык киемнәрендә нинди орнаментлар (бизәкләр) күренә?

– Әйе, күп вакыт чәчәкләр чигелгән була. Милли бизәкләрдә нинди төс юк?

б) Татар милли киеме кигән кыз һәм малай курчакларны карау, аларның киемнәре турында фикер алышу.

– Малай белән кызның киеме нәрсә белән аерыла? (Җаваплар)

- Ә хәзер без сезнең белән кинусайга техникасын кулланып татар милли үрнәге төшерелгән паннолар ясарбыз. Агач такта урынына без пенопласт кулланыр-

быз. Панно әзерли башлаганчы, кайчы белән эшләгәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен искә төшереп алыйк.

**Кайчы белән эшләгәндә куркынычсызлык кагыйдәләре.**

Кискәндә кайчыны киң итеп ач.
Кайчыны биргәндә ябык килеш сабын алга каратып бир.
Эшләгәндә кайчыны өскә күтәрмә.
Кайчыны ачык килеш калдырма.
Ватык кайчы белән эшләмә.

**III.Эшне башкару тәртибе:**

1. Эскизны сайлыйбыз.

2. Теләсә нинди зурлыктагы пенопласт яки пеноплекс алабыз. Пенопластның калынлыгы 1,5 см-дан ким түгел.
3. Рәсемне пенопластка фломастер яки йомшак карандаш белән күчерәбез.
4. Канцелярия пычагы белән барлык сызыкларны җентекләп 5 мм. тирәнлектә кисеп чыгабыз.
5. Барлык сызыкларны җилем белән сылыйбыз.
6. Кирәкле төстәге һәм зурлыктагы тукыманы алабыз. Сузыла торган тукыма белән эшләү җиңелерәк.
7. Стек белән тукыманы рәсем сызыгына кертәбез.
8. Тукыманы кисеп кыстырабыз, аннары кайчы белән кисеп алабыз.
9. Артык тукыма кисәкләрен уемнарга яшерәбез.
10. Рәсемнең башка детальләре белән дә шулай эшлибез.
11. Эшне рамка белән тәмамлыйбыз.

**Ш.Нәтиҗә ясау.**

Тәрбияче: балалар, үз эшләрегезгә игътибар итегез, аларның һәрберсе үз тематикасын чагылдыра.Билгеле бер тематиканы сайлап, эшләрнең тулы сериясен булдырырга мөмкин. Әзер паннолар теләсә нинди интерьерны

бизәячәк, балалар бакчасы төркеме дисеңме яки бакчабызның залы яки үзегезнең өйне. Панно ясау иҗади эш булганлыктан, әзер эшегез һәркемдә үзен-чәлекле килеп чыккан. Өйдә ташлау материалыннан сез үзегез дә сувенирлар паннолар ясый аласыз, дусларыгызга бүләк итә аласыз, яисә бүлмәгезнең эчке ягын бизи аласыз, шулай ук төрле күргәзмәләрдә катнаша аласыз.

**Рефлексия**

Тәрбияче:

- әйтегез әле, балалар бүген сез нәрсә белдегез?

(Балалар җаваплары)

- Сез ничек уйлыйсыз, тагын төсле тукымалардан нәрсәләр ясап була?

(Балалар белән сөйләшү)

Тәрбияче: бүген сез иҗади технологияләренең бер төре белән таныштыгыз ул - кинусайга, шөгыльдә алган билгеле күнекмәләр белән сез бу эшне үзегез дәвам итә аласыз, һәм бүтән балаларны яки олыларны да өйрәтә аласыз. Башкарган эшләрегез һәм иҗади сәләтегез өчен рәхмәт. Шуның белән мастер-класс тәмам.



"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау "Шаян" катнаш төрдәге балалар бакчасы" мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениясе

**Абдрахманова Гөлия Ришат кызы**

***Мастер-класс: "Милли бизәкле букча"***

Нәфис зәвыгы, күңел нуры, житез кулларының осталыгы белән элек-электән үк дан тоткан татар хатын-кызлары. Челтәр-челтәр ак пәрдәләрсез, чигүле сөлге, ашъяулыкларсыз ямьле булмас иде татар йортлары. Ә әбиләрнең сандыкларындагы буыннан буынга тапшырыла торган кадерле байлыкны караганда без тарихыбыз белән генә түгел, татар халкының милли сәнгате белән дә танышабыз.





Бүген хатын-кызларның күпчелеге эш белән мәшгуль. Ул балалар да үстерә, йорт-җирне дә карый, өстәвенә карьера да ясый. Мең төрле мәшәкатьләргә чумып, заман таләпләренә буйсынып яши. Ә үзенчәлекле, кабатланмас һәм серле татар хатын-кызы булып калу өчен нишләргә кирәк соң? Моның өчен һәрбер хатын-кызның үз сере бардыр, мөгаен. Мин дә үз серләремнең берсен чишеп, уртаклашасым килә. Хатын-кыз, нинди генә кием сайласа да, аның образын тулыландырып торучы нәрсә – ул матур, зәвыклы букча. Төркемгә йөргән кызлар көндә бер яңа букча белән килергә яраталар. Аларның тышларында чит ил мультфильмнарының геройлары төшерелгән.

Шул геройларның исемнәрен истә калдырып, иптәшләре белән әңгәмә коралар. Шунлыктан балаларыбызны татар милли бизэге ләлә чәчәге турында сөйләргә булдым. Балаларның кызыксынуын тагын да артырыр өчен ләлә чәчәген букчага ясарга тәкъдим иттем. Хәзерге заманда тукамага бизәк төшерү өчен буяулар бик күп, мөмкинчелеге булган кеше күңеленә ошаган буяуны ала. Аны төрле ысуллар белән төрле материалларга төшерә, ясый. Буяны тукымага төшерегә уңайлы булсын өчен пумаланы губка белән кечкенә карандашлардан ясадым. Шулай трафаретны әзерләп, тукымадан букчалар тегеп куйдым. Минемчә, ләлә чәчәге төшерелгән букча, ул татар хатын-кызларына гына хас булган нәзәкатьлелек, сихри зәвыклык биреп торачак.

Әзер букчалар эстенә трафарет куела, пумалага буяу алабызда букчаны бизибез. Букча буялып бөткәч. трафарет алына. Буяу кибеп бөкәч, букча әзер.





Әлеге бизәкле букча күңелгә җылылык биреп, татар милли сәнгатенең бизәге булып торачак. Аның ярдәмендә туган як тарихы турында булган белемнәр киңәя, матурлыкны күрә белү генә түгел, аны сурәтләү, татар бизәкләрен көнкүрештә куллану ысулының берсе үзләштерелә. Һәм үзара булган хезмәттәшлек уңай тәэсирләр калдыра.



Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының “Гомуми үсеш бирүче төрдәге Балтач 2нче номерлы балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе, беренче квалификацион категорияле тәрбиячесе

**Габделхаева Гөлшат Мәгъсүм кызы**

***Виммельбух технологиясе кулланып – сөйләм үсеше аша әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.***

Остаханәмнең максаты, әхлакый сыйфатлар тәрбияләүдә сөйләм үсеше аша виммельбух технологиясе куллану.

-Башта виммельбухның нәрсә икәнен ачыклыйк.

Виммельбух-текстсыз, әмма күз явын алырлык күп детальле, иллюстрацияле китаплар: персонажлар, предметлар, сюжет линияләре – болар барысы да бердәм мәгънәле композициягә берләштерелгән. Мондый китаплар беренче тапкыр Германиядә барлыкка килә. «Wimmeln» фигыле «тупланырга, җыелырга»дигәнне аңлата. Бу баланың сөйләмен үстерүдә бик яхшы ярдәм итә.

Виммельбухларның үз үзенчәлекләре бар. "Классик" виммельбух шактый зур, А2 форматында, әмма юлга яки алып йөртергә уңайлы булган кечкенәрәк вариантлары да бар. Кагыйдә буларак, тыгыз картонда басылган, бит саны 5тән 10га кадәр. Битләрдәге детальләр саны бик күп, һәр сантиметр рәссам тарафыннан кулланыла һәм ниндидер вакыйганы бәян итә. Монда бердәм мәгънә үзәге юк, сюжет линияләре бер үк вакытта бара.

Куллану максаты:

- хәтер, фикерләү, күзаллау, игътибар үсеше, ягъни сөйләмнең тулы үсеше белән тыгыз бәйләнгән психик процесслар, шулай ук турыдан-туры сөйләм үсеше (сүзлекне баету, сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үсеше;

-әйләнә-тирә дөнья турында күзаллауларны киңәйтү; булган социаль коммуникация тәҗрибәсен актуальләштерү һәм яңасын туплау;

-башка кешегә теләктәшлек итү сәләтен үстерү, аның хисләрен һәм эмоцияләрен аңлау, үз тәртибен алар нигезендә көйләү;

-тырышлык, утырып эшләүне күнектерү;

- кул моторикасын үстерү.

Эш этаплары:

Башта китапны карыйбыз, ә аннары әкренләп аның дөньясына баланы җәлеп итә башлыйбыз. 1-2,5 яшьтән безнең бурыч-балага бер-ике битен күрсәтү. Детальләр күп булганлыктан, яңа сүзләргә басым ясыйбыз: хайваннар, транспорт, предметлар. һәрбер хайванны, предметны атыйбыз, төс, зурлык, формасы турында сөйлибез. Хайван, персонаж һ. б. нәрсә эшли икәнен аңлатабыз. Бер бит белән бер атна дәвамында хикәяләр уйлап чыгарырга мөмкин, ә аннары чираттагысына күчеп, яңа хикәяне таныш геройларны эзләүдән башларга мөмкин.

2 - 4 яшьтә мәгълүмат күләмен арттырабыз. Бу яшьтә бала күп мәгълүматны кабул итә ала, игътибар арта. Күбрәк күләмле хикәяләр төзи алабыз яки хәтер һәм игътибарны яхшыртабыз, элек әйтелгән геройларны искә төшерә һәм таба алабыз. Хисапны өйрәнә башларга, ничә икәнен белергә тәкъдим итәргә, яисә хәрефләрне өйрәнә башларга була: "А авазыннан нәрсә башлана?”.

Хайваннар һәм транспорт балаларнын яраткан темасы, ләкин виммельбухта һәрвакыт таныш булмаган нәрсәне табарга мөмкин нәкъ менә шулай суз запасы киңәя.

5-7 яшьтә баланың мәктәпкә әзер булуының мөһим аспектларының берсе-рәсем буенча хикәя төзү сәләте үстерү бик мөһим.

7 яшьтән башлап виммельбухны үзен булдырырга да тәкъдим итәргә вакыт. Үз вакыйгаларын эзләргә, уйлап чыгарырга, темасын билгеләргә, фон ясарга (ватманга рәсем ясарга һ.б.). Сюжет һәм шартлар уйлап чыгарып, күп санлы геройларны табу һәм кисү. Геройларны фонга урнаштырырга һәм аларныябыштырырга.

Виммельбух әзер!

Виммельбух жанрындагы китаплар балаларның шәхесенең гомуми мәдәниятен формалаштыру, шул исәптән аларның социаль, әхлакый сыйфатларын һәм социаль җаваплылыгын үстерү мәсьәләләрен хәл итәргә мөмкинлек бирде. Балаларның үзара мөнәсәбәтләре, хайваннар дөньясына карата сакчыл караш, җәмәгать транспортында, шифаханәләрдә, мәдәният үзәгендә үз – үзләрен тотышларында әхлакый сыйфатлар тәрбияләүдә ярдәм итте. Бу китаплар тормышны бер агым итеп кабул итәргә өйрәтә, анда булган һәрнәрсә кешеләр һәм әйләнә-тирә мохит белән тыгыз бәйләнгән.

**Практик өлеш**

Барышы:

-Без балаларга рухи - әхлакый кыйммәтләрнең орлыкларын чәчүчеләр, мәкальләрне искә төшерик әле, беләбез микән? *(катнашучыларга мәкалләрнен башы язылган битләр таратыла)*

-Бирелгән мәкалләрне дәвам итик-

-Олыласаң олыны, ... *(олыларлар үзеңне)*.

-Җәй эшләсәң... *(көз ашарсың)*

-Кош канаты белән... *(кеше дуслык белән көчле)*

-Киемеңә карап каршы алалар ... *(акылыңа карап озаталар)*

-Агач җимеше белән... *(кеше эше белән матур)*

-Ә хәзер мин сезне үзегезгә виммельбух ясарга тәкъдим итәм, кемнәрдә мәкалләрбар рәхим итегез.

-Сезнең алдыгызда бик күп төрле төсле рәсемнәр һәм карандашлар ята. Алар ярдәмендә китапның бер сюжетлы битен ясарга тәкъдим итәм. Ясап бетергәч бу рәсемнәр буенча хикәя, экият төзеп сөйләргә тәкъдим ителә).

-Аңа исем уйлап табыгыз һәм языгыз. Балаларның нәрсә белән кызыксынуына һәм нәрсә турында хыяллануына игътибар итегез.

-Сораулар бирәбез: Ни өчен? Нәрсә булды? Ә моңа кадәр нәрсә булган? Геройның яки персонажның хисләре һәм эмоцияләре белән кызыксынабыз. Кечкенә генә хикәяне үзебез уйлап табып, вакыйганы виммельбухка таянып дәвам итүен сорыйбыз.

Татарстан Республикасы Чистай  муниципаль районы
“Кояшкай” балалар бакчасы тәрбиячесе
**Гатауллина Эльвира Гаптракиповна**

# ***“Балалар остахәнәсе”***

**Программа эчтәлеге:**

1. Милли киемнәр, орнамент турында белемнәрен ныгыту.
2. Милли киемнәргә кызыксыну уяту, үзләренә генә хас булган үзенчәлекләрен ачыклау. Халык сәнгате аша балаларда зәвык, матур итеп киенергә теләк тәрбияләү.
3.Балаларның логик фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерү.

**Сүзлек:** лалә, өчьяфрак, канәфер чәчәге, милли күлмәк, калфак, күкрәкчә.

**Т**: *Идел ярларынанурларсибеп,*
*Матурбулыпатабездәтаң.*
*Таңшикеллеяктытуганилем,*
*Бәхетбиргәнҗирем- Татарстан!*

**Т:**Балалар, безнең республика ничекатала?

**Б:**Республика Татарстан.

**Т:** Дөрес ,балалар. Республикабызданиндимилләтләряши?

**Б:**Татарлар, руслар, чувашлар, үзбәкләр, һ.б.

**Т:**Дөрес, балалар. Без ниндимилләткешесеикәненничекбеләалабыз?

**Б:**Милләтләрнетелләре, киемнәре, киемдәгеорнаментларыбуенчааерыпбула.

**Т:**Дөрес, шулай. Балалар, карагызәлемиңа, минем кием сезгәошыймы?Ә мин нинди халыкның милли киеменә киенгәнмен? (тәрбияче татар халык милли киеменә киенә).

**Б:** Ошый! Сез татар халык милли киеменә киенгәнсез.

**Т:**Дөрес балалар! Мин сезгә кул эшләре остаханәсенә барырга тәкъдим итәм. Барасыгыз киләме?

**Б:** Әйе!

**Т:**Безнең остаханә ике цехка бүленгән. Ә кем нинди цехта эшләгәнне без хәзер белербез. Подностан үзегезгә ошаган геометрик фигуралар сайлап алыгыз. Кемдә очпочмак геометрик фигура, кулларны өскә күтәрегез һәм фигураларыгызны күрсәтегез. Бик әйбәт!

Хәзер үзегезнең эш урыныгызны табыгыз. Сезнең беренче цех була. Турыпочмак фигураларны күрсәтәбез. Әйбәт, эш урыныгызны табыгыз. Сезнең икенче цех була.

(Өстәл янына килә, сорый)1 нче цех сез нәрсә бизисез?

**Б**: Калфак.

**Т:** 2нче цех. Сез нәрсә бизисез?

**Б:** Күкрәкчә.

**Т:** Бик әйбәт! Мин оста булам, ә сез минем укучыларым буласыз. Эшебезне башлаганчы, хәрәкәтләнеп алыйк.

***Физ.минутка :****Кулны куябыз билгә,*

*Бөгеләбез һәр якка.*

*Күтәрәбез аякларны, кире куябыз аларны.*

*Кулларны без күтәрик, бераз гына селкетик.*

*Шулай итеп ял итик.*

**Т:** Ә хәзер эшебезне башлыйбыз. Балалар сез татар милли орнаментның нинди бизәкләрен беләсез?

**Б:** Ләлә, канәфер, кыңгырау, өчъяфрак, яфрак.

**Т:** Борынгы заманда барлык кеше дә кием сатып ала алмаган, алар киемнәрне үзләре теккәннәр һәм матур булсын өчен бизәгәннәр. Ә аларны бизәү өчен үрнәкләрне каян алганнар?

**Б:** Табигатьтән алганнар.

**Т:** Дөрес балалар! Бу матур киемнәрне нәселдән-нәселгә биргәннәр һәм шулай ук музейларда да саклаган.

**Т:** Минем оста укучыларым хәзер эшләгән эшләрегезне киеп күрсәтегез.

Нәрсә бизәдегез сез бүген?

Сезгә кул эшләре остаханәсендә ошадымы?

Минем укучыларым булу авырмы?

Өйгә кайткач кемгә сөйли аласыз?

Рәхмәт!

Татарстан Республикасы Чистай  муниципаль районы

“Кояшкай” балалар бакчасы тәрбиячесе

**Габитова Рәзинә Рүзәл кызы**.

**“Гөлназның читекләре”**

Россия үзенең күпмилләтле составы белән уникаль, анда һәр халык үз тарихы, традицияләре, мәдәнияте белән аерылып тора. Буыннан-буынга мәдәни халык кыйммәтләрен саклау һәм тапшыру - бу зур җаваплылык һәм намус вазыйфа.

Идел буенда Россия мөселман мәдәнияте үзәге - бай һәм гүзәл башкаласы булган Татарстан Республикасы урнашкан. Казан - милли татар традицияләренә хәзерге заман тормыш ритмы белән ярашкан шәһәр. Монда буыннан-буынга уникаль һөнәрләр бирелә, аларга бары тик осталардан гына өйрәнергә мөмкин.

Хәзер милли костюм һәм аяк киеме тегү белән махсуслаштырылган җитештерү предприятиеләре шөгыльләнә, анда профессиональ осталар костюм тарихын, аны әзерләү үзенчәлекләрен яхшы белә.

Читекләр - матур, яхшы уйланылган һәм функциональ татар итекләре. Йомшак борын һәм каты арткы ягы читекләрнең үзенчәлекле билгесе булып тора.  Бу аяк киеме татарларда киң таралган һәм мили костюмның бер өлеше булып тора. Читекләр шулай УК Себер, Ерак Көнчыгыш, Кавказ халыклары арасында да билгеле. Бу аяк киеме тарихи яктан уңайлы җәяү йөрү өчен билгеләнгән, шул исәптән күчмә халыкар асында да. Читекләр аучының аякларын

алыштыргысыз, шул УК вакытта аяк табанын һәм балтырларын яхшы саклап, урман буйлап йомшак һәм тавышсыз гына йөрергә булышучы аяк киеме. Бу читекләрне төрле төрдәге табигый күннән тегәләр: бәйрәм була калса - юка һәм эластик сафьяннан, көндәлек вариант сыйфатында хром яки юфть кулланалар.

Хатын-кыз читекләрен төрле төсләргә буялган күн белән бизәү кабул ителгән. Андый читекләр безнең көннәргә кадәр сакланган.

Орнаментны сайлауга килгәндә, ул гадәттә үсемлек мотивлары яки абстракт фигуралар белән тәкъдим ителә, чөнки мөселман дөньясы кагыйдәләре хайваннарны һәм кошларны сурәтләргә мөмкинлек бирми. Канун нигезендә тегелгән аутентик читекләр декоратив-гамәли сәнгать предметы булып тора. Асылда һәр пар үзенчә уникаль.

Мастерлар, авторлар - читек әзерләү традицияләрен саклаучылар, яңа буыннарга әлеге кабатланмас аяк киеме тегү технологиясен бирергә тырышалар.

Балаларны татар милли киеме үзенчәлекләре белән таныштыру һәм читекләргә татар орнаменты элементларыннан бизәкләр төзергә өйрәтү максатыннан мин дә өлкәннәр төркеме балалары өчен “Читеккә бизәк төшерү” исемле мастер класс конспектын эшләдем.

**Шөгельнең бурычы** булып ир-ат һәм хатын-кыз костюмнарының элементлары һәм үзенчәлекләре турында төшенчә бирү, балаларның иҗади сәләтләрен, күз үлчәмен, хыялын, нәфис зәвыгын үстерү тора. Шулай ук мастер класс сүзлек запасын киңәйтергә (читекләр, калфак, камзул, бөрмәләр, түбәтәй) мөмкинлек бирә. Әйләнә-тирә чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәт тәрбияли. Татар халкының декоратив-гамәли сәнгате белән кызыксыну тәрбияли.

Мастер класс барышында музейга экскурсиягә бардык. Анда татар декоратив-гамәли сәнгате белән таныштык. Татар үсемлек орнаментлары турында әңгәмә уздырдык. Татар милли киемнәре турында илюстрацияләрне,

альбомнарны карадык. Трафарет аша милли орнаментлар ясарга өйрәндек. Булачак читекләребезнең фоамиран материалыннан эскизларын кистек.

**Эш барышы:**

Ишеккә шакыган тавыш. (Кулына капчык тоткан курчак керә)

Тәрбияче: Балалар, безгә бүген Гөлназ исемле курчаккунакка килде. Әйдәгез, исәнләшик аның белән.

Балалар: Исәнме, Гөлназ.

Тәрбияче: Аның күлмәге нинди?

Балалар: Матур, озын җиңле күлмәк, бизәкле жилет. Башында калфак. Аякта күн итекләр.

Тәрбияче: Гөлназның кием-салымы ничек дип атала?

Балалар: Татар милли киеме.

Тәрбияче: Татарлар борынгыдан шундый кием киеп йөриләр. Халык осталары аны үсемлек орнаментыннан төзелгән татар бизәкләре белән бизәгәннәр. Сез татар орнаментының нинди элементларын беләсез?

Балалар: Яфраклар, ләлә чәчәкләре, кыңгыраулар, дугалар, дулкынлы сызыклар.

Тәрбияче: Дөрес. Татар орнаментында нинди төсләр кулланыла?

Балалар: Яшел, сары, зәңгәр, кызыл, коңгырт.

Тәрбияче: Дөрес. Балалар, безнең курчагыбыз буш кул белән килмәде. Аның хәтта капчыгы да татар бизәге белән бизәлгән. Гөлназның капчыгы эчендә нәрсә ятканын беләсегез киләме? Капчык авызын ачканчы табышмак чишнргә кирәк булачак.

Йомшак итеп тегелгән,

Матур бизәп чигелгән

Бәйрәмнәр җитте исә

Аягына кияләр.

(*Читекләр күрсәтәм*)

Балалар: Читек.

Тәрбияче: Читек-татар милли киеменнән итекләр. Читек нәрсә белән бизәлгән?

Балалар: Яфрак һәм чәчәкләр белән.

Тәрбияче: Дөрес. Кешеләр мондый аяк киемен кая кияләр?

Балалар: «Сабантуй» бәйрәменә. Татар халык биюенә.

Тәрбияче: Кем мондый аяк киеме кия?

Балалар: Әниләр, әбиләр, кызлар һәм хәтта әтиләр.

Тәрбияче: Минем дә әбием бар, ул да «Сабантуй» бәйрәменә Барганда матур бизәкле читекләрен киеп куя.

Тәрбияче: Балалар, сезнең дә матур бизәкле читекләр ясаучы остазлар буласыгыз киләме?

Балалар: Әйе.

Тәрбияче: Барлык остазлар да остаханәдә эшлиләр. Без дә сезнең белән остаханәгә барабыз һәм эскизларыбызны бизәрбез. Гөлназ да остаханәдә булачак. Дөрес утырыгыз һәм эшебезне башлыйбыз.

*(Фоамиран материалыннан эзерләнгән читек эскизлары, тюбиктагы буяулар, милли бизәк төшерелгән үрнәкләр куелган өстәл янына киләбез. Балалар эскизларны алалар.)*

Тәрбияче: Балалар, ничек уйлыйсыз, минем кулымда нәрсә?

Балалар: Читек.

Тәрбияче: Әйе, дөрес. Без әлеге читекләребезне гади булмаган ысул белән бизәрбез. Сезнең алдыгызда тылсымлы буяулар. Бу буяулар белән осталар киемнәргә төрле матур рәсемнәр төшерәләр. Иң элек карандашлар белән читек эскизына сезгә ошаган бизәкне ясыйбыз. Шуннан соң төсле тюбикларыбызны алып бизәкләребезне буйыйбыз. Нинди бизәкләр төшерәбез, балалар?

(Балаларның җаваплары)

Тәрбияче: Мәликә, син нинди төсләр куланнасың?

Мәликә: кызыл, яшел, сары, ак.

Тәрбияче: Бик яхшы. Балалар, читегебезне бизәгәндә матур, ачык төсләр кулланабыз.

Тәрбияче: Нинди бизәкләр ясыйбыз?

(Балалар җаваплары)

Тәрбияче: Эшебезне башлыйбыз!

(Эш барышында балаларга киңәшләр,күрсәтмәләр, индивидуаль ярдәм итәм)

Эш тәмамлангач, балаларга күргәзмә оештырырга тәкъдим итәм.

Тәрбияче: Балалар, карагыз әле, безнең эшләребез белән нинди кызыклы күргәзмә барлыкка килде.Читекләребез кибеп бетсен, ә хәзер мин сезне "Түбәтәй" уенында уйнарга чакырам. Балалар түгәрәк эченә керәбез. Милли музыкага түгәрәк буенча түбәтәй бирәбез. Көй туктала, түбәтәй кемдә кала, шул бала биремне үтәячәк.

Нәтиҗә:

Тәрбияче: Балалар, без бүген нәрсә ясадык?

Балалар: читек.

Тәрбияче: Дөрес. Кемнең читеге сезгә күбрәк ошады?

(Балаларның җаваплары)

Тәрбияче: Сез читекләрне нинди бизәкләр белән бизәдегез? Сезгә читекләрне бизәргә ошадымы? Ясаган читекләрегезне кемгә бүләк итәр идегез?

(Балаларның җаваплары)

Тәрбияче: Барлык эшләр дә бик матур килеп чыкты. Әфәрин, балалар!

Курчагыбыз Гөлназ матур читекләргә шатланды, барагызда да рәхмәт әйтте.Сез булдырдыгыз!



Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районның “Дөбъяз “Гөлчәчәк” балалар бакчасы”, мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

**Минһаҗева Альбина Ришат кызы**

Милли колоритлы мастер-класс

**“Милли ризыклар-табын түрендә”**

**Максат:** Балаларны татар халык ашлары – чәй ашы ясау серләренә өйрәтү, үзеңнең хезмәт җимешеңә карата хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Бурычлар:**

1. Татар халык ашлары турында төшенчә бирү, милли ризыклар турында белемнәрен киңәйтү.
2. Камыр җәяргә һәм чәй ашы кисәргә, ясарга өйрәтү. Эш кораллары белән таныштыру һәм алар белән эшләргә өйрәтү.
3. Төгәллек, игътибарлылык, мөстәкыйльлелек, пөхтәлек сыйфатлары булдыру. Үз хезмәтеңнең нәтиҗәсен күреп, горурлану хисе тудыру.
4. Татар гореф-гадәтләренә хөрмәт, ихтирам һәм хезмәткә кызыксыну уяту.

**Эш кораллары:** куна такталары, уклау, камыр, махсус җайланмалар (пумала, пычаклар), алъяпкычлар.

**Күргәзмә әсбаплары:** татар халык ашлары төшерелгән сурәтләр, экран.

**Сүзлек:** куна тактасы, уклау, камыр, гөбәдия, чәк-чәк, паштет, чәй ашы, мич ашы.

**Шөгыль барышы:**

Балалар алдан әзерләп куелган өстәл тирәли басалар.

**Әдилә:** “Гөлчәчәк ” бакчасына
Җыелды татлы ашлар,
Гөбәдия, бәлешләр, пәрәмәч, өчпочмаклар.

Иң кадерле икмәк тә.

Табын яме чәк-чәк тә

Утыралар тезелеп,

Кабарып, өстәл тулып.

**Тәрбияче:** Балалар, безнең әби-бабайларыбыз, әти-әниләребез кул эшләренә, җырга-биюгә бик сәләтле булу белән бергә, аш-суга да оста булганнар, тәмле, татлы ризыклар пешергәннәр.

Менә бүген без сезнең белән татар милли ашлары, ризыклары турында сөйләшербез.

Милли ашларның үзенчәлеге халыкларның тормыш рәвешенә бәйле. Һәрбер халыкның үз милли ризыгы бар.

Мәсәлән: русларда-пилмән, үзбәкләрдә-пылау, башкортларда – бавырсак…

-Балалар, ә сез нинди ашларны беләсез? (Балалар җаваплары)

Татар халкы бигрәктә камыр ризыклары, чәй ашлары пешерергә яраткан. Алар бик күп төрле. Сез нинди татар милли камыр ризыкларын беләсез? (Балалар җаваплары)

**Презентация карау**.

Әйе, балалар, сез дөрес әйттегез. Иң кадерлесе-ипи, татлы гөбәдия, итле пәрәмәч, өчпочмаклар, кыстыбый, катлы паштетлар, чәк-чәк һәм кабартма-болар барсы да безнең милли ризыкларыбыз.

**Тәрбияче:** Балалар, ә хәзер без сезнең белән чәй ашы ясарга өйрәнербез. Аннары тәмләп чәй эчәрбез.

**Практик эш**

**Тәрбияче:** Балалар, вакытны озакка сузмас өчен мин камырны алдан бастым. Нәрсәләр салдым икән? Сезнең күргәнегез бармы әниләрегез камыр куйганын? (Балалар җаваплары)

Әйе, балалар, бик дөрес! Камыр куяр өчен безгә сөт, йомырка,тоз, шикәр комы, сыек май, чүпрә һәм он кирәк. Барысын бергә салып. яхшылап басып камыр бастым. Без сөйләшкән арада камыр ял итеп алды, ә хәзер эшкә керешәбез.

Мин хәзер сезгә камырны бүлеп бирәм. Аны кулда әвәләп, түгәрәк ясыйбыз. Уклау белән әкренләп камырны җәябез. Камыр кулга ябышса, он сибеп җибәрәбез. Җәемебез әзер булгач, пумала белән сыек май сылыйбыз, песок сибәбез. Камырны рулет формасында төреп як ягын тоташтырабыз. Куркынычсызлык кагыйдәләрен истә тотып, пычак белән бер ягын кисәбез әм менә әйләндергәч йөрәк формасында чәй ашыбыз килеп тә чыга.

Ясаган чәй ашларын майлы табага төзеп, кайнар мичкә пешәргә куябыз.

Чәй ашы пешкән арада, әйдәгез әле, кызларым-йолдызларым, “Без, без, без идек” уенын уйнап алыйк!

(“Без, без, без идек” уены уйнала)

Әфәрин, кызлар! Менә ничек күңелле булды! Тәмле исләр чыга башлады. Әйдәгез, мичебезне карыйк әле. Ууу, субханалла, ничек матур итеп күпереп пешеп чыккан безнең чәй ашыбыз! Әйдәгез, балалар, дәү эти, дәү әнине чакырып бергәләшеп тәмле итеп чәй эчик.

**Тәрбияче:** Милли ризыкларны пешерик без,

Гореф-гадәтләрне онытмыйк,

Тарихтагы эзне югалтмыйча,Киләчәктә атлыйк, сынатмыйк



Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Коркачык “Черемушка” балалар бакчасы тәрбиячесе
**Минһаҗева Роза Гаптелхай кызы**

***Сөембикә ядкарьләре***

**Максат:** Татар халкының бизәнү әйберсе – беләзек белән таныштыру, аны бизәү

**Бурычлар:**

- балаларның иҗади сәләтләрен үстерү;
- бәйләнешле сөйләм телен үстерү;
- вак моториканы үстерү;
- балаларның тырышлыкларын, игътибарлыкларын үстерү;
- татар халкыбызның тарихына, милли киемнәренә, ашамлыкларына, бизәнү әйберләренә карата хөрмәт хисе, мәхәббәт тәрбияләү;
- ярдәмләшү, күмәклелек кебек сыйфатлар тәрбияләү

**Җиһазлау:** проектор, ноутбук, лалә чәчәкләре рәсеме, конверт белән биремнәр, бизәкләр төшерелгән ашъяулыклар, тәлинкә белән өчпочмаклар, тозлы камыр, такталар, “Сөембикә остаханәсе” дигән тартма, беләзекләр, ташлар

## Барышы

**Тәрбияче:** Балалар, әйдәгез, кулга-кул тотынышып, бер-беребезгә үзебезнең сәламебезне, җылыбызны бүләк итик әле.

Кулларга без тотындык,
Бер-беребезгә елмайдык.
Җылы китте кулларга,
Рәхәт булды дусларга.

*“Кучтәнәч” тапшыруының көе яңгырый*

**Тәрбияче:** Балалар, ишетәсезме ниндидер көй яңгырый. “Күчтәнәч” тапшыруы башлана икән. Дәү әни нинди әкият сөйләр икән, әйдәгез, тыңлыйбызмы? (балаларның җаваплары)

*Балалар экран каршына килеп утыралар.*

**Дәү әни:** Исәнмесез, минем нәни дусларым! Экран каршына җайлабрак утырыгыз. Әкиятебезне башлыйбыз. Борын-борын заманда Сөембикә исемле патшабикә яшәгән. Ул бик чибәр, акыллы булган. Аны бөтен кеше дә яраткан, хөрмәт иткән. Сөембикә бик матур итеп киенергә, бизәнү әйберләре тагып йөрергә яраткан. Ә аларны үзенең матур сандыгында саклаган. Аның әле тагын бик матур бер тартмасы бар икән. Ул тартмада нәрсәләр генә юк ди. Сөембикә үзе шулардан төрле-төрле бизәнү әйберләре ясаган. Ләкин көннәрдән бер көнне аның тартмасы югалган һәм ул “кайдан эзләп табыйм
икән инде дип” бик борчылган. Сөембикә әле дә бу тартманы эзләп таба алмый икән. Балалар, бәлки Сөембикәгә сез ярдәм итә алырсыз? Аның тартмасын табып бирә алмассыз микән? Мин сезнең акыллы, кыю, тапкыр

балалар икәнегезне беләм. Шуңа күрә тартманы эзләп таба алачагыгызга да ышанам. Ә хәзергә сезнең белән саубуллашам. Сездән яхшы хәбәрләр көтеп калам. Сау булыгыз, минем нәни дусларым!

**Тәрбияче:** Балалар, Сөембикәгә ярдәм итәбезме? (балаларның җаваплары)
Ә тартманы кайдан эзләп табыйк икән инде? (балаларның җаваплары)

**Тәрбияче:** Әйдәгез, тылсымлы сүзләр әйтеп карыйк. Ә хәзер күзләрне йомыйк та минем арттан кабатлыйк.

2 тапкыр кул чабыйк

3 тапкыр тыпырдыйк.

Аннары утырыйк

Ә хәзер уяныйк.

*Тәрбияче палас кырыеннан саннар язылган лалә чәчәкләре табып ала.*

**Тәрбияче:** Балалар карагыз әле, идәндә лалә чәчәкләре ята. Ә аларга нәрсәләр язылган? (балаларның җаваплары) Балалар, бу гади генә чәчәкләр түгел. Аларның ниндидер сере бар. Бәлки алар безгә тартманы эзләп табарга ярдәм итәрләр. Анда нәрсәләр язылган? (балаларның җаваплары) Әйдәгез, алайсам чәчәкләргә язылган саннар буенча барып карыйк әле. Бәлки безгә юлны күрсәтерләр. Нинди саннан башлыйбыз.

*Балалар 1 саны язылган чәчәк янына баралар һәм биремне үтиләр.*

**Тәрбияче:** Балалар, монда пазллар бар икән. Әйдәгез аларны җыеп карыйк әле, нинди рәсемнәр килеп чыгар икән?

*Балалар пазлны төзиләр һәм нинди рәсем килеп чыкканын әйтәләр.*

**Тәрбияче:** Ә сез аның татар кызы һәм татар малае икәнен кайдан белдегез? (балаларның җаваплары) Булдырдыгыз, балалар. Әйдәгез, юлыбызны дәвам итик.

*Балалар 2 саны язылган чәчәк янына баралар һәм биремне үтиләр.*

**Бирем:** Табышмакның җавабын табыгыз.

Йомырка белән онны
Бутап камыр басканнар
Бәрәңге, ит, тоз салып,
Почмаклар ясаганнар. (өчпочмак)

**Тәрбияче:** Дөрес әйттегез микән. Карыйк әле. Булдырдыгыз. Әйдәгез хәзер камырдан өчпочмаклар ясыйк әле.

*Балалар өчпочмаклар ясыйлар*

**Тәрбияче:** Бигрәк матур өчпочмаклар килеп чыкты, балалар, булдырдыгыз. Әйдәгез, аларны җыеп куйыйк, кабара торсыннар. Ә без кулларыбызны сөртик тә юлыбызны дәвам итик.

*Балалар 3 саны язылган чәчәк янына баралар һәм тартманы табалар*

**Тәрбияче:** Балалар, менә Сөембикәнең тартмасын эзләп тә таптык. Әйдәгез, карыйк әле нәрсәләр бар икән бу серле тартмада.

*Тартманы ачып карыйлар, беләзекне күрәләр.*

**Тәрбияче:** Балалар, бу бизәнү әйберсен беләсезме? (балаларның җаваплары) Бу – беләзек. Аны татар кызлары кулларына тагып йөргәннәр. Ул төрле ташлар белән матур итеп бизәлгән. Балалар, карагыз әле, Сөембикә беләзекләр тә әзерләп куйган икән. Әйдәгез аларны ташлар белән матур итеп бизик әле.

*Балалар, беләзекләрне ташлар белән бизиләр*

**Тәрбияче:** Бигрәк матур килеп чыкты беләзекләр. Шулай бит, балалар. Сезгә ошадымы?

**Тәрбияче:** Ә хәзер , әйдәгез, Сөембикәгә тартмасын тапшырыйк. Ул таба алмагач, бик борчыла торгандыр. Әйдәгез, киттек.

*Балалар чыгып китәләр.*

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе тәрбиячесе
**Яруллина Фирдәвес Нәҗип кызы**

***“Һөнәр-кеше канаты,канатлы бул,канатлы”***
***(милли традицияләрне куллану)***

**Максат**.

-Кунак каршы алуга хөрмәт, игътирам белән карарга өйрәтү;

-Кыстыбый пешерү серләрен өйрәтү;

-Пешекче хезмәтенә карата кызыксыну хөрмәт тәрбияләү;

- милли гореф –гадәтләрне, әхлак кагыйдәләрен өйрәтү;

-Бергәләшеп, тату эшләү күнекмәләрен ныгыту.

**Җиһазлар.** Кирәкле савыт-сабалар, ризыклар,пешекчеләр кия торган махсус киемнәр.

**Катнашучылар.** Катнаш төркем балалары,тәрбияче, кече тәрбияче, пешекче

***Эшчәнлек барышы***

**Тәрбияче.**Балалар зур сөенеч бар. Бүген күршедә яшәүче ак әбиебез кунакка керергә вәгъдә бирде. Әйдәгез, нишлибез, кунакны ничек каршы алабыз?

**Балалар җавабы**. Өебезне җыештырырга, бүләк әзерләргә, чәй куярга, тәмле ризык пешерергә, матур күлмәкләр киеп куярга кирәк.

**Тәрбияче.** Балалар алай булгач, әйдә, эшкә тотыныйк. Кунакны сыйлар өчен нинди милли ризык әзерлик икән?

**Балалар**. Бәлеш, кош теле, бавырсак, чәк-чәк, кыстыбый.

**Тәрбияче**. Әйдәгез, кыстыбый пешерәбез .

**Балалар**.Бик әйбәт, әйдәгез, пешерәбез.

**Тәрбияче.**Кыстыбый бик тәмле һәм туклыклы, шул ук вакытта әзерләргә артык катлаулы булмаган татар милли ашы. Кайбер җирдә кыстыбыйны **күзикмәк**, **якмыш** та диләр. Гадәттә аны төче камырдан әзерлиләр. Кыстыбый эченә төйгән бәрәңге, тары боткасы, төйгән киндер орлыгы, мәк һ.б. салалар.




***Әзерләү тәртибен аңлатып үтәм, тыңлагыз, исегездә калдырыгыз***

Бит каты итмәчә генә төче камыр басалар да, бераз тоткач, 75 әр г лы кисәкләргә бүлеп, юка гына итеп җәяләр, җәемнәрне кызган табада, май сөртмичә генә, башта бер, аннары икенче ягын әйләндереп пешереп алалар, суынмасын һәм катып китмәсен өчен, берсе өстенә берсен өеп, тастымал белән каплап куялар. Чөнки суынса, урталай бөкләгәндә сына.

Кыстыбый эченә салу өчен, бәрәңге пешереп, кайнар килеш төяләр, кайнар сөт, сары май, майда кыздырылган суган салып болгаталар.

Әзер җәемнең яртысына бәрәңге боламыгы ягып, тиз генә икенче ягы белән каплыйлар. Кыстыбыйны, эрегән май белән майлап, табынга кайнар килеш бирәләр.

*1 кыстыбыйга: 75 г камыр, 100 г бәрәңге, 20 г суган, 20 г сөт, эченә салырга һәм тышын майларга 20 шәр г атланмай.*

Безгә ярдәм итәр өчен бакчабызның пешекчесе Гөлшат апабыз килде. Шулай итеп, әйдәгез, кыстыбыйны үз кулларыбыз белән әзерләп карыйк






***Гөлҗамал апа** керә.* Әссәламегаләйкем, балалар.

**Балалар.** Исәнмесез, Гөлҗамал апа, түрдән узыгыз,без сезне көттек.

**Гөлҗамал апа**. Кунак киләсен каян белдегез, мәчегез битен юдымы әллә?

**Тәрбияче**. Ник алай дисез, бездә мәче юк бит.

**Гөлҗамал әби**.Бу бит халык сынамышы. Тыңлагыз алай булгач, тагын сынамышлар әйтәм

-Мендәр идәнгә ишелеп төшсә-кунак килүен көт;

-Мәче битен юса-кунак килә;

-Самовар җырласа-кунак килә.

**Балалар** Гөлҗамал әби, әйдә, түрдән чәй табына узыгыз.

**Тәрбияче.** Гөлҗамал апа, балаларыбыз син килә диеп, әй тырыштылыр, әй тырыштылар.

**Гөлҗамал әби**. Рәхмәт, әйдәгез, табын янына утырганчы сезгә әйтәсе сүзәрем бар. Исегездә калдырыгыз яме.

-Әти-әнидән алда өстәл янына утырырга ашыкма,

-Алдыңа куелган ризыкны ашыкмыйчан гына аша,

-ипине сындарып кына ал, валчыгын койма,

-буең җитмәгән ризыкка үрелмә, сорап кына ал.

- өстәл янынннан рәхмәтеңне әйтеп кит.

- алдыңа тастымал куй, аңа авызыңны , кулыңны сөртмә

- авыз кырыйларын сертү өчен кәгазъ салфеткалар куллан.

**Балалар**. Бик зур рәхмәт,тәртипле булырга тырышырбыз.

**Тәрбияче.** Ягез, өстәл артында дөрес туклану кагыйдәләре турында тагын нәрсәләр беләсез.

**Балалар.**

- Авызда ризык булганда сөйләшергә ярамый,

-Авызны чапылдатып, кашыкны тәлинкәгә бәрә-бәрә тавыш чыгарып ашарга ярамый;

-Терсәкләрне өстәл өстенә җәеп, аякларны селкетеп утырырга ярамый.




**Тәрбияче.**Үгет-нәсыйхәтләрең өчен зур рәхмәт. (Балалар Гөлҗамал апаны өстәл артына утырталар, аннан соң үзләре утыралар, алларына тастымал ябалар,сыйланалар )

**Гөлҗамал әби**. Иии, бик тәмле булды, рәхмәт балалар. Кем пешерде соң бу кыстыбыйны?

**Балалар** Без пешедек, пешерергә пешекчебез Гөлшат апа өйрәтте.

**Гөлҗамал апа** . Иии, менә бит. Пешекче бик кирәкле, дәрәҗәле һөнәр шул. Менә сез дә үскәч, зур булгач пешекче һөнәрен сайласагыз бер дә үкенмәссез. Кешеләргә куаныч китерәм диеп куанып кына яшәрсез.




**Тәрбияче**. Ак әбиебез безне куандырып кунакка керүегезгә, балаларга кирәкле үгет-нәсыйхәт, киңәшләр бирүегезгә зур рәхмәт.

**Балалар.** Рәхмәт Гөлҗамал апа (Кунакка рәхмәт әйтәләр, озатып калалар)



Татарстан Республикасы Балтач районы

муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

“Салавыч балалар бакчасы”югары кв. категорияле тәрбияче

**Борханова Гүзәлия Гәбделәхәт кызы**

***Татар халкының милли ядкарьләре буйлап сәяхәт ( маршрутлы уен)***

**Тема** : Татар халкының милли ядкарьләре буйлап сәяхәт( маршрутлы уен).

**Максат**: Татар халык милли ядкарьләре турындагы белемнәрен тулыландыру.

**Үстерү бурычы:** Татар халкының милли хәзинәләре аша сөйләмдә исемнәрне сыйфатлар белән бәйләргә өйрәтуне дәвам итү, алаларнын диалогик сөйләмен үстерү.

**Тәрбия бирү бурычы:** Татар халкының милли хәзинәләренә карата соклану хисе, сакчыл караш тәрбияләү.

**Белем бирү бурычы:** Татар халкының милли хәзинәләре булган гореф-гадәтләре, бизәнү җиһазлары, уеннары, мәкаль әйтемнәре белән таныштыруны дәвам итү.

**Төп белем бирү өлкәсе:** танып белү үсеше.

**Интеграль белем бирү өлкәләре**: социаль-коммуникатив үсеш, сөйләм үсеше, сәнгать-эстетик үсеш, танып белү үсеше, физик үсеш .

**Методик алымнар:** Сөйләмне һәм танып белү активлыгы, проблемалы ситуация, эзләнү эшчәнлеге, төркемдә эшләү эшчәнлеге.

**Материаллар һәм җиһазлар**: Маршрут картасы, видео хат, дидактик уеннар.

**Сүзлек өстендә эш:** Чулпы, изү, читек.

**Алдан үткәрелгән эш:** такмаклар ятлау, татар халык уеннарын уйнау, татар халкының милли киемнәре белән танышу, дидактик уен уйнау.

## Шөгыль барышы

## Кереш өлеш

- Бүген эшкә килгән вакытта минем телефоныма видео хат килде. Балалар, минем дустым бәлагә очраган, аны урманда Шүрәлеләр тоткынга алган. Балалар, исемен оныттым кем соң әле ул? Әйе, ул -Былтыр. Әйтегез әле, ул нинди әкияттән?

"Исәнмесез, балалар. Мин Былтыр исемле егет булам.Урманга утынга дип барган җиремнән мин Шүрәлеләр тоткынына эләктем. Тоткынлыктан чыгар өчен миңа аларның җәзаларын үтәрлек батыр, тапкыр дуслар кирәк. Нәкъ менә шундый балалар дип мин сезне күз алдына китердем. Сезнең бу җәзаларны үтәп чыга алуыгызга ышанып калам."( видео хат)

-Балалар, ярдәм итәбезме Былтырга?

Ә ул миңа җәзалар үтәр өчен юл картасы биргән иде.

-Ә хәзер юл картасына күз салыйк әле. Менә монда табышмак язылган.

Күрешергә кулы юк,
Сөйләшергә теле юк.
Аның белән күрешмәгән,
Киңәшмәгән кеше юк.

Балалар нәрсә булыр икән бу?(Китап.)

**1нче тукталыш.**

Димәк, безгә китап почмагына барырга кирәк. Картаны карыйк әле, анда нәрсә яшерелгән?- Алъяпкыч. Алъяпкыч серле, аны татар халкының милли бизәкләре белән бизәргә кирәк. (Татар халкының милли бизәге белән бизиләр)

**2 нче тукталыш.**

Картаны карыйк әле, хәзер без кайда барырга тиеш, нәрсә ясалган анда? (Чәй өстәле. Ул безнең кайсы почмакта?) Димәк без "Өй" почмагына барабыз. Монда хат яшерелгән булырга тиеш. Эзләп табыйк әле. (Хаттагы бирем: "Татар милли өстәлен бизәргә")

**3 нче тукталыш.**

Картаны карыйк әле. Өй почмагында тагы серле бер җиһаз бар дип күрсәтә. Карагыз әле нинди серле әйбер. Нәрсә соң бу балалар? Әйдәгез эзләп табыйк. Тукмакны балалар күреп ала. (Анда серле язу була. ) Хаттагы бирем: “Бу тукмак белән бәйле татар халкының милли уенын уйнарга” Нинди милли уен бар икән, белмисезме?

Әйдәгез, бергәләшеп “Тукмак тәгәрәтү” уенын уйнап алыйк әле . Бу уенны безнең әби- бабаларыбыз да бик яратып уйнаган.(Балалар түгәрәк ясап,тезелеп утыралар, тәрбияче тукмакны тәгәрәтеп җибәрә. Тукмак сабы кемгә карап туктый шул бала җәза үти)

**4 нче тукталыш.**

Балалар, картага күз салыйк әле, без кая барырга тиеш икән?

-Серле сандыкка барырга тиеш. Аны табар өчен безгә милли киемнәр почмагына барырга кирәк.(Сандыкны таптык) Сандык серле, аның җәзасы бар. Хаттагы бирем: “Татар милли өен бизә” (Чумадан эчендә музей ясала)

Булдырдыгыз балалар. Әйдәгез, юлыбызны дәвам итик, маршрутны картабыздан карыйк әле.

**5 нче тукталыш.**

Монда сабантуй рәсеме ясалган. Ә безнең группада кайда сабантуй күренешен табып була? (Эзлибез) Игътибар белән карагыз әле.

- Сабан туенда нинди милли уеннар уйнатылган? Исемнәрен әйтегез әле. Әйлән-бәйлән уенында уйнаучы кызларның калфаклары юк. Хаттагы бирем: “Кызларга калфак ясарга” Сабантуй почмагында безгә эшләр өчен остаханә почмагы ясалган. Әйдәгез, тиз генә өстәлләр артына утырып куркынычсызлык кагыйдәләрен искә төшерик. Кисеп ябыштыру күнекмәләрен искә төшереп эшләп алыйк. Зур итеп ясыйк та серле сүзләр белән кечкенәйтербез. (Тәрбияче балаларны артка каратып басытыра да серле сүзләр әйтеп калфакларны кечкенәгә алыштыра)

Картага күз төшерик әле. Нәрсә диелгән? (Шүрәле белән видео, экранда рәсем)

Видеодан былтыр сөйли, янында Шүрәле тора (Рәхмәт сезгә балалар, сез мине коткардыгыз)

-Бигрәк тапкыр балалар булдыгыз әле сез. Сез минем биремнәремне үтәп нәрсәләр белдегез соң?

-Карагыз әле балалар бигрәк хәйләкәр булган бу Шүрәле. Ниндидер бер милләткә генә хас булган уеннарны гына уйнаткан түгелме соң бу? Кайсы милләткә хас биремнәрне үтәгәнбез?

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Бала үсеше үзәге – Арча шәһәре 4 нче балалар бакчасы" муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе музыка җитәкчесе

**Закирова Раушания Наил кызы**

## ***"Бишек җыры"***

Халидә Фәйзрахманова тәрҗемәсендә Наталья Гусева сүзләре, Раушания Закирова көе



**ИСКӘРМӘЛӘР ӨЧЕН:**